PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 2 / 2023

СӨЮМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ШУРАВИ *ханымнар* *тарих*

әни, мин үзем БАЛАГА *ирек бирәбезме*

КАЛҖА *борынгы рецепт*

Гөлнара САФИУЛЛИНА:

«Авыл табибы халыкка күпкә якынрак».





СӨЕМБИКӘ

110

Елъязма

Без бүген: «Журналыбызны яратып, җан җылысын кушып эшлибез!» – дип кабатларга яратабыз. Алар, ягъни бездән алда килгәннәр дә шулай эшләгән... Араларында репрессияләргә дучар булганнар да бар... Төрмә салкынлыгы, гаделсезлекләр кичерүчеләр дә... Исемнәре аклану шатлыгын күтеп алучылар да... Журнал кызыклы, файдалы булсын, укучыны уй-гамьнәргә салсын дип иҗат газапларында янганнар... «Сөембикә» журналы битләре әнә шулай тарихка керә барган... Менә хәзер безгә шушы фотосурәтләрдән карауччы шәхесләр аша «Сөембикә» бүгенге көнгә килеп җиткән. Кыйбласын да, максатларын да югалтмаган! Бу сәхифәбез – кайчандыр журналыбыз өчен җан атып яшәүчеләр хакында.

«Сөембикә»нең беренче саны чыгуга быел 110 ел була! 1913 елда ул нәкъ менә «Сөембикә» исеме белән нәшер ителә башлый, революциядән соң «Азат хатын» дип үзгәртелә, ә аннан соң кабат үз исеменә – асылына әйләнеп кайта.



1937–1941 еллардагы «Азат хатын» журналының баш редакторы Рокыя Әхмәтшина (сулда) һәм журналист Мәрьям Дибаева.



Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Фото: Резеда Галиуллина

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасарлары 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламаның эчтәлеге (фото, текст) аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Гөлнара Сафиуллина
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 30.01.2023 ел.
Чыгу көне: 6.02.2023 ел.
Заказ С-0199
Тираж 7573

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык), П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

PRESSA





Фото: Анна Арахамия

Марсель ГАЛИЕВ

Ник ашыга сәгатьләр?

Син киләсе юлның карлары да
иртә-таңнан инде күрәлгән.
Мин дә күреп калыйм, диган кебек,
топольләр дә юлга төбәлгән.

Бар да нәкъ синеңчә киенгәннәр,
бу шәһәргә бүген ни булган?
Әмма кабатлану буламыни! –
синең караш синдә табылган.

Күрешүдән бәлки татлырактыр
көтә белеп көтү газабы.
Үзең белән түгел, күңел белән
аңлашудан тора азагы.

Син тагын да бүген кызганмадың
иске сәгатьләрен урамның –
ашыктылар бар да... Син күрмәдең
урамымның төнге буранын.

Күз кысышты мең-мең тәрәзәләр,
йокы керде барча өйләргә,
бер мин калдым, буран аръягыннан
син киләсе юлны күрергә.



Безнең тышлыкта

«Авыл җирендә, гомумән, авыру белән табиб арасында дистанция юк. Кибеткә кергәч, кемнеңдер сине туктатып, чирен сөйли башлавы, киңәш соравы – бездә гадәти күренеш. Баш тарта алмыйм – барысы да үземнекеләр бит инде алар.»

10

Кеше гомере

Гөлнур Сафиуллина

6



Шурави ханымнар

Чулпан Галиәхмәтова


18



Безнең заман герое

Мәдинә Авзалова

26



Абруй апа

Гөлнур Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

Заман һәм без

Алмагачның алмалары — 14
Камәрия Җамалетдинова

Мин үзем! — 22
Лилия Гәрәева

Татар дөньясы

Гөлзәлинәнең милли мозаикасы! — 34
Эльмира Закирова

Мәдәни тормыш

Елларымның багып торам күзләренә... — 38
Гөлзадә Бәйрәмова

Китапның бәхете — укучы уйлап бетерә алган фантазиядә — 45

Яшәеш

Безнең почта — 46

Гап-гади бәхет — 48
Раил Садретдинов

Мәккәдән — пирамидалар иленә — 50
Әлфия Самат

«Хатының — иң якын кешең...» — 54
Гөлнур Сафиуллина

Хуҗабикә

Сорау—җавап — 56

Кунак булсаң, тыйнак бул — 58

Томау төшүдән профилактика — 59

30




Арысландай батырлар
Алсу Шакирова

40



Авыл малае
Шәмсия Җиһангирова

60



Калҗа
Рамилә Закирова тәкъдим итә

PRESSA



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

1989 елның 15 февралендә ун ел барган Әфганстан сугышына нокта куела – Советлар Союзы соңгы хәрби колоннаны чыгара. Шулай итеп, «интернациональ бурыч» тарихы тәмамлана. Рәсми мәгълүматлар буенча, Әфганстан Демократик Республикасында барган гражданнар сугышында Советлар Союзы хакимиятенә ярдәм итәргә тели, әмма бу уңышсыз операция була. Ул вакыттан инде 34 ел үтсә дә, Әфган хатирәләре онытылмый, чөнки кеше хәтере компьютер түгел, мәгълүматны сызып ташлап кына булмый. Татарстаннан хәрби хәрәкәтләрдә 9358 якташыбыз катнаша, 520 егет яуда башын сала. Әфган сугышы ветераннары бер-берсенә шурави дип эндәшә: совет гражданнарын Әфганстанда әнә шулай дип йөртәләр. Сугышка төрле сәбәпләр белән совет хатын-кызлары да бара. Кемдер приказ буенча, кемдер акча өчен, кемдер йөрәге кушканга... «Партия сказала: надо! Комсомол ответил: есть!» дигән сүзләр бик актуаль була ул чорда. Хатын-кызларның күбесе госпитальләрдә һәм медсанчастьларда эшли. Алар сугышта катнашмый, әмма вакыты-вакыты белән гомерләрен ут астына куярга туры килә. Союздан барган 50 гә якын хатын-кыз Әфган сугышында һәлак булган дигән мәгълүмат бар. Әмма моны хәзерге көндә беркем дә тәгаенләп әйтә алмый. Күпме эзләп карасак та, хәтта Татарстаннан киткән хатын-кызлар санына да чыга алмадык... Татарстан хәрби комиссариаты да, иҗтимагый оешмалар да төгәл мәгълүмат булмавын әйтте. Әфганны үз күзләре белән күргән хатын-кызларны эзләп табып, алар белән сөйләшергә булдык. Ни дисәң дә, ул сугышның тарихта үз эзе бар...

ШУРАВИ ХАНЫМНАР

«Тормышым икегә бүленде»

– 1982 ел иде ул. Бервакыт хәрби комиссариаттан шалтыраттылар, – дип сөйли Любовь Коровина. – Хәрби бурычлы булгач, чакыруга барырга тиешмен. Ул чорда медицина хезмәткәрләре гаиләләре белән Германия, Чехословакиягә эшләргә китә иде, ә мине Әфганстанга җибәрергә телиләр икән. Мин, әлбәттә, баш тарттым. Аннан тагын берничә тапкыр чакырттылар. Комсомол булуымны искә төшерделәр, әйбәт хезмәт хакы, кайткач, төрле ташламаларга ия булачагым турында кат-кат сөйләделәр.



Аннан басым ясый башладылар. Мин кияүдә, 11 яшьлек улым үсә. Анысын да әйтеп карыйм, әмма файдасыз. Ахырда, ирем белән бергә китсәк кенә риза булам, дидем. Аны да җибәрергә вәгъдә иттеләр. Мин алдан киттем, ә ул соңрак килергә тиеш иде, әмма килмәде. Гаилә белән барырга ярамый, дип, рөхсәт бирмәгәннәр. Әфганстанда сугыш барганлыгын белә идем, әмма үләрмен дигән уй башыма да килмәде. Мин бит медицина хезмәткәре, солдат түгел. Аннан соң үлүчеләр турында берниндиi статистика да юк иде.

Мин килгәндә Кабулда 70 градус эссе иде! Тузан! Афганец (таулардан искән җилне шулай дип йөртәләр) исә башласа, бөтен җиргә ком тула. Юеш простыняга төренеп, комнан котылырга тырышабыз. Мин килгәндә әле палаткалар гына иде. Безнекеләр бик нык оешкан төстә эшләде: тиз арада модульләр төзеделәр. Өч ай Кабулда госпитальдә эшләгәннән соң, Кондузга җибәрделәр. Аны төньяк зонадагы иң канлы санбат, диләр. Вакытлыча дип кенә җибәргәннәр

иде, ике елга якын шунда эшләдем. Сугыш хәрәкәтләренә якын территория булгач, анда кешеләр бердәм иде. Без үзара бертуганнар кебек булдык.

Солдатларның сәламәтлекләрен тикшерер өчен төрле частьларга да очабыз. Очкычларга һөҗүм иткәннәрен беләбез, куркыныч. Үземне тыштан тыныч тотам, ә эчемдә – утлар өермәсе. Гомеремдә чиркәүгә йөргәнем юк, догалар белми идем, анда бик күп догалар өйрәндем. Берсендә Ташкурганга очканда безне утка тоттылар. Очучылар вертолетны җиргә утыртып өлгерде. Мин ни үле түгел, ни тере... Солдатларны тикшергәч, кире кайтырга кирәк, ә мин очкычка утырырга куркам. «Кайтмыйм, шушында калам», – дим. Шул вакыт безнең дивизия командиры килде. Ә командирларны куркынычсызлык өчен ике вертолет озатып йөри иде. Бөтен кыюлыгымны җыеп, командирдан үзләре белән алуларын үтендем. Хәлемә керделәр.

Безнең госпиталь бик яхшы җиһазландырылган иде. Андагы кебек инструментларым Казандагы поликлиникада да булмады. Ашау да бик яхшы. Әмма сугыш, яшь кенә егетләрнең яралануылары, үлүләре йөрәкне өзә. Хәрбиләр операциягә китүгә, яралыларны көтә башлыйбыз. Алар күп була торган иде. Берсенең дә ачыргаланып кычкырып ятканын, Союзны, язмышны сүккәннәрен ишетмәдем. Аяклары киселгән яшь кенә лейтенантны алып килделәр. Фамилиясен әле дә хәтерлим: Князев. Төркемен билгеләр өчен аннан кан алырга кирәк. Аны күргәч, кулларым калтырый башлады, кайсы яктан килергә белми йөдәдем. Каушап, система куелган штативка абындым. «Доктор, әкрен, егыла күрмәгез», – ди. Югыйсә үзенең хәле хәл бит инде! Ул соңыннан Мәскәүдә әфганчылар төркемен җитәкләде.

Безгә Союздан концертлар белән артистлар да килә иде. Эдита Пьеха ике тапкыр килде. Бер килүендә концерт алдыннан гына вертолет шартлап, хәрбиләр үлде. Җырчы шок хәлендә калды. Һәлак булган егетләргә багышлап җыр язарга вәгъдә итте. Гомерем буе аны тыңладым, әмма вәгъдә ителгән җырны ишетмәдем...

Нәкъ ике елдан кайтып киттем. Калырга өндәделәр. Фән белән шөгыльләнер өчен медицина хезмәткәрләреннән торган бер төркем төзеп, шуларның җитәкчесе булырга тәкъдим иттеләр. Кабулда яшәрсез, гаиләгезне үзегез янына алырсыз, диделәр. Әмма ризалашмадым, хәзер күңелемнең бер почмагында үкенеч тә яши... Сугышка барып кайтканнан соң тормышым икегә бүленде. Бөтен нәрсәгә мөнәсәбәтем, дөньяга карашым үзгәрде. Мондый сынау биргәне өчен язмышыма рәхмәтлемен дә.

Әфганстаннан кайтуга элекке эш урыныма урнаштым һәм гомерем буе Юдинода тимер юлчылар поликлиникасында эшләдем. Беренче елларда ниндидер хөрмәтләү бар иде, Союз таралгач безне оныттылар.

Яшьрәк булсам, махсус хәрби операциягә китәр идем. Украинадагы хәлләрне йөрәгемә бик якын кабул итәм. Егетләргә ярдәм кирәк бит. Анда киткән табибларга хөрмәтем бик зур!

«Барысы да хәтердә»

– Әфганга баруымның төп сәбәбе – фатир. Ә анда икешәр оклад бирәләр, өстәмә чек белән дә түлиләр, – дип бүлешә үзенең хатирәләре белән Нурия апа Тимергалиева. 69 яшендә булса да, яшь кызлар кебек ул. 50 еллык эш тәҗрибәсе бар, әле һаман хезмәт урынында – Казандагы 12 нче хастаханәнең кан салу бүлегендә эшли. – 1984 ел. Миңа 30 яшь. Тулай торакта яши идем, кооператив фатир алырга теләдем, әмма акча юк.



Ташкенттан танклар ташый торган йөк самолетына утырып, Кабулга очтык. Берзаман очучы чыкты да: «Всем перейти в носовой отсек», – ди. Берни аңламыйбыз. Ә тыштан безнең самолетка борчак аталар кебек. «Всем сказали!» – дип кычкырып җибәрүгә, тизрәк урыныбыздан тордык. Самолетыбыз атышка эләккән икән. Сугышның нәрсә икәнен беренче тапкыр шунда тойдым... Мине Кандагар госпиталенә билгеләделәр. Шул ук төнне яралыларны китерделәр дип уяттылар. Солдатларның яраларын бәйләргә куштылар. Ә минем хәлем китте. Югыйсә нинди генә җәрәхәтләр күрмәгән идем инде. Ничә көн юньләп йокламау, алҗу, һава басымы күпкә югары булу хәлне алгандыр, мөгаен. «Боевое крещение»не шулай уздым. Операционныйда өлкән шәфкать туташы булып эшләдем. Операцияләр, аннан соң чистарту, стерильләштерү, кварцлау... Әфганстанда һавада һәрвакыт тузан, еш кына афганец җиле исә, бөтен җиргә тузан тула. Килеп, чисталыкны тикшереп кенә торалар. Ризыкны ашап булмый, ком гына. «Теш казналарыгызны бер-берсенә тидереп бетермәгез, алайса тешсез каласыз», – дип өйрәттеләр. Хирургиядә эшләгәч, нинди генә яралар, имгәнүләр күрмәдем. Искә төшерсәм, әле дә йөрәгем авырта. «Земля в иллюминаторе» җырын ишетсәм (Нурия апаның күзләре яшьләнә. – *Ч. Г.*) Пашка Белыхны искә төшерәм. Ике аягы да юк иде аның. Минада өздергән. Ялкынсыну башлангач, кабат кистеләр. Ә мондый яраны тегәргә ярамый, үзе төзәлергә тиеш. Физрастворда чылатылган стериль бинтлар белән каплап кына куябыз. Аларны көн саен алыштырырга кирәк. Ачык яра бит ул! Авыртуны басар өчен бераз наркоз бирәбез, әмма аңында кала. Табиб аңа җыр-



ларга куша. Паша: «Земля в иллюминаторе», – дип җырлап җибәрә... Тагын бер афәт: пычраклыктан гепатит, корсак тифы кебек йогышлы авырулар котыра. Үзем дә ялга кайтыр вакыт җиткәч кенә гепатит эләктердем.

Ике ел буе тимерчыбык артында яшәдем, дим хәзер. Чыгып, офыкка таба йөгерәсе килә, әмма ярамый... Ике ел буе автомат аткан тавыш тынып тормады. «Автоматная очередь»не җибәргәндә тынычлап йоклый идек. Күз алдына китерәсезме, тынлыктан куркып уяна идек. Димәк, постта торган егетләргә нидер булган.

Килешү вакытым беткәч, кайтып киттем. Калсам, хәрби чин бирәселәр иде. Ә хәрбиләрне, сорап та тормый, теләсә кая җибәрәләр. Риза булмадым, югыйсә балам көтәме инде өйдә?!. Кайтып фатир аласым бар дигән уй белән генә яшәдем. Дөрес фикерли белмәгәнмендер, мөгаен... Барыбер фатир ала алмадым. Чиратка бастым, әмма һаман чигереп килделәр. Аннан соң Союз таркалды, Әфганстаннан алып кайткан акчам кассада янды. Шулай итеп, фатир да булмады, акчасыз да калдым, гаилә дә кора алмадым... Әтинең абыйсына «Бөек Ватан сугышында катнашучы» буларак фатир бирделәр. Шунда яшәдем. Безгә ниндидер ташламалар турында сүз дә булмады. Хәрби комиссариат ташлама тиеш дигән белешмә бирә, ә район хакимиятендә: «Вы только служащие советской армии», – диләр. «Сугыш хәрәкәтләрендә катнашучы» дигән таныклыкны да 2019 елда гына алдым. Әфганстанда танышкан иптәш кызым Маша таныклыкны алыр өчен, комиссариат белән ике ел судлашып йөрде. Безнең җәмгыятьтә «үземә мөмкин, әмма кешегә бирмим», дигән принцип яши шул... Үзем өчен түгел, егетләр өчен үпкәм зур. Бик күп яраланган солдатлар кайтты бит. Күбесенең тормышы кире якка тәгәрәде. Ялгызлык... «Беркемгә кирәкмим», дип, үз-үзенә кул салучылар да булмады түгел. Кеше язмышында сугышның иң куркыныч нәтиҗәләредер инде бу...

«Әфганстан – шәхси фаҗигам...»

– Бик тә Казан дәүләт медицина университетының стоматология факультетына укырга керәсем килә иде. Өч тапкыр имтихан бирдем, керә алмадым. Әфганстанга барып кайтучыларга рабфакка (!) керү өчен ташлама бирелүен белүгә, документларымны хәрби комиссариатка илтеп бирдем, – дип сөйли Казан дәүләт медицина университетының ортопедия стоматологиясе кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты Гүзәлия ханым Юдина. – Озак та үтми, җыенырга дигән хәбәр дә килде. Әнигә Германиягә йә Чехословакиягә барам, дидем, әмма ялганымны сизде. Мине хәрбиләр арасында икән дип төш күргән. «Өйдә урындыктан егылып төшеп тә үләргә мөмкин, документларым инде анда, кирегә юл юк», – дидем. Әфганстанга шундый зур чемодан белән киттем. Хәтта электр плиткасы белән кечкенә табага кадәр тыктым һәм... биек үкчәле туфлиләремне алдым. Сугышка баруымны аңлый идем, әмма яшьлек бит. Ком-таштa туфлиләремнең бик тиз эштән чыгачагын, ике ел буе Ташкент базарыннан сатып алган «мыльница» – резин тапочкалар киеп йөриячәгемне белми идем әле.

Хәрби комиссариатта кая баруыбызны беркемгә дә әйтмәскә куштылар. Кабулга барып җиту – үзе бер тарих. Ташкенттан хәрбиләрне озату пункты аша түгел, аэропорттан очканбыз. Бу инде безне моннан озаткан инструкторларның җавапсызлыгы. Әнә шулай Әфганстанга баручыларның югалу очраклары да булган. Дөньяда яхшы кешеләр бар бит ул, Казаннан бергә киткән Аня белән миңа да гел шундыйлар очрады. Алар ярдәме белән Кабулга – тарату пунктына барып җиттек. Килеп җитүен җиттек, ә чемоданнарыбыз юк. Ташкентта самолетка утырырга теркәлү узганда, бер үзбәк кешесе килеп: «Акча бирсәгез, чемоданнарыгыз үзегез белән барачак», – дигән иде. Ә безнең акча юк. Бер атна буе бернәрсәсез яшәдек. Мин шул вакытта якташ дигән төшенчәнең нәрсә аңлатканын белдем. Безнең Казаннан килүебезне әйткәннәрдер инде, ике солдат йөгереп килде. Якташлар икән. Менә шулар безгә бар кирәк-яракны сатып алып бирде. Югыйсә үзләренең дә артык акчалары булмагандыр...

Безне Баграм шәһәре янындагы медицина-санитар батальонына җибәрделәр (кыр почтасының номеры: 93982). Анда хирургия бүлегенә операция шәфкать туташы итеп билгеләделәр. Беренче көнне иртән шартлау тавышларыннан уянып киттек. Елыйбыз гына. «Дух»ларның явызлыгы турында әллә ниләр





ишетергә өлгергән идек. Аннан ату тавышларына ияләштек инде... Әфганстанда беренче күргән яралы – бала булды. (Гомумән, яралы балаларны күп дәваладык.) Аягы ядрә тиеп сынган. Зур носилкада сөрмә күзле кечкенә генә баланың канга батып ятуын күргәч, үземне бик начар хис иттем. Беренче елны аяк-кулы киселгән солдатлар күп булды. Союзда һәр икенче кеше кулсыз йә аяксыз йөрер инде дип уйлый идек. Әмма боларның берсе турында да якыннарыбызга язмадык. Ярамый. Хат «дух»лар кулына эләксә, алар өчен мәгълүмат булачак дип аңлаттылар. Хәзер аңлыйм инде: Союзда мәгълүмат таратырга теләмәгәннәр. Шуңа без, гадәттә, һава торышы, табигать турында яздык. Мин, мәсәлән, монда җылы, кояш, лаләләр чәчәк атып утыра дип яза идем. Беренче вакытларда килгәнемә үкендем, әмма бетте ул. Хирургларның тәүлек буе үзләрен аямыйча эшләүләрен күреп, үкенеп утырырга оят булгандыр. Ул чорда патриотизм көчле иде. Ышанасызмы, йоклап китмәс өчен нашатырь спирты кушылган су эчәләр иде. Әле бит күпме кан тапшыралар. Баш табибыз Алексей Васильевич Яковлев бер ел эчендә 10 литр (!) кан бирде. Кан бирә дә операция өстәле янына барып баса. Үзем дә ике елда 10 литр кан тапшырдым. Нәрсә өчендер түгел. Бер банка тушёнка белән бер банка куертылган сөт тиеш иде, әмма туйган идек алардан. Яшь кенә солдатлар кан югалтудан үлеп ятканда, кан бирми ничек түзәсең?! Патриотлык хисеннән тыш, намус та бар бит әле!

Сугышта да һәрвакыт соры тормышта гына яшәмисең инде. Яралыларның, үзебезнең күңелне үстерү өчен төрле бәйрәмнәр, концертлар оештыра идек. Союздан да артистлар килде. Берсендә Валерий Леонтьев концерты булды. Шуннан бирле ул минем иң яраткан җырчым. Әфганстанда бөтен частьларда чыгыш ясаган. Хәзер хәрби бәрелешләр булган җиргә бер тапкыр барып кайткан җырчыларның үзләренә пиар ясап йөрүләрен күреп гайрәт чигә.

Әфганстанда гомерлек мәхәббәтемне дә очраттым. Медсанбатта узган комсомол туенда күрдем мин аны. Сугыш хисләрне сүндерә алмый. Мәхәббәт тә, кавышулар да булды... Мин биегәндә, гел елмаеп карап торды ул. Аннан соң үзе дә биергә чакырды. Бездә даруханә башлыгы булып эшли икән, хәрби. Туйдан соң кайтырга чыксам – урамда көтеп тора. «Сезне озатырга буламы?» – ди. Ә минем бүлмә каршы якта гына. Бүлмәмә юл ул төнне озын булды: сөйләшеп йөрдек тә йөрдек. Төн тыныч иде, яралыларны да китермәделәр. Шулай аралашып киттек. Әфганстанда эшләвемнең икенче елы тәмамланып килә иде. Калырга үгетләделәр. Юдин (Гүзәлия апа ире Игорь Юдинны гел әнә шулай дип атады. – *Ч. Г.)* калырга теләгем барлыгын белгәч шатланган иде, әмма соңыннан: «Казанга кайт, укырга кер», – диде. Ул минем хыялым турында белә иде. Бер ел хат алышканнан соң Казанга кайтты ул. Мин рабфакта укый идем. Без язылыштык. Бераз Казанда булганнан соң ул үзенең Барнаулына кайтып китте. Әти-әнисе аның Әфганстанда хезмәт иткәнен белмиләр иде. Абыйсы фаҗигале төстә үлгәч, әнисе Игорь өчен бик борчылып яшәгән булган... Гомумән, әфганчыларның күбесе кайда булуларын якыннарыннан яшерә иде. Озак та үтми, Әфганстаннан безнең гаскәрләрне чыгара башладылар. Иремне каршыларга Термез шәһәренә киттем. Без аның белән бер атна Термезда яшәдек, аннан Барнаулга кайтып киттек. Анда бер атна яшәгәч, ул – Ташкентка, мин Казанга кайтып киттем. Самолет трабы буйлап күтәрелгәне күп еллар күз алдымда торды. Аны соңгы тапкыр күрүем булган...

Аерылышуыбызга бер ай да үтмәде, үлүен хәбәр иттеләр. Ничек үлүе хакында әлегә кадәр белмим һәм белә дә алмаячакмын. Сорамавың, белешеп йөрмәвең хәерле, диде егетләр. Соңгы тапкыр шалтыратканда: «Ташкентта калмаска иде, монда – мафия», – дигән иде Юдин. Ә ул частьтагы төрле даруларны, медицина җиһазларын Әфганстаннан чыгаруга җаваплы иде...

Шуңа да Әфганстан сугышы шәхси фаҗигам инде. Ирле хатын булып бары тугыз ай яшәп калдым, башка кияүгә чыкмадым. Югыйсә гаилә корыр кешеләр дә очрады. Күрәсең, мине Юдин җибәрмәгәндер. Барнаулга каберенә барып йөрим. Быел да абыйсы белән икесенең каберләрен тәртипкә китереп кайттым. Юдин артымда гел елмаеп басып торды кебек. Кызганыч, балабыз булырга өлгермәде. Җиңелрәк булган булыр иде.

Әфганстан сугышында булуым турында элек сөйләмәдем. Мине барыбер аңламаслар иде. Ишетеп кенә күз алдына китерү – бер нәрсә, ә үз күзләрең белән күрү – бөтенләй башка. Беренче мәлдә күпләр онытырга теләде шул аны. Кайберләре аракы белән дуслашты. Аларны да аңлыйм. Анда булучылар үзләренә бикләнде. Гомумән, сугыш үз эзен калдырмый гына үтми инде ул. Күпме гомер узган, әмма берсе дә онытылмый. Сугыш аша үткән кешенең тормышы сугышка кадәр һәм сугыштан соңга бүленә. Хәзер телевизордан хәрби бәрелешләр турында репортажлар карыйм да, кабат үткәнгә кайтам. Бүгенгеләр белән безнең хәтта йөзләребез бертөрле – эмоцияләрсез. Елмаябыз да кебек, әмма ул башка елмаю...

Фотолар: гаилә архивларыннан.





КЕШЕ ГОМЕРЕ

Телефон шалтырады да шалтырады. Әңгәмәбез күп тапкырлар бүленсә дә, аны читкә алып кую, тавышын басу мөмкин түгел – бу башка очрак. «Телефоным ялгыш сүнсә дә, үземне җинаять эшләгән кебек хис итәм... Бәлки мине эзлиләрдер, бәлки мин кирәктер?» – ди ул. Кайбыч районы үзәк хастаханәсенең баш табибы, анестезиолог-реаниматолог Гөлнара Илдус кызы САФИУЛЛИНА белән кеше гомере турында сөйләшәбез. Гомер исә көннәрдән, сәгатьләрдән, мизгелләрдән тора... Аның үз тормышында да онытылмас көннәр байтак. Һәм аларның бик күбесе башка берәүләрнең гомере белән бәйләнгән. Бердәнбер гомере белән...



Гөлнур САФИУЛЛИНА



Беренче көн

– Күршебездә яшәүче Сәхибкамал әби: «Синең белән рәхәтрәк, җиңелрәк», – дип, беренче тапкыр үзенә чакырып керткән көнне миңа ничә яшь булды икән? Мөгаен, 8–9 яшьләр тирәседер... Ул инде авырый башлаган иде бит. Янында утырам, сөйләшәбез... Күрәзәче дип әйтәләр иде аның турында – анысын белмим, әмма: «Кызым, үскәч, син врач буласың», – дигәне исемдә. Хәер, мин кечкенәдән үк курчаклар белән дә гел «больница» гына уйнадым. Алма агачыннан ерак төшми инде ул... Әнинең апалары да табиблар, әни үзе дә 47 ел медицина өлкәсендә эшләде – фармацевт иде, РФның «Сәламәтлек саклау отличнигы» билгесе белән бүләкләнде. Кыскасы, мәктәпкә укырга кергәндә үк үземнең киләчәктә табиб буласымны белә идем. Әнинең абыйсының кызлары Горькийдагы медицина институтына укырга керде. Мин дә алар артыннан киттем. Мәктәпне алтын медаль белән тәмамласам да, Казанда керә алачагыма ышанып җитмәдем. Имтиханнарга әзерләнәм. Утырам да елыйм, утырам да елыйм – авылны, әнине сагынам... Шунда аңладым: керсәм дә, укый алмаячакмын – өйдән болай еракта яши алмыйм икән. Беренче имтихан биргәндә үк махсус хата ясадым... Ә табиб буласы килә! Кайтып, документларымны Яшел Үзән медицина училищесына тапшырдым. ...Һәм үз-үземә сүз бирдем: «Мин институтка барыбер керәм!» Училищены «кызыл диплом»га тәмамладым һәм мине шул елны ук имтиханнарсыз, әңгәмә белән генә Казан дәүләт медицина институтына кабул иттеләр. Студент эскәмиясенә утырганчы, ярты ел Кайбыч участок больницасында эшләргә өлгердем – училищеда уку ел уртасында ук тәмамлана.

Роберт белән дә мин шул вакыт таныштым. Аварияләдән соң алып килделәр аны. Мотоцикл белән бәрелгәннәр иде: дусты үлгән, ә ул аңсыз... Роберт аңына килгәнче әнисе берничә көн янында утырды. Бик иркә егет кебек күренде ул миңа... Ике ел мин аннан качып йөрдем әле. V курстан соң без өйләнештек. Роберт Казан дәүләт университетын тәмамлады, ул – радиотехник, әмма: «Мин – авыл малае, авылга кайтам», – диде. Ә мин шәһәрдә калырбыз дигән идем... Соңгы курсны кулымда бала булган килеш тәмамладым, аннан бер ел интернатура уздым. Авылга кайткач, беренче тапкыр кызым белән капка төбеннән әйләнеп кергән көнем истә: Кайбычның әле яңа район булып оешкан гына чагы – бала арбасы белән дә йөрерлек юллар юк... «Ә группадашларымның барысы да диярлек шәһәрдә калды», дип моңсуланып уйлаганым истә.

Икенче көн

– Авыруга иң беренче үзем куйган диагноз? Әлбәттә, ул көнне хәтерлим! Мин эшкә чыкканда терапевт урыны буш түгел иде – йогышлы авырулар бүлегенә кертеп утырттылар. Сайлау мөмкинлеге юк... Авыруны кабул итәм, зарларын тыңлыйм, күңелемнән диагноз куям. Һәм... берәр сәбәп табып, күрше бокска чыгам – тизрәк китабымны актарам: «Ялгышмыйммы?» Диагнозларым дөрес булып чыккач, үз-үземә ышаныч артты... Йокларга яткач та, авыруның «тарихы»н кат-кат башыңнан уткәргән, аннан сикереп торып, китапка ябышкан чаклар хәзер дә бар әле ул.

Хастаханәдә анестезиолог-реаниматолог юк иде – укырга мине җибәрделәр. Аннан кайтып эшли башлагач кына медицинаның нәрсә икәнен чынлап торып аңлаганмындыр. Моңарчы сәгать дүрттә эштән кайтып китәсең дә, аннан инде сине берәү дә борчымый иде. Ә монда – тәүлек әйләнәсе кирәк булуың бар. Исемдә: Шуширмә авылыннан бер кызны алып килделәр. Машинадан төшкән дә юлны чыга башлаган. Тирә-ягына карамаган, күрәсең – КамАЗ бәрдереп киткән. Аңында түгел, сынмаган бер җире юк... Өч тәүлек без аның яныннан китмәдек. Күчерергә мөмкин булгач кына, Республика клиник хастаханәсенә озаттык. Исән калды! Медицинаның көченә мин беренче тапкыр шунда ышандым.

Өченче көн

– Көннәрнең төннәре дә бар бит әле... Иң авыры дигәндә шушы төнне искә төшерәм. Башта бер әбине алып килделәр: кулындагы кан тамырлары тыгылган. Аңа операция ясап кына чыгардык, «Ашыгыч ярдәм» бер яшь хатынны алып килде. «Аналыктан тыш йөклелек», кан киткән – операция кирәк. Өч сәгатьтән соң тәмамладык кына, алдагы пациентның кабат каны китте. Тагын операция өстәле артына бастык. Ул арада яшь ханымның гемоглобины бик төште. Бездә запас кан юк һәм аны дүрт сәгатьтән дә алдарак алып кайтып җиткереп булмый, ә кан менә хәзер үк кирәк, шушы минутта! Төн уртасында кайдан эзлисең аны – операцияне туктатып торып, үзем бирдем. 20 шприц кан салдык, ул хатынга азрак хәл кергәч, әбигә операция ясауны дәвам иттек. Таң беленгәндә – иртәнге сәгать дүрттә яңа авыруны алып килделәр: аңа да катлаулы операция кирәк булып чыкты. Иртәнге тугызда гына тәмамладык... Һәм, иң куанычлысы, аларның барысы да терелеп аякка басты! Район кечкенә бит: үзем ул чакта кан биргән хатынны кибетләрдә очраткалыйм. Мөрәле авылында яши, әлеге төнне ул да онытмыйдыр. Ә канны беренче һәм соңгы бирүем генә түгел...

Дүртенче көн

– Иң дулкынландырган көн? Җиде ел элек баш табиб вазыйфасына керешкән көнемдер. Коллективка мине Татарстанның сәламәтлек саклау министры Гадел Вафин үзе тәкъдим иткән иде. Хәер, хезмәттәшләремә ят кеше түгел идем – эшли башлавыма 15–16 ел иде ул чакта. Белгечләр гел җитми, әйткәнемчә, йогышлы авырулар бүлегендә дә эшләдем, кабул итү бүлегендә дә, участок табибы булып та... Берсендә Иске Тәрбиткә барган истә. Юл юк, буран – ат чанасына утырып бардык. Авыл кешесе ихлас бит ул. Хәл белергә керүеңне зур вакыйга итеп кабул итә. Урын өстендә яткан бер әбине икенче көнне «Ашыгыч ярдәм» белән район хастаханәсенә алып килделәр. «Нәрсә булды, кичә генә барысы да әйбәт иде бит?» – дим. Мин кергәнгә, дулкынланып, кан басымы күтәрелгән икән...

Бу урындыкка утырганчы ук, баш табибыбыз Газимагомед Магомедов ялга китте дә, бер ай аның урынында

Фото: Анна Арахамия

Һәр операция алдыннан беренче тапкырдагы кебек дулкынланам: нәрсә көткәнен белмисең...









калып тордым. Эшнең очы-кырые юк! Бу урында ничек эшләп була икән, тизрәк үзе чыксын иде дип йөрдем... Әйе, нинди вазыйфа йөкләүләрен белдем! Әмма бөтен нечкәлекләренә эшли-эшли генә төшендем. Авыру дәвалау белән, әйтик, биналарга ремонт ясату арасында аерма зур шул... Үлчәү тәлинкәсенә салсаң, баш табибның административ эшләре ягы басып китә. Анда торба тишелә, монда нидер ватыла, анысы кирәк, монысы...

Соңгы елларда бөтен машина паркын яңарттык – 14 машина кайтты безгә. Президентыбыз дүрт яңа «Ашыгыч ярдәм» машинасы бирде. Яңа гараж төзедек. Тәрәзәләр алыштырдык. Күпфункцияле караватлар алдык. 24 миллион акча бүлеп бирделәр безгә, шуның 12 миллионына яңа җиһазлар кайтарттык. Әмма нинди генә ремонт ясатсаң да, нинди генә җиһаз алсаң да, белгечләр булмаса, берни эшли алмыйсың. Беренче чиратта, җаннарын биреп эшләүче табиблар кирәк. Шөкер, андыйлар бар бездә.

Бишенче көн

– Көннәрнең исәбен югалткан чаклар булды. Коронавирус белән бәйле пандемия турында әйтәм. Без берничек тә коткарып кала алмаган беренче авырулар... Ковидның башланган гына чоры. Борындык авылыннан ирле-хатынлы бер парны китерделәр – янәшә палаталарда яттылар. Салганда хатынының хәлен артык авыр дип тә әйтеп булмый иде. Дәвалыйбыз, алга китеш бар шикелле. Кинәт ул сулыш ала алмый башлады, зәңгәрләнде һәм... Бездәге чарасызлыкны белсәгез?! Кулдан килгәннең барысын да эшләдек бит! Балалары борчыла: «Хәзер әтигә дә берәр нәрсә булса?» – диләр. Динамика әйбәт бит, дибез. Ә авыруның хәле бу юлы да кинәт кенә начарланды... Таң белән өзелде ул... Мин елыйм, мине кочаклап шәфкать туташы Сәвия елый: «Башка монда эшли алмыйм», – ди. Улына әлегә шалтыратмыйк, тагын өч сәгать булса да тынычлап йокласын, дип сөйләштек. Бөтен документларны тутырып сәгать дүрттә генә кайттым. Өй буйлап әрле-бирле йөрим, ничекләр генә әйтермен, дим... Безнең эштәге иң авыр ситуация бу. Андый авыр хәбәрне йә баш табиб, йә реаниматолог җиткерергә тиеш. Ә минем сайлау мөмкинлегем юк – икесе дә үзем. Нинди сүзләр табарга белмисең... Мондый хәлдән соң күзгә бик озак бернәрсә күренми: өйдә дә, эштә дә. Җанда да бушлык кына... Тагын бер нәрсә бар: шәһәр табибларыннан аермалы буларак, без һәр очракта да диярлек белмәгән-күрмәгән кешене түгел, ә бер танышыбызны югалтабыз. Безнеке кебек кечкенә районда яшәү һәм эшләүнең бер минусы бу...

Алтынчы көн

– Гомеремдә дә онытмаячак иң озын төн бар әле... Пандемия башланганда 20 кислород баллоныбыз бар иде. Алмашка тагын шуның кадәр алдык. Барыбер җитми! Төнге сәгать ике. Аппаратка өч-дүрт кешене тоташтырдык. Баллоннар бик аз калды. Апаска шалтыратам – алмыйлар, Буаны җыям – анда да җавап бирмиләр. «Бара торыгыз», – дип, машинаны барыбер чыгарып җибәрдем. Буада кислород тутырырга була иде – шалтыратып, баш табибны уяттым. 8 баллонны алар тутырып җибәрде. Сөйләшеп торабыз – машина кайтып җитәргә 20 минутлар калды. Әмма кислород бетте диярлек! Буш баллоннарны тартып чыгардык – төпләрендә аз булса да калгандыр, дибез. Соңгы 8–10 минутны ничек үткәргәнебезне үзебез генә беләбез. Берара хәтта аягым атламый башлады... Берьюлы дүрт кеше бит! Дүрт гомер!

Ковидтан соң эш бер бәйрәм кебек кенә тоела. Бер уңай ягы булды: грипп белән чирләп китсә дә, халык хастаханәгә килә хәзер – авырудан соң катлауланулар шуңа да кимеде. Кайбычның ковид госпитале аша исә 337 авыру узды. Моның нинди коточкыч зур сан икәне үзебезгә генә мәгълүм...

Җиденче көн

– Иң үкенечле көн?.. Иртәгәсен Робертның туган көне булырга тиеш иде. Кызым белән кереп кибеттән табынга дип әйберләр алдык. Салатка дип пешерергә чөгендер, кишер, бәрәңге куйдым. Үземнең җаным тыныч түгел... «Әтиең һаман кайтып җитми әле», – дип, кызыма әйтеп кенә бетердем, телефон шалтырады. Ирегез авариягә очраган, авыр хәлдә дип хәбәр иттеләр. Ярты юлга җиткәч, кабат шалтыраттылар: «Ул инде исән түгел...» – диделәр. Мин барып җиткәндә «Ашыгыч ярдәм» килеп киткән иде инде. Күңелне сыздырып үкенечле уй узды: «Күпме чит кешегә ярдәм иттең, ә үзеңнекенә...» Соңыннан куелган диагнозларны күргәч, аңладым – булыша алмаган булыр идем. Мин дә, башка берәү дә... Әмма үкенү юшкыны барыбер калды. Дүртенче ел инде аны югалтканга... Тормышта хәзер төп таянычым – әнием һәм абыем Илшат. Тагын – кайнатам белән кайнанам. Алар мине һәрвакыт якын итте. Кайнанам гел булышырга тырыша: «Кызым, син бит тәүлегенә 48 сәгать эшлисең», – ди...

Сигезенче көн

– Иң озын көн? Бар! Тик аны иң озын юл дип тә атарга буладыр. Узган көз берәүне китерделәр: пычак белән яралаганнар – бугазына эләккән. Шунда ук сулыш алу аппаратына тоташтырдык. Тик операцияне аңа Казанда гына ясый алалар иде – бездә андый белгеч юк. Юлга кузгалдык. Машина идәнендә аның янында тезләнгән килеш барам. Сатурация бер менә, бер төшә... Борылам да, машина тәрәзәсеннән карыйм: ерак калдымы икән? Кайбыч белән Казан арасын ике түгел, ә 20 сәгать узгандай булдык. Ниһаять, барып җиттек! «Син бит безгә мәет алып килгәнсең», – диләр. Нинди мәет, тизрәк карагыз, дим. Терелеп кайтты ул ир!.. Фаҗигагә тарыган һәркемне шунда ук Казанга, белгечләр кулына озата алмыйсың – бөтен очракта да юлга чыгып булмый. Башта әле канны туктатырга, пациентны шок хәленнән чыгарырга, кан басымын көйләргә кирәк... Андый вакытта авырулар гына түгел, туганнары белән дә эшлисең – аларны да ничектер тынычландырырга тырышасың. Яшермим, нигә бу юлны сайладым дигән мизгелләр дә була. Ә аннан авыру терелә һәм сиңа да канатлар үсә!

Тугызынчы көн

– Бәхетле көннәр... Буага спартакиадага бардык шулай. Соңыннан кафега кердек. Таныш түгел бер хатын көтмәгәндә яныма килде дә елый-елый мине кочаклый башлады. Берни аңламыйм! «Сез минем абыйны коткардыгыз!» – ди... Менә шундый мизгелләр өчен эшлибез инде.

Авыл җирендә, гомумән, авыру белән табиб арасында дистанция юк. Кибеткә кергәч, кемнеңдер сине туктатып, чирен сөйли башлавы, киңәш соравы – бездә гадәти күренеш. Баш тарта алмыйм: әйткәнемчә, барысы да үземнекеләр бит инде алар. Көнетөне телефон шалтырауга да күптән күнектем – район җирендә номерымны табу берәүгә дә авыр түгел. Ничек җавап бирмисең – беркем дә болай гына шалтыратмый бит.

Унынчы көн

– Борчулы көннәр... Җитәрлек... Хастаханәбезгә педиатр, лаборант-врач, психиатр-нарколог, участок терапевты, педиатр, лор, анестезиолог-реаниматолог кирәк. Белгечләр килми түгел, «Авыл табибы» («Земский доктор») программасы буенча шактый килделәр. Эшкә өйрәтәбез, ияләшәбез генә – биш ел уза да, алар китеп бара. 17 табибтан 3 се генә Кайбычта төпләнде. Әлеге программа бүген дә эшли, әмма соңгы елларда кайтучылар юк диярлек. Миллион ярым гына инде кызыктырмый бугай яшьләрне... Районыбыз башлыгы Альберт Илгизәр улы Рәхмәтуллин быел яшь белгечләр өчен ике йорт төзетергә вәгъдә итте – алар буш тормас дип өметләнәм.

Республикадагы кебек үк, бездә дә беренче урында – йөрәк-кан тамырлары авырулары тора. Бер участок терапевтыбыз дүрт ай укып, яңа гына имтихан тапшырып кайтты. Ул инде бары тик шушы авырулар белән генә шөгыльләнәчәк. Диспансеризация узу өчен район халкының хәзер барысын да чакырырга, китертергә тырышабыз. Авыл кешесе, гадәттә, соңгы чиккә җитмичә килергә атлыгып тормый ул... Узган ел шуның нәтиҗәсендә 11 онкология очрагы ачыкланды менә. Безнең район өчен зур сан... Димәк, шуның кадәр кеше гомерен саклап калдык дигән сүз...

Авыл табибы беренче чиратта үз-үзенә, үзенең белеменә ышанырга тиеш. Бездә бер табиб та үз белгечлеге буенча гына кабул итми: авыруны аякка бастыру өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Яшь белгечләргә гел кабатлыйм: кешене ягымлы, җылы сүз дә терелтә, дим. Ышанычын яуламасаң, авыру сиңа күңелен ачмаячак, сөйләмәячәк. Дөрес диагноз кую өчен аның эчке дөньясын да белергә кирәк... Авыл хастаханәсендә эшләү – яшьләргә тәҗрибә туплау өчен менә дигән мөмкинлек. Хәер, яшәр өчен дә! Бассейн, шугалак, парклар, кибетләр, мәктәп, балалар бакчасы – һәркайсы кул сузымында. Юк, мин инде үзем хәзер шәһәрдә тора алмас идем...

Унберенче көн

– Җитми калган көннәр? Бихисап! Берсендә циркка билет алдым. Башкалар кебек балаларга күрсәтәсе килә бит... Юк, барып булмады – ашыгыч операция килеп чыкты. Үпкәләделәр инде... Кунакка бармый калган чакларны санамыйм да... Гүзәл минем юлдан китте – табиб-стоматолог. Киявебез дә табиб, ул – микрохирург, Республика клиник хастаханәсендә баш табиб урынбасары. Миңа инде оник бүләк итәргә өлгерделәр... Камилә КФУда укый, дизайнер булырга җыена. Алар икесе дә кечкенәдән бик мөстәкыйль булып үстеләр. Мин гел эштә идем бит... Дөрес, башкача да яшәп булгандыр. Әмма хатын-кыз һәрвакыт аягында нык басып торырга тиеш дип санадым. Кызларыма да шулай, дим.

...Төне буе операция ясап, таң белән генә кайтып керәсең. Өйдә тыптын, балалар йоклый. Өсләренә ябасың... Җаныңа шунда бер тынычлык иңә. Роберт кайчак уянып: «Син бүген дә өйдә кунмадыңмыни?» – дия иде. Якыннарың сау-сәламәт булганда эшкә барып эшләп кайтуның берниндиавырлыгы юк аның...

Мәктәп еллары һәр кешенең язмышында иң матур, истәлекләргә бай сөенечле бер чор булып урын аладыр. Тормыш белән очрашу, белем ачкычына ия булу, зур коллективта тәрбияләнү, үзеңне шушы җәмгыятьнең бер күзәнәге итеп тоя башлау, милли үзаң формалашу – болар һәммәсе мәктәп чоры белән бәйле могҗизалар бит. Ә мәктәпне һәм бу мөһим вакыйгаларны Укытучы дигән гаҗәеп затлардан башка берничек тә күзаллап булмый.

АЛМАГАЧНЫҢ АЛМАЛАРЫ



Камәрия
ҖАМАЛЕТДИНОВА

Күзләр саен мәктәпләргә дулкын-дулкын булып балалар агыла, җитлеккән яшьләр исә зур тормыш агымына кушылып китә бара һәм олыгая башлауларын үзләре дә сизми кала. Ә менә укытучылар – бала тормышына нинди яшьтә, нинди халәттә, нинди холыкта килеп кергән булсалар, гомер буена нәкъ шундый булып калалар. Чөнки Вакыт чикләүләре Укытучы дигән илаһи затка кагылмый. Классташлар белән очрашканда да, телефон-интернет аша аралашканда да мәктәп елларын, укытучыларыбызны сагынып искә алабыз, гомеребезнең шул чорына бүгенге акыл, яшәү тәҗрибәсе белән карап фикерләшәбез.



Укытучыларыбызның кайсын гына алсак та, һәркайсы кабатланмас шәхес булган!

Урта мәктәпне тәмамлавыбызга бу язда 50 ел булачак. Җәен сабакташлар белән очрашу турында хыялланабыз. Һәм, әлбәттә, укытучыларыбызны барлыйбыз.

Заманында КХТИны тәмамлап, юллама белән Новосибирск шәһәренә эшкә киткән, шунда бүгенгәчә гомер итүче Рәис Ханнанов болай дип язган:

«Беркөн телевизордан укытучыларның күргәзмә ачык дәресләрен кызыксынып караган идем. Инде бүген илнең мәгариф министры «Ел укытучысы» дигән зур исемгә лаек булганнарны бүләкләде. «Нәкъ шундый педагоглар мәктәптә миңа ничәмә ел буена һәр көнне күргәзмә дәрес укытканнар икән бит! Ул чакта без моны шулай тиеш дип кенә кабул иткәнбез!» – дип шаккатып утырдым. Күңелдә хатирәләр җанланды. Һәркайсы үзенчәлекле, һәркайсы беркем белән чагыштыргысыз... Әйтик, математика укытучысы Клара апа Мөхәммәтшина үз фәнен башка дөньяви мәгълүматларга оста итеп бәйләп аңлатучы талантлы кеше иде. Хәтерләсәгез, Фарсы падишаһының да теше үтмәгән мәсьәләне – шахмат тактасына геометрик прогрессиядә бодай бөртекләре тезеп, нинди зур саннар чыгасын без 5 нче класста ук чиштек инде! Яшь химия укытучыбыз Хәниф абый Солтанов теорияне һичшиксез фәнни тәҗрибә белән раслап инандырырга һәвәс иде. Ә бервакыт практик эш вакытында водород бүлеп чыгарырга тиешле прибор... безне тыңламады. (Хәер, безнең шартларда мондый ихтимал булырга мөмкин икәнен тәҗрибәле лаборант Сәкинә апа кат-кат кисәткән иде...) Юк, беркемгә дә зыян тимәде, киресенчә, без тормышның язылган кагыйдәләргә генә буйсынып бармавын аңладык. Тагын бер яшь укытучыбыз – физик Йолдыз абый Шәрипов армия хезмәтен дә узган шәп егет иде! Дөрес, футбол уйнарга бик яратмый, әмма үз фәнен иң кирәкле фән дип теләсә кемне ышандыра белә иде! ВУЗга керү имтиханнарын «бишле»гә тапшырып, укытучыларымның өметләрен акладым дип шатланган идем. Нәкъ шушы фәннәр миңа гомерлек һөнәр сайларга булышты... Тел-әдәбият буенча да супер-укытучылардан тәрбия һәм белем алдык. Рус теле һәм әдәбияты укытучыбыз Гыйльменур апа Шакирҗанованың күпме җыр-романслар өйрәткәнен санап кына бетерерлек түгел! Кайчак әле үзем дә «Буря мглою небо кроет...» дип әкрен генә көйләп йөрим... Ә шагыйрә Клара апа Булатова дәресләре – үзе аерым тарих!

Болар барысы да безнең укытучылар! Алар әле күбәү! Һәм аларның һәркайсы шул заманда ук дәүләт бүләкләренә лаек булганын менә хәзер аңладым!»

Рәиснең бу сүзләрен сабакташыбыз Илсөяр Бакирова да хуплаган: «Әйе шул, без бик бәхетле чор балалары булдык. – ди ул. – Ә укытучыларыбыз барысы да махсус сайлап алынгандай сәләтле шәхесләр иде. Югары дәрәҗәдәге белемгә ия чын совет укытучылары!»

«Әнинең укучылар дәфтәрләре белән тулы сумкасы ничек ярылып чыкмаган! Төн буе шул дәфтәрләрне тикшерә, дәрес планнары төзеп утыра иде әнием. Сарайда кош-корт, җитмәсә, әле кәҗә дә бар! Әниемә ике сәгать йокы тия иде. Иншаны әүвәл башта үзе өйдә яза да дәрестә балаларга укый, аннан соң гына укучыларга темасын биреп, инша яздыра... Башы авыртканы исемдә калган. «Әнием озын гомерле булсын берүк», – дип, эчтән генә теләп ята идем. Ә әтием төннәр буе мәктәптә бөтен укытучыга яраклы итеп, тәфсилләп, расписание төзи, фотолар ясый, укытучылар чирләп китсә, үзе кереп, төрле фәннән дәрес бирә...»

Бу юллар исә Рушания Гыйләҗеваныкы. Укытучыларыбыз Азат абый белән Фидания апаның кызы ул. Азат абый инде арабызда юк, ә Шириязданов кызы Фидания Әхмәтҗанова узган көз үзенең 93 нче туган көнен каршылады! Һаман яшь күңелле, сөйкемле, зирәк үзе!

Чистай төбәгенең Каргалы авылында дөньяга килгән кызга Аллаһы Тәгалә тарафыннан бик күп күркәм сыйфатлар бүләк ителгән, һәм чибәр, акыллы, сәләтле Фидания туган гаиләсенең дә иң затлы кыйммәтләрен үзенә мирас итеп алган. Авылында урта мәктәпне, аннары Казан педагогика институтын тәмамлаган. Чуашстанның Батыр районы Шыгырдан авылында – укытучы, шул ук районның мәгариф бүлегендә инспектор булып эшләгән. 1954 елда Татарстанга кайтып, Әлмәт районының Ирекле авылында җидееллык рус мәктәбендә тарих укыткан. Язмышы аны тулы бәхеткә лаек дип санаган: 1955 елда кыз Яңа Кәшер урта мәктәбе укытучысы Азат Гыйләҗевка кияүгә чыккан һәм ире белән бер коллективта эшкә керешкән. Шуннан соңгы унбиш ел буена бу мөгаллимнәр гаиләсе Кәшер балаларының мәхәббәтен, авыл халкының ихтирамын һәм рәхмәтен яулап матур гомер кичерде. 1969 елда гаилә яңа төзелешләр белән шаулаган Түбән Камага күченеп китте, әмма алар калдырган яшәү рәвеше,



Азат абый белән Фидания апа Кама буенда. 1952 ел.

Авыл укытучысының көнкүреше гади халык тормышыннан күпкә мәшәкатьлерәк булгандыр.

тормышчан тәрбия һәм матур истәлекләр бүген дә безнең белән яши, һәм бу яктылыкны бүгенге яшьләр белән дә уртаклашасы килә.

Безнең Яңа Кәшер мәктәбенең бер гасырлык бай һәм игелекле тарихы бар. Һәм бу тарихның үзәгендә татар гаиләләренә генә хас булган тәртип һәм тәрбиягә нигезләнгән укытучылар коллективы тора. Бүгенге истәлекләрнең төп геройлары – менә шул коллективның ихлас җанлы мөгаллимнәре Фидания апа һәм Азат абый.

Ни дисәң дә, без үскән елларда «Укытучы бар яклап та үрнәк булырга тиеш!» дигән язылмаган кагыйдә бар иде. Гаиләң дә, балаларың да, холкың-фигылең дә, кигән киемең дә, бакчаң-хуҗалыгың да һәм башка бик күп якларың да шушы таләпкә буйсына. Әлбәттә, өйләнешеп, торак-хуҗалык булдырып, өч бала үстереп, мәктәптә укытудан тыш та барлык иҗтимагый эшләргә чумып, ул чорда меңнән артык хуҗалыгы булган тынгысыз җанлы Яңа Кәшер авылында үрнәк гомер итү өчен бик күп энергия сарыф иткәндер бу гаилә. Әмма алар шул югарылыкка ирешкән кешеләр. Без – балалар ул чакта моны үзебез аңлаганча, сабый күңеле белән генә бәяләгәнбез. Тормышның асылын исә ничәмә дистә еллардан соң гына, яши-яши генә аңлаганбыз. Әмма сабый акылы да ул тәрбияне күңеленең түренә салып куйган. Бу сүзләремә дәлил итеп, Фидания апа һәм Азат абый гаиләсе белән мәктәптән тыш та аралашкан укучыларының кайбер хатирәләрен китерәм.

Ландыш Салихова сөйли: «Без Фидания апалар белән бер урамда, күршеләр булып яшәдек. Һәм кызлары Рушания белән бер класста укыдык. Бала-чага һәрчак бергә җыелып уйный идек. Каникуллар вакытында алар, балаларының дус-ишләрен өйләренә чакырып, бәйрәмнәр дә оештыралар. Азат абый оста итеп гармунда уйнап, безне җырлата, биетеп тә ала. Бу минутларда Азат абыйның мәктәптәге иң таләпчән завуч булуы да истән чыгып китә. Шунда ук шигырьләр сөйлибез, төрле уеннар уйнап мәш киләбез. Яңа ел бәйрәмнәре аеруча истә калган. Тун киеп, билен ефәк яулык белән буган, бүрек кигән, зур ак сакаллы һәм... күзлекле Кыш бабайның чынлыкта Азат абый икәнен белсәк тә, бик тә күңелле иде. Җитмәсә, Кыш бабай һәркайсыбызга Яңа ел күчтәнәче салынган пакетлар да өләшә. Мондый бәйрәмнәр Фидания апа пешергән бәлеш һәм камыр ризыклары, өйдә ясалган компот белән сыйланып тәгәлләнә...»

Сирена Абдуллина дәвам итә: «Ул бәйрәмнәрне мин дә бик хәтерлим. Хуҗаларның күңел киңлеге шаккаттыра. Шуның кадәр бала-чаганы җыеп бәйрәмнәр оештыру өчен уңган-булган булу белән бергә, ул балаларны ничек бар, шулай кабул итеп, барысын да тигез күреп яратырга да кирәк булган бит! Әле ул тиктормас кунаклардан соң өеңне җыештырып тәртипкә салырга да көч кирәк ләбаса! Бу бит инде узган гасырның 1960–65 нче еллары. Ачлык булмаса да, гаиләләрдә ризыкның да чиксез-чамасыз түгеллеген хәтерлибез...

Мин кечкенәдән үк матур гына җырлый идем. Үзешчәннәр конкурсларына мине дә еш алып баралар. Үзебезнең авылда, аннан күрше авылларда, соңыннан район үзәге Әлмәттә чыгышлар ясыйбыз. Тормышлар алга барса да, ишле бала үскән гаиләләрдә кием-салым кытлыгы барыбер дә үзен сиздерде. Ул елларда миңа сәхнәгә чыгардай килешле кием табу кыен иде. Шундый чакларда Фидания апа миңа үз кызының матур киемнәрен кидереп, кеше арасына җибәрә иде...»

«Ә күлмәкләргә килгәндә, төн йокысын калдырып, әни үзе тегә иде, – дип, Рушания ачыклык кертә. – Әнием тегүче дә иде бит. Өлгеләрен ничек кисәндер инде, таң калам. Кечкенә балалар киемнәре булмаган бит элек, әни үзе теккән...»

«Тагын бер очракны сөйләми кала алмыйм, – ди Сирена. – Фидания апаларның өенә каршы якта сусыл яшел болын бар иде, ә анда Имай бабай чишмәсе дигән мул сулы чишмә челтерәп ята. Якын-тирәдә яшәүчеләр шул чишмә буена кер чайкарга йөри. Чишмәдән бераз читкә, яшел чирәм өстенә зур ләгән куеп су салабыз да керне шунда чайкыйбыз. Бер көнне мин дә кер чайкарга килдем. Көн дә салкынча, чишмә суы да кулны өтеп ала. Шулай да бирешмим. Әмма бер зур калын җәймәнең суын һич тә сыгып булмый. Әйләндереп-әйләндереп, шактый азапландым. Шунда ни күрим: өстенә җиңелчә кием генә элгән Фидания апа яныма килеп басты. Ул минем күшеккән сабый кулымнан җәймәне алып чайкады, суын сыгып бирде. Эш арасында тәрәзәгә күзе төшеп, чарасыз хәлемне күргән дә миңа шулай ярдәмгә йөгергән икән ул!.. Мин бу хәлләрне бүгенге тормыш, бүгенге кешеләр белән янәшә куям да таң калам!.. Кешелекле булырга өйрәткән тәрбия дәресләрен мин Фидания апаның тормыштагы гамәлләреннән алдым...»

Сөйләр сүзләр, хатирәләр бихисап. Бу гаиләнең Хуҗасы – җитмеш төрле һөнәргә ия Азат абый бик хуҗалыкчан кеше булса, аның насыйп хәләле Фидания апа уңганлыгы белән дан тоткан чын Хуҗабикә иде. Бакчада җиләк-җимеш, яшелчә, чәчәкләр үстерү серләрен, өлгергән уңышны кышка ни рәвешле әзерләү ысулларын, хәтта утырту өчен яшь үсентеләр һәм орлыкларны да алар тирә-күрше, таныш-белеш белән бик теләп уртаклашалар иде. Алар бакчасында үскән, халык телендә «золотая китайка» дип йөртелгән алмагачның үтә күренмәле җимешен авыз иткәч, «Әкияттәге тылсымлы алтын алма нәкъ шундый булган!» дигән инану балачактан бирле тамчы да үзгәрмәде.

Гармунда оста уйнаучы Азат абый һәм моңлы тавышка ия Фидания апа үзешчән спектакльләрдә, концертларда һәрвакыт катнашалар иде.

Азат абый фотога төшерү белән дә мавыга иде. Авылдашларның ул ясаган яшьлек фотолары авылыбыз тарихына багышланган китапларда да кыйммәтле мәгълүмат буларак урын алды. Миндә дә бала чакта ул төшергән

берничә фото саклана. Инде алтмыш елдан артык гомер узса да, аклы-каралы бу фотолар төсе уңмый-саргаймый торган сыйфатта калалар.

Бу гаилә язмышындагы шагыйранә матурлык, китапларда гына яши торган ихласлык бүген дә сокландыра. Алар үзләренең күңел халәтен, хыялларын көндәлек тормышка өлге итеп алган икән! Азат абыйның урыны оҗмахта булсын! Ә без – Фидания апаның укучылары – үзебез дә җиденче дистәне түгәрәкләп килгән чагыбызда, күңелдәге хатирәләрне барлап, гомер буена сакланган һәм еллар узган саен арта барган ихтирамыбызны Укытучыбызның шәхсән үзенә әйтә алуыбыз белән бәхетле!

Фидания апаның тумыштан килгән асыл сыйфатлары аңа гомере буена юлдаш булгандыр, һәрвакыт игелекле гамәлләргә генә өндәп торгандыр дип уйлыйбыз. Күңелендәге якты нуры, җанындагы яхшылыгы, зыялы булуы, зирәклеге, чаялыгы, уңганлыгы сокландыра. Шушы сыйфатлары белән үз нәселен-дәвамын гына түгел, ничәмә буын укучыларын да тәрбияләргә ният кылган мөгаллимә, асыл сөякле мишәр кызы ул!

Фидания апаның мөхтәрәм яше уңаеннан кузгалган якты истәлекләр аның гомер юлдашы сәләтле, зыялы, артык дөрес һәм таләпчән, шул ук вакытта гаҗәеп тыйнак Азат абыйның да, аларның замандашлары – хезмәттәшләренең дә күркәм образын яңартырга бер сәбәп булды. Чөнки бу истәлек геройларының һәркайсы холкы-фигыле, максаты һәм шөгыле белән бүгенге көн өчен бик тә кадерле затлар. Алар – үзләренең яшәү идеалын тудырып, шуңа ышанып һәм омтылып яшәгән һәм яшәүче ихлас шәхесләр. Алар үз кыйблаларын табып, замандашларын да шул тарафка юнәлтә белгәннәр, укучыларына да шул тәрбияне биргәннәр. Ә бу кыйбланы аларның һәркайсы үз нәселеннән мирас итеп алган бит. Бу кешеләрнең күбесе мөгаллимнәр династиясен дәвам итүчеләр – укытучылар. Зыялы нәсел балалары, язмышларын мәктәп белән бәйләмәгән очракта да, җәмгыять өчен бик тә тәҗел булган һөнәри тармакта талантларын раслап, үзләренә алмаш әзерләгән кешеләр булуына беребез дә гаҗәпләнми. Киресенчә, без моны шулай тиеш дип саныйбыз. Бу гамәл халык телендә дә «Алмагачның алмасы...» дип тыйнак бәяләнә...

Фидания апа белән Азат абый да – узган гасырның зыялы мөгаллимнәре, Югары Багражда гына түгел, бөтен Зәй, Сарман якларында билгеле укытучылар Мөгаттәрә апа белән Мирсәет абый Гыйләҗевларның нәселен дәвам итүче буын лабаса. Гаиләнең беренче сөенече Азат абыйдан соң янә өч ир бала дөньяга килгән. Бу егетләр бер тамырдан үскән гөлләр кебек бердәй тәрбия алганнар, белем-һөнәргә тиенгәннәр һәм гаилә корганнар. Кәләш сайлау һәркемнең шәхси зәвыгы булса да, нәсел тәрбиясе җан тоемлавы аша егетләр күңеленә үз теләген «пышылдаган», күрәсең... Менә алар – берсеннән-берсе затлы дүрт кыз, килендәшләр булып, бер гаиләгә җыелган. Яшьләр Азат–Фидания, Аяз–Нәкыя, Алмаз–Энҗе, Альберт–Лира булып кавышканнар. Исемнәренә генә карасаң да, бу тәңгәллекнең югары көчләр тарафыннан сайлануына шик юк! Хезмәтләре буенча дүрт киленнең өчесе – мөхтәрәм мөгаллимәләр, кечесе Лира фән-техника дөньясында үзен сирәк белгеч һәм остаз буларак таныта. Тумыштан күптөрле сәләткә ия дүрт егетнең һәркайсы күңеле тарткан белгечлекне алып рәхмәтле гомер кичерә. Азат абый әти-әнисенең юлын дәвам итеп – укытучы, Алмаз абый – табиб, Альберт абый инженер һөнәрен сайлый. Ә Аяз абый – кодрәтле каләм иясе, халык язучысы буларак таныла. Бу көндә бу дүрт гаиләнең дә балалары, оныклары бар. Яңа буын яшьләре исә Мирсәет агалар башлаган юлны заманча гыйлем, бабаларыннан килгән үҗәтлек белән дәвам итә. Укымышлы, талантлы Гыйләҗевлар нәселе – укытучылар һәм остазлар язмышы да ул. Яшәүнең мәгънәсен, гомернең кадерен алардан да дөресрәк аңлаучы һәм үткен гаделлек белән гавамга җиткерә алучы тагын кемнәр бар икән?..



Алда (сулдан уңга) бертуганнар Аяз, Азат, Алмаз; артта (сулдан уңга) укытучы киленнәр Фидания, Нәкыя, Энҗе. 70 нче еллар.



Укытучылар Мөгаттәрә һәм Мирсәет Гыйләҗевлар уллары Азат, Аяз, Алмаз, Альберт белән. 60 нчы еллар.

PRESSA

БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ

27 окт в 11:29

Здравствуйте. Я нахожусь сейчас в большом отчаянии. Нам с детьми через неделю отключат газ за долги. Дело в том, что мы все в долгах. Только за свет оплатили. Я одна живу с двумя детьми. Муж умер семь лет назад. В 19 году моя мама заболела раком. Поставили сразу 4 стадию. Мы боролись полтора года. В 2020 в октябре мамы не стало. И мы остались одни. Пока мама болела и когда умерла мы набрали кучу долгов и кредитов. Так как я не работала и ухаживала за мамой. После маминой смерти я тоже начала болеть. Проблемы со спиной и суставами. В мае переболела ковид и теперь ещё проблемы с легкими и сердцем. Дети получают пенсию но у нас почти всё уходит на долги. Я уже не знаю, что делать! Думала уже даже об суициде. Помогите пожалуйста, если можете. Я уже не знаю куда можно обратиться



elvira_mikhailova72

прокомментировал(-а): Спасибо вам всем, за добрые дела. Лет 5-7 назад одного дальнего родственника привезли хоронить, он пропал было, родные долго искали через полицию, не могли найти,нашли только мертвого. Нашли в Нижегородской области, без ног,видимо тоже так заставляли попрошайничать. А дома он ходил на своих ногах... Так толком и ничего не узнали родственники, что же с ним случилось... 30 мин.

Ответить



Мәдинә АВЗАЛОВА

Волонтерлык – һөнәр түгел, яшәү рәвеше. Ул моны күптән аңлады һәм... килеште.

Кешеләрне ничек бар шулай кабул иткәндә генә **дөньяда игелек артачак.**

...Аның арыганлыгы йөзенә чыккан. Көн әле уянып кына килә, ә аңа инде күпме кеше ярдәм сорап шалтыраткан. Ул аларның берсенә дә «юк», дими, үтенечләрен кире какмый. Ахыр чиккә җиткермәсәләр, кем иртәнге дүрттә телефонга ябышсын инде. «Ир кеше шалтырата, үзе елый. Инвалид икән. Әти-әнисе юк. Күптән түгел генә абыйсы үлеп киткән. Ялгыз калган. Кибеткә йөри алмый. Аннары... акчасы да юк дип аңладым. Ярдәм сорый. Эшкә килүгә үк аңа азык-төлек җибәрдек. Хәзер ул безнең карамакта», – дип башлый җитди проблемаларга кагылган бу авыр сөйләшүне «Душа России» волонтерлык хәрәкәте җитәкчесе Юлия Камил кызы Хәкимова. Әңгәмәбезне әледән-әле телефон шалтыравы өзә. Кемнеңдер өендә газ миче эшләми, кемгәдер документ рәсмиләштерү өчен булышлык кирәк, кемдер «Киемнәрем бар, кая алып килим», – дип кызыксына. Кыскасы, алар эшләмәгән эш, хәл итмәгән мәсьәлә юк та бугай. Әле дә әнә ул, эшкә килешли, урам чатында коляскада утырган инвалидны күреп алган да, ашыга-ашыга кемгәдер шалтырата. Бу салкында иртә таңнан башына бәла төшмәгән кеше ни эшләп йөрергә мөмкин?

– Мин ялгыз түгел, – ди Юлия сүзен дәвам итеп, – киләләр, шалтыраталар, язалар. «Ничек ярдәм итә алам?» – дип сорыйлар. Бу дөньяда битарафларга караганда, шәфкатьле кешеләр күбрәк. Мин моңа торган саен инана барам.

Дөньяны күптән инде аклы-каралы итеп түгел, ә бәлки, соры итеп, башкача әйтсәк, ничек бар шулай күрергә, кешеләрне ничек бар шулай кабул итәргә өйрәнгән волонтерның юлында – ул нинди генә сикәлтәле, авыр булмасын – рәхимле, мәрхәмәтле кешеләрнең очрап торуына бер дә гаҗәпләнмим. Җан авазы адәм баласын беркайчан алдамый ул. Бүгенге көндә «Безнең заман герое» дигән республика премиясенә лаек булган, волонтер буларак, Татарстанда гына түгел, бөтен илгә исеме танылган Юлия Хәкимованың үзе сайлаган, әлеге дә баягы җаны тарткан юлга аяк басуы балалар йортларына барудан, ятимнәр белән аралашудан башланган. Нәкъ менә аралашудан. Әти-әни кочагына, аларның күз карашына тилмереп торган бәхетсез сабыйларга, алып килгән күчтәнәчтән бигрәк, сөйләшү, серләшү җитми. 25 яшьлек Юлия, инде ул чагында үзе дә бала әнисе, елап-зарыгып әниләрен көткән сабыйларның ни өчен шундый хәлгә төшүләрен аңламый. Аннары... торабара барысы да үз урынына кайта. Баксаң, тормыш авырлыклары хатын-кызны тиз сындыра: кайсы эчә башлый, кайсы баласын ташлап өйдән чыгып китә... Бу проблеманы алдан кисәтеп куярга да мөмкин бит. Һәм ул шушы җаваплы эшкә алына. Хокук саклау органнары белән бергәләшеп уңышсыз гаиләләргә йөри башлыйлар. Кемнедер исәпкә куялар, кемнеңдер фатирына ремонт ясыйлар, кайберләрен эчүдән дәвалыйлар. Күпме гаиләләрне таркалудан саклап калдылар инде.

Качаклар

Ә шулай да, тәүлекнең кайсы гына вакыты булмасын, ярдәменә мохтаҗларны үз канаты астына сыендыра ул. Илдә барган күңелсез күренешләр шуңа китерде. 2014 елда Казанга Донбасстан качаклар – торырга урыннары, ашарга ризыклары булмаган балалы әниләр кайта башлады. Берара волонтер өч бүлмәле фатирына – әнисе һәм дүрт баласы янына 13 кешене сыендыра. «Әкренләп бу эшләр минем тормышыма, яшәү рәвешемә әйләнде», – ди ул хәзер. Дөрес, аның да авырлыктан сыгылып төшкән чаклары булган. «2016 елның бер көне иде, – дип елмая ул шул вакытларны искә төшереп. – Әле дә хәтерлим, җомга көн иде. Житте, булды, дидем. Туктарга кирәк. Ә дүшәмбе көнне миңа янә шалтыраталар. «Зинһар, ярдәмеңнән ташлама!» – диләр. Ничек юк дисең инде? Кыска «ялым» шуның белән тәгәлләнде». Украинадан чыгып китә алмаган әниләр, балалар турында, күңел ачуларга тотыласы акчаларны шунда җибәрү хакында сөйләп ала. Нәкъ шул вакытларда ярдәм пунктларын ачып җибәрүләрен исенә төшерә.

«Душа России» волонтерлык хәрәкәтенең формаль структурасы юк, ләкин бу аларга ай саен меңнән артык кешегә ярдәм күрсәтергә комачауламый. Өстәвенә, көн саен дистәләгән үтенеч, дистәләгән сорау. «Безнең үзебезгә дә ярдәм бик кирәк, – ди Юлия Камиловна, – чөнки бары да акчага килеп терәлә. Фатирга ремонт та, газ мичен алыштыру да, кемнеңдер коммуналь бурычын түләү дә, әледән-әле азык-төлек җибәреп тору да акча белән бәйле».

Соранучылар

Башкарган эшләрнең бу кадәресе, кем әйтмешли, айсбергның өске катламы гына. Иртә таңнан юл чатында коляскада утырган инвалидка тикмәгә генә игътибар итмәгән волонтер. Әлеге дә баягы юл чатларында, җир асты юлларында, зур сәүдә үзәкләре тирәсендә еш очрый алар. Ул бәхетсезләрнең һәркайсының үз тарихы, үз язмышы – куркыныч язмышы... Авыр хәлгә төшеп, урамда калган һәм нәтиҗәдә, «колбиләүчеләр» кармагына эләгеп, гомерләрен теләнергә мәҗбүр булып, тоткында үткәргән инвалидлар турында тыныч кына сөйли алмый. Ул күргән, ул кичергән вакыйганың һәркайсы тетрәндерә, уйланырга мәҗбүр итә. Әлбәттә, хәзер аларның барын да искә төшерү мөмкин түгел. Әмма берсен...

– Ул кеше элек хәрби булган. Аннары югары уку йортында укыткан, – ди Юлия Камиловна, хәтеренә мәңгегә уелып калган истәлекләренә бирелеп. – Курск шәһәрендә туган, Казакъстанда яшәгән. Хатыны үлгәннән соң, инде олыгаеп барганда туган иленә әйләнеп кайтмакчы була. Йортын сата, тик күчеп кайтканда бер тиенсез кала. Аны кый-

Фото: Анна Арахамия

Коллыкка төшкән инвалидларны коткару гаять авыр, чөнки алар даими күзәтү астында.





Фото: Юлия Хәкимованың соцчелтәр битеннән

ныйлар да, танымаслык хәлгә китереп, юл кырыенда ташлап калдыралар. Шундый җансыз, кабахәт кешеләр була бит дөньяда...

Ул шунда үлеп тә калган булыр иде. Аны үлем хәлендә кар чистартканда тракторчы табып ала. Картның колагына зыян килгән, бер күзе күрмәс булган, аяк табанын кисәргә туры килгән... Хастаханәдән чыгар вакыт җиткән, ә аның барыр җире юк. Акча турында әйтмим дә инде. Бер бина янында утырганда чегәннәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Тегеләре картны шундук эләктереп алган һәм теләнергә мәҗбүр иткән. Ләкин ул алардан качып китә алган. Шулай итеп, ул Мәскәүдән Казан приютына килеп эләгә.

Бу турыда ишеткәч, волонтер картны өенә ала. Башта күзләренә операция ясата. Аннары гражданлык хокукларын торгызу мәшәкате белән йөри. Карт бүген дә – алар гаиләсендә. Балалар, яратып, аңа «бабай» дип дәшәләр.

Коллыкка төшкән ул бичараларны коткару гаять авыр, чөнки аларны бер шәһәрдән икенчесенә күчереп йөртәләр. Алар исемсез, паспортсыз... һәм һәрдаим күзәтү астында. «Бездә дә бик күп кеше югала. Мөрәҗәгать итәләр. Ә без таба алмыйбыз. Сәбәбе бик гади: аларны башка шәһәргә алып китәләр. Монда бит туганнары, таныш-белешләре күрергә, эзләп табарга мөмкин», – ди волонтер. Һәм шунда ук «мин әфганчы» дип, хәер сорап йөргән ике аяксыз егет турында сөйләп ала. Волонтерлар аны видеога төшереп, социаль челтәргә куя. Зур тавыш чыккач кына эчке эшләр һәм тикшерү комитеты хезмәткәрләре эшкә алына. Нәтиҗәдә, Молдовадан килгән «колбиләүчеләр»не судка бирәләр. «Соңгы елларда җиделәп кешене коллыктан коткардык. «Әфган» егетебез хәзер интернатта яши. Хәлен белешеп торабыз. Бәлкем, өйләнеп тә җибәрер әле, – ди Юлия Камиловна.

«Душа России» волонтерлык хәрәкәтенең җылы җилләре Татарстанга гына түгел, бөтен илгә таралган. Меңләгән кешене үзенә тартып торган игелек көче аның исемен күренекле иткән. Чегәннәр кулына эләгеп, еллар буе хәер сорап йөргән әбине дә, Ростовтан табып алып, моннан өч мең чакрымдагы туган авылына кайтарганнар, унсигез ел эзләүдә булган Чиләбе егетен дә коллыктан азат итеп өенә озатканнар.

– Бу бизнес 90 нчы еллардан бирле килә, дөресрәге, чәчәк ата, – ди әңгәмәдәшем. – Соранучыларның әйтүенә караганда, алар көненә 10 мең тирәсе, ә аена 300 мең сумлап акча эшлиләр. Бигрәк тә бу ямьсез күренеш бездә һәм БДБ илләрендә киң таралган. Соңгы вакытта Казанга яңа корбаннар алып килгәннәр. Алар безнең күз алдында, ләкин коллыкта булуларын, кемнәндер бәйле икәнлекләрен исбатлау гаять авыр, катлаулы эш. Бу хәлләрне, оештыручыларны җаваплылыкка тартып, җитди җәза биреп кенә туктатырга мөмкин. Югыйсә алга таба тагын да ныграк, тирәнрәк тамыр җәячәк, чөнки ул, әйткәнемчә, бик керемле эш. Әгәр дә хәер эстәп торучы инвалидка ярдәм итәсегез килсә, полиция чакыртыгыз, килгәнен көтеп торыгыз. «Киткән, күрмәдек, тапмадык...» дип әйтерлек булмасын. Гадәттә шулай була. Шәхесен ачыклау өчен полиция аны бүлекчәгә алып барырга тиеш. Бәлкем, аны эзлиләрдер. Шул чагында чын туганнарын табу да ул кадәр кыен булмаячак. Ялган туганнары, алып китәргә дип, инвалидны бүлекчә ишек төбендә сагалап торалар. Ә теге бичара алардан курка һәм еш кына дөресен әйтми дә. Мин социаль челтәрдәге укучыларыма гына түгел, полиция хезмәткәрләренә дә мөрәҗәгать итәм: безнең белән элемтәгә керегез, ул кешенең гаиләсен эзләп табарга булышырбыз, кирәк икән, юлына билет сатып алырбыз. Шул коточкыч хәлдән ычкына алмыйча еллар

буе бер шәһәрдән икенчесенә бәргәләнеп йөри бит алар.

Аз керемле пенсионерлар

Волонтерлар алар турында азга гына да онытмый. Бүгенге тормыш шартларында – азык-төлеккә, коммуналь-торак түләүләренә бәяләр көннән-көн күтәрелгән бер заманда 8 мең пенсиягә яшәүне күз алдына китерүе дә кыен. Карт-карчыклар фатирга түли алмый, ашыйсы килгән ризыгын сатып ала алмый. Приставлар бернигә карамый банк карталарына арест сала. «Без бу проблеманы кат-кат күтәрдек. Аз керемле әби-бабайларның исәпләренә арест салмаска, дидек. Андый мохтаҗларга азык-төлек белән булышабыз. Хәзер без Казан шәһәренең социаль хезмәт күрсәтү үзәге белән эшлибез. Бергәләшеп ай саен азык-төлек таратып йөрибез: ярма, макарон, чәй, шикәр, ит консервалары... Көндәлек кулланыштагы бөтен кирәк-ярак, кыскасы. Ә бит ул әби-бабайларның күбесенең балалары бар». Кайчандыр республика клиник хастаханәсендә баш акушер-гинеколог булып эшләгән, картаймыш көнендә бик авыр хәлдә калган әбинең хәлләрен мисал итеп китерә. Деменция билгеләре күренә башлагач, кызы әнисен подъезд төбенә чыгара. Карчык озак вакытлар шунда яши. Күршеләре күрә, ярдәм дә иткәли. Әмма кая шалтыратырга, әбине кайда урнаштырырга кирәклеген берәү дә белми. Ә бәлкем, белеп тә шөгыльләнәселәре килмәгәндер. «Безнең телефонны белмәсәләр, һичьюгы 112 номерын җыярга була иде бит инде», – дип өзгәләнә координатор, шул хәлләрне кабат күз алдыннан кичереп. Сөйләгән арада, ризыклы пакетлар, төрле киемнәр белән шыплап тутырылган бүлмәгә алып чыгып, шуларны күрсәтеп керергә дә өлгерә. «Мохтаҗларга!» – ди ул эчке бер канәгатьлек белән. Үзенә бер тарихны сыйдырырлык хикәятен тыңлаганнан соң, мин дә үземчә бер дулкынлану, канәгатьлек кичерәм. «Ярдәм күрсәтү системасы җайга салынды», – ди ул. Димәк, бездә бу проблемага җитди карыйлар. Социаль яклау хезмәткәрләре көн дими, төн дими, бәйрәм, ял көннәренә карап тормыйча – волонтерлар шалтыратуга, шундук алар белән бергә булышырга алына. Алардан башка кыенга туры килер иде. Кәгазь эшләре генә дә никадәр бит! Инде килеп... кем булыша бит әле ул оешмаларга. Юлия Хәкимова шикелле, гомерен шушы изге эшкә багышлаган волонтерлар тагын кайда бар икән?! Аның изге эшләре турында легендалар йөри. 67 яшьлек Зөлфия Гайнуллинаны туганнары (туган дияргә яраса) тәрәзәсез, утсыз, сусыз, канализациясе эшләми торган бер бүлмәгә кертеп утырталар. Сукыр карчык озак вакытлар шунда яңгыр суы эчеп яши. Кешеләр китергән ризыкны ашый. Тагын шулай күпме дәвам иткән булыр иде аның михнәтле тормышы? Көннәрдән бер көнне могҗиза була. Әбинең хәлләре турында Юлия Хәкимова ишетә. Үз тирәсенә кеше хәсрәтен үзенеке итә белгән мәрхәмәтле кешеләрне җыеп, карчыкның бүлмәсенә ремонт, ә күзенә операция ясата. Карчык хәзер җылыда, чистада яши. Уты да бар, канализациясе дә эшли. Әби өчен ул да, аның ярдәмчеләре дә – чын геройлар!

Үзе турында

Хәрәкәт җитәкчесенең һәрнәрсәгә үз карашы, һәр вакыйгага үз фикере. Әйтик, гаиләләргә ташламалар биреп кенә калмаска, ә бәлки, көндәлек тормышларын да күз уңында тотарга, хәтта дәүләт биргән акчаның кайда, кемгә, нәрсәгә тотылуына кадәр белеп торырга кирәк. Бу бик мөһим, чөнки әниләрнең кайберсе иртәгәсе көн турында уйламый. Бусы да волонтер фикере. «Безнең хәрәкәт социаль челтәрләремә язылучылардан һәм гади кешеләрдән кергән акчага яши. Акча җитмәгәндә үз акчамны тотам», – ди Юлия Камиловна. Ул әле эшмәкәр дә. Аның, үзе әйтмешли, кечкенә генә тимерчелек цехы да бар әле. Бу эш аңа әнисеннән күчкән. Гомумән, Юлия гаиләсе турында сөйләргә яратмый. Дүрт баласы күбрәк әнисе карамагында, чөнки ул үзе иртә таңнан чыгып китә, кич соңлап кына кайтып ава. Көн туды исә дистәләгән проблемалар, кичектергесез хәл ителергә тиешле мәсьәләләр аны һәрчак киеренкелектә тота.

Ун ел инде менә шулай. Аның өчен чит проблема юк. Бер белмәгән кешегә дә булышырга, җанын бирергә әзер ул. Каян килгән аңа мондый сыйфат? Аңа шундый сорау бирәм. Ә ул, нәрсәсе гаҗәп инде аның дигәндәй, җилкәсен җыерып куя. Анда, бәлкем, әбисенең әнисе холкыдыр... Ул үзе дә еш кына шул турыда уйлый. Аның унсигез баласы булган. Шуның уналтысы фронтка киткән. Сугыш чорында инвалид әбисе тәрбиягә чит балалар алудан да курыкмаган. Хәтта авыр сугыш чорында, бер телем ипине бүлеп ашаганда да кешеләр бер-берсенә булышканнар. Хәзер безгә нәрсә комачаулый? Нигә булышмаска?! Юлия Камиловна шулай уйлый һәм эшли. Балаларын да кешегә, бигрәк тә ярдәмгә мохтаҗ булучыларга игътибарлы, шәфкатьле булырга өйрәтә. Бары да балачактан, кечкенәдән башланганын ул үз мисалында күрсәтә.

«Душа России» волонтерлык хәрәкәте башкарган гаҗәеп эшләр турында республикада гына түгел, илдә беләләр. Беләләр һәм ярдәм көтәләр. 2020 елны Юлия Хәкимова «100 подвигов обычных людей» дип исемләнгән китапның героинясы булган. Ә аңарчы – 2016 елда аңа, волонтер буларак, «Герой нашего времени» («Безнең заман герое») дип аталган республика премиясе тапшырылган.

«...Кеше үз кайгысы, үз бәласе белән өйдә бикләнеп утырырга тиеш түгел. Һичьюгы, күршеләре, якыннары күреп алырга, социаль хезмәт органнарына, хәйриячеләргә хәбәр итәргә тиеш», – дип кисәтә волонтер. Күреп алу, кичекмәстән ярдәмгә ташлану өчен, героебыз әйтмешли, җан шуны теләргә тиештер шул.



МИН ҮЗЕМ!



Лилия
ГӘРӘЕВА

Үзенең беренче тапкыр әнисенә булышканын кемнәр хәтерли? Шул чакта үзегезне зур кеше итеп, әниегезнең ярдәмчесе итеп тойганыгыз исегездәме? Әле «р» авазын да дөрес әйтә белмәгән телегез белән: «Бил, үзем!» – дип, ботинкаларыгызны мышный-мышный үзегез киеп маташа идегезме? Һәркемнең дә әнә шундый – «мин үзем!» диген чоры була. Үзем ашыйм, үзем киенәм, үзем юам... Бала күңелендә эшсөярлек орлыклары шыта торган чор икән ул.
Хәзер инде, әти-әни буларак, үз балагызны искә төшерегез. «Мин үзем!» – дип үрелгәндә ирек бирә идегезме сез аңа?
«Савыт-сабаларны юып куй әле», – дим кызыма. Булышасына өметләнеп тә әйтмим, киреләнәсен белеп торам. Дөрестән дә, әнә бүлмәдән: «Мин арыдым! Өй эшен күп бирделәр, абый юсын!» – дигән тавышы ишетелә. Абыйсына кушсаң: «Малайлар эше түгел!» – диячәк. Эш кушкан саен бездә шушы хәл. Син эшлә дә, мин эшлә...
Балаларны үзара чагыштырмаска кушалар кушуын да, бар бит ул андыйлар да: син әйткәнне ярты сүздән тыңлый, эш кушасы юк, үзе белеп эшли торган. Бүлмәсендә, өстәлендә – тәртип. Урыны да җыелган, киемнәре дә үз урынында... Ничек шулай тәрбияли алган бу баланы әти-әнисе дип шаклар катарсың. Әллә соң берәр сере бар инде?!

Чәчсен, түксен – өйрәнсен

Утыз еллык педагогик стажы булган Гүзәл Галиева әнә шул серләрне белә булыр. Ире Рәдиф абый белән өч егет үстерде алар. Рәмис, Рәдис, Илгизне өйдәге бар эшне тәгәрәп эшли, әти-әниләренә булышудан тәм таба торган итеп тәрбияләделәр. «Кышкарның иң тырыш малайлары», – диләр алар турында безнең Арча ягында.

– Гүзәлләргә барган идем, 3 яшьлек малае үтмәс пычак белән өстәл аягын кисеп утыра. Тагын берәр атна тырышса, тәки кисеп чыгара ул аны, – ди әни бервакыт. – Гүзәлдән үрнәк алып, балаларыгызны да анынча үстерегез, – дип нәсыйхәт бирә без – кызларына.

Укытучыбыз Илсөя апа Батталова сөйли: «Өчесе дә идәнгә түгәрәкләнеп утырганнар. Урталарында бер табак бәрәңге. Берсе әрчи, берсе яра, берсе турый. Әниләре өчпочмак пешерә икән».

Бәләкәйдән эшләп үсте алар. Бер килүемдә табак-савыт юып ятышлары иде. Берсенә – 6, икенчесенә 4 яшьләрдер. Терсәк тиңентен җиңнәрен сызганып алганнар, әниләре ике табакка су салып биргән. Өстәлгә урындык терәп менеп басканнар. Идән – күл, өстәл өсте – күл...

Күлмәк-ыштаннары инде сыгып алырлык.... «Һай, Гүзәл апа, бер эшеңне ун иткәннәр. Артларыннан тагын күпме җыештырасың була!» – дим, исем китеп.

– Юсыннар, суны сөртәсең дә аласың аны, – ди әниләре. – Эшләп карамыйча гына өйрәнеп булмый бит.

Белеп торам, бу савыт-сабаны уллары артыннан тагын бер кат юачак әле ул. Алар түккән суны сөртеп, кухняны тәртипкә китерү өчен дә шактый вакыты үтәчәк.

– Эшлим дигәндә тыймаска кирәк аларны. Кечкенә баланың һәрвакыт әнисе артыннан кабатлыйсы килә. Йөрсен шунда, эшләшкән булсын... Булдырасың, диген, мактап җибәр, – ди Гүзәл апа.

Менә эшсөярләр үстерүнең беренче сере ачылды да. «Кагылма! Ватасың! Пычратасың!» димәскә кирәк икән! Артларыннан җыештырасы күп була дип, күбебез балаларга эшләп карарга, өйрәнергә ирек бирмибез шул.

– Монда әни кешенең балаларның тырышлыгын кабул итә алу-алмавы да бик мөһим, – ди «Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» психологы Лилия Сафина. – Һәр әни дә моны кабул итә алмый. Әйтик, кызыбыз салатка яшелчәләр турыйм дип теләк белдерә икән, безгә ул җитәрлек вак турамый кебек тоела. Тәнкыйтьлибез, төзәтәбез, без теләгәнчә эшләвен таләп итәбез. Шул рәвешле хезмәтен кире кагабыз, иҗатын чиклибез.

Һәрнәрсәнең үз вакыты, дибез. Мәктәпкәчә кадәрге өлкән яшьләрдә бала кагыйдәләрне тизрәк һәм җиңелрәк үзләштерә. Бу үткен, шуңа күрә аңа кагылмыйбыз, монысы – пешерә, ераккарак куябыз... Шул рәвешле без балага бер яктан ирек бирәбез, ә икенче яктан кагыйдәләргә дә өйрәтәбез. Хәзер исә әти-әниләрнең күп көче баланы мәктәпкә әзерләп үтә. Аннары карыйбыз: балабыз уйнап туймаган, эшләргә өйрәнмәгән. Өченче класста кулларына энә-җеп тоттырып, сәдәф тагарга өйрәтмәкче булабыз, алар өчен мәгънәсез бер эксперимент кына булып тоела. Чынлап та, бу эш балага кызыклы булган вакыт инде узып киткән... Ул вакытны без башка нәрсәгә сарыф иткәнбез.



Фото: Анна Арахамия

«Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге»нең «Сердәш» психологик хезмәте психологы Лилия САФИНА:
«Баланың тырышлыгын әти-әнинең кабул итә алуы да бик мөһим. Бала өчен аның эшен хуплау гына түгел, ә шул эшнең кыйммәтен күрә белү әһәмиятлерәк».

Өч яшьтән соң инде соң

1950 нче еллар уртасында Масару Ибука исемле авторның «Өч яшьтән соң инде соң» дип аталган китабы дөнья күрә. Масару Ибука – «Талантлар укыту» оешмасының директоры һәм бөтен дөньяга билгеле Sony фирмасын барлыкка китерүче. Аның бу китабы япон педагогикасында чынчынлап революция ясый. «Беренче өч елда баланың шәхесенә нигез салына. Шушы вакытта баланың сәләтен ачу өчен барлык мөмкинлекне тудырырга кирәк», – дип саный ул. Тәрбиядә өч принципка таянырга кирәген әйтә. Беренчесе – балада кызыксыну тудырып, аны танып-белүгә омтылдыру. Икенчесе – холкын тәрбияләү. Өченчесе – иҗади һәм башка төрле эшчәнлеген үстерү. Шул ук вакытта төп бурыч – баладан гений үстерү түгел, аның акылын һәм сәламәтлеген арттыру, кешелеклелек, тырышлык сыйфатларын тәрбияләү.

Япон педагогикасында бала туганнан алып 5 яшенә кадәр – илаһи зат, 5 тән 15 яшенә кадәр – кол, 15 яшеннән башкалар белән тигез санала. Икудзи дип атала әлеге тәрбия алымы. Хәер, ул тәрбия алымы гына түгел, кешедә кечкенәдән социаль җаваплылык тәрбияләү фәлсәфәсе дә. 5 яшенә кадәр японнар баланы тыймый, ачуланмый, куркытмый...

– Балага үзен яратуларын белү бик мөһим. Ләкин бу матур сүзләр, иркәләүләр генә түгел. Баланы ярату – аның кызыксынуларын кабул итү, аңа үз вакытыңны бүлү ул. Ирек биреп, без үзебез дә аның психикасын, үзүзен тотышын өйрәнәбез, балабызны ныграк аңлый башлыйбыз, – ди психолог Лилия Сафина. – Японча тәрбияләү алымы дигәндә, балага ни теләсә шуны эшләргә ирек бирүне күздә тоту түгел ул. Шәһәр фатиры шартларында бу мөмкин дә түгел. Кысаларны киңәйтү дип әйтсәк, дөресрәк булыр, мөгаен.

Уенчык эчендә ниләр бар?

Гүзәл апа сөйли:

– Бишенче класста укыганда Рәдис аркалы урындык ясап куйган. Ныклыгы булмаса да, карап торышка чып-чын урындык. Әтисенең яхшы тактасын бозганын күрсәк тә, ачуланмадык. Файдалы эш эшлим дип, үзенчә тырышкан бит!

Әтиләре урынында башка берәү: «Яхшы тактаны бозгансың?» – дип, «пешереп» алырга да күп сорамас... Дөресен әйткәндә, урындыгы эшкә яраклы ук булып та бетмәгән бит.

– Алар үскәндә өйдә сүтелмәгән бер генә нәрсә дә калмагандыр безнең, – дип фикерен дәвам итә әниләре. – Мин мәктәптән кайтуыма үтүккә кадәр сүтеп куярлар иде. «Улым, ник сүттегез аны?» – дисәң, эчендә ни барын күрәсебез килде, диләр. Ничек ачуланасың инде? Өйрәним дип, яхшы нияттән сүткән бит ул. Яңа гына алган уенчык машиналарының да детален детальгә аерып куярга мөмкиннәр... Шулай өйрәнүләренең файдасыдыр – үсә төшкәч, ике иске велосипедтан бер яхшы велосипед, ике иске мотоциклдан берне җыеп, үзләренә йөрерлек хәлгә китерәләр иде. Хәзер әнә кер юу машинасы ватыламы, суыткычмы – беркемне дә көтеп тормыйлар, үзләре рәтли.



Айсылу ГАЛИӘХМӘТОВА,
«Татарстан» китап нәшрияты мөхәррире.
Кызлары Алиягә – 17,
уллары Айнурга – 14, Әмиргә 11 яшь.

Безне әти-әниләр, әйтеп эшләргә түгел, үзең белеп эшләргә тиеш дип өйрәттеләр. Башлангычта укыганда Юныс Әхмәтҗанов китабыннан карап «роза»лар пешердем. «Майны бетергәнсең», – дип сукмәде әни. Өченче класста укыганда булды микән, дөгеле җимеш бәлеше пешердем. Бөрттереп салмагач, дөгесе каты иде. Ачуланмыйча гына ашадылар. Әни: «Дөгесен бөрттерергә кирәк башта», – дип кенә әйтеп куйды. Өйдә шкафларны, диваннарны тегендә-монда күчереп йөртү турында әйтмим дә инде, гел үзгәреш ясап тора идем. «Үзегез белеп эшләгез», дигән сүз кайвакыт минем авыздан да чыгып киткәли. Балалар инде үзләре белеп эшли, үз вазыйфалары бар. Алиябез без әйткәнне көтми, үзе ашарга әзерли. Аның яшь тә сигез айлык чагында минем белән мантый ясаганда төшергән фотосы бар. Чәчләренә кадәр онга батып беткән, үзенең кечкенә генә уклавы белән камыр җәеп утыра. Улларым Әмир дә, Айнур да 3-4 яшьләрендә миңа кыстыбый пешерергә булышалар иде инде. Кемдер тузаннарны сөртә, келәмнәрне чистарта, кемдер гөлләргә су сибә. Ләкин шулай да үзләре белеп эшләү әле җитенкери димим.

Өч бертуганның балачагыннан тагын бер эпизод: бабайлары Фәрит абый ишегалдыннан кадак җыеп йөри. «Бер әрҗә кадакны җиргә кадаклап бетергәннәр бит!» – дип сукрана. Верандадагы озын эскәмиягә дә, өйдәге урындыкларга да әллә ничәшәр кадак кадакланган.

Тугызынчы, унынчы классларда укыганда шушы малайлар иске кар базларын сүтеп, яңасын ясап куйдылар. Төзи алмабыз, димәделәр. Әтиәниләре дә: «Тотынмагыз, булдырмассыз», – дип әйтмәде. Аннары өчесе бер бригада булып таштан абзар төзеделәр, өйләренең түбәсен яңарттылар. Нинди эшкә тотынсалар, кулларыннан шул эш килә. Белмибез, булдыра алмыйбыз дигән уй юк аларда.

– Хезмәт бәяләнергә тиеш. Баланың менә шушы, хәзерге нәтиҗәсеннән нindидер яхшы, уңай нәрсә күрү, аны бәяли белү бик мөһим, – ди Лилия Сафина. – Ни өчен балалар рәсем ясарга ярата? Матур ясагансың, дип, без бит аны мактыйбыз, ул рәсемне бер кадерле әйбер кебек күреп, стенага элеп куябыз. Эш белән дә шулай. Әгәр дә баланың тырышлыгы бәяләнми, аның тырышуына ихтыяҗ юк икән, ул бер тапкыр гына башкарыла торган акциягә әверелә, «комга сеңә». Уңышлы килеп чыккан эшен бала күңеленә салып куя. «Мин моны булдыра алам», – ди. «Әни, йомырка тәбәсе кыздырыйммы?» – дип сорый ул, бер тапкыр пешергәне яхшы килеп чыгып, үзен мактауларын ишеткәч. Бу хезмәт аның күңеленә рәхәтлек бирә.

Безнең һәркайсыбыз үзенчәлекле. Кемдер кул белән эшли торган эшләргә маһир, бу аның табигатеннән. Ул да интеллектның бер төре, практик интеллект дип йөртелә. Кемдер спортка, кемдер укуга хирыс. Бала кайсы эшне яхшырак башкара, нинди таланты бар – аңа ул эшләрне эшләп карарга ирек биреп кенә ачып була.

5-6 яшьләрендә баланың өйдә үз вазыйфасы инде булырга тиеш. Әнинең тормышын җиңеләйтү, аңа булышу өчен түгел, ә бала үзен хөрмәткә лаеклы итеп тойсын өчен кирәк бу. Хәзер бит баланы хөрмәт итәргә кирәк, дип күп сөйләнелә. Ләкин хөрмәт буш урында гына барлыкка килә алмый, ул нәрсәгә дә булса нигезләнгән булырга тиеш.

Күпчелек әти-әнинең төп хатасы – бала өчен үзләре эшләү. Без балабызны тискәре нәтиҗәдән сакларга омтылабыз. Велосипедын яки аяк киемен яңгыр астында калдыра икән, тизрәк барып алу ягын карыйбыз. Кайсы эшнең нәтиҗәсе нинди буласына ул үзе төшенергә, сабак алырга тиеш. Ул эшлисе эшне башкарып, без балабыз тормышының бер өлешен үзебез яшибез.

Кич белән балагызны бакчадан алырга килгәч, игътибар иткәнегез бармы? Әти-әниләр ике төркемгә бүленә анда. Берәүләр баласын үзе киендерә, ә кемдер сабыр гына көтеп тора. Уйлап карагыз әле: сез кайсы төркемгә керәсез?

Әлбәттә инде, балабыз эшсөяр булып үссен дибез икән, мактау, бүләкләү турында да онытырга ярамый. Тырышкан икән, эшне ахырына кадәр җиткерә алган икән, бүләкләгез аны.



Гүзәл ИДРИСОВА-БАҺ,
җырчы, педагог
Уллары Камилгә – 11, Рамилгә – 8,
Марсельгә 6 яшь.

Гаиләбездә төп мәкаль: кем эшләми – шул ашамый. Балаларның һәркемнең үз вазыйфасы һәм һәрберебезнең үз эш коралы бар. Бүген бу эшне эшлибез, иртәгә шуны, дип, көн дә план корабыз. Ә эшне эшләп бетергәч, балалар өчен берәр күңелле чара, үзенә күрә бүләк әзерлибез. Ул йә ишегалдында пикник ясау, учакта тәмлерәк ризык әзерләү була, йә киногa, кафега барабыз. Балаларны мактарга, канатландырып торырга кирәк. Бер тапкыр мактасаң, икенче юлы бу эшкә тагын да җаваплырак карый ул. Улларыбыз кечкенәдән үз янибызда эшләп үсте. Өй җыештырганда аларның һәрберсенә эш кушам – үз өстәлләрен җыештыралар, тәрәзә төпләреннән тузан сөртәләр, урыннарын җыялар.

Тәмлерәк әйбер пешерсәм, балаларның булышуларын сорыйм. Өчпочмак, мантыйларга бәрәңгене Камил турый. Җәй җитсә, көн дә миннән окрошка сорыйлар. Ризыкларын үзегез турасагыз, әзерләп бирермен, дим. Турыйлар, тырышалар, ләкин идәннәр ризык валчыгы белән тула инде. Аның да җаен таптык – бакчада турыйлар, эткә дә бер бәйрәм була.

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Сезнең кулларга елның икенче саны килеп кергән икән, димәк, без быел да – «Сөембикә» журналының 110 еллыгында да бергә булачакбыз!

Юбилей елын, вәгъдә ителгәнчә, бүләк өләшүдән башладык. «Сөембикә» журналына бер елга язылган иң өлгер беренче 110 укучыбызга ышандырган «Матурлык сандыгы» үз ияләренә барып ирешә башлады. Ул бүләкнең кайтавазына, сездән килеп ирешкән рәхмәт сүзләренә ничек куанганыбызны белсәгез!

Инде чираттагы бүләкләр белән сөендерер вакыт җитте. «Сөембикә» журналына 2023 елның беренче яртыеллыгына йә тулысынча бер елга язылып, квитанция күчермәсен безгә җибәргән укучыларыбыз арасында кыйммәтле бүләкләр уйнаттык. Зур тырышлык белән күңел биреп сайлаган ике иттарткыч, ике мультиварка, ике миксер, ике гриль үз ияләрен редакциядә күптән көтәләр иде.

Бүләк уйнату 23 гыйнвар көнне «Сөембикә»нең ВКонтакте битендә туры эфирда уздырылды. Барлыгы 427 квитанция хуҗасы катнашты. Бүләк уйнатуны бәйсез эксперт – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең PR-директоры Ләйсән Сафина күзәтте. Шунысы кызык: бүләк отучылар арасында журналга бер елга язылып, «Матурлык сандыгы»на да, кыйммәтле бүләккә дә ия булучылар бар! Алар өчен без икеләтә куандык!

Менә алар, безнең җиңүчеләр, кыйммәтле бүләк ияләре:

Венера Фатыйхова,
Арча (*иттарткыч*);
Фәнзилә Вәлиева,
Казан (*иттарткыч*);
Наил Зәйнәгиев,
Саба (*мультиварка*);
Айсылу Бәдретдинова,
Самара (*мультиварка*);
Рәзилә Асретдинова,
Казан (*миксер*);
Гөлшат Фәсахова,
Казан (*миксер*);
Ләйсән Газизуллина,
Кайбыч (*гриль*);
Гөлсинә Гыйльванова,
Арча (*гриль*).

Элемтә өчен редакция телефоны:
8 (843) 222-09-77

ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ ЧЫН КҮҢЕЛДӘН КОТЛЫЙБЫЗ!



«ТАТМЕДИА» АҖ реклама 16+


БУ СӘХИФӘДӘ ДӘ – БЕЗНЕҢ ЖУРНАЛ ТАРИХЫ. ДӨРЕСРӘГЕ, КАЙЧАНДЫР «АЗАТ ХАТЫН» («СӨЕМБИКӘ») РЕДАКЦИЯСЕНДӘ ЭШЛӘГӘН ЖУРНАЛИСТЛАР ЯЗМЫШЫ. ХӘЕР, АЛАР ЯЗМЫШЫ ИЛНЕКЕННӘН АЕРЫЛМАГАН ДА УЛ ЧАКТА...








Милләт Мәҗлесендә территориаль автономия яклылар фракциясе.
Рәсемдә: 5. Фатыйх Мөхәммәдьяров, 8. Әхмәдиев, 9. Сәлах Атнагулов, 13. Сәет Вахиди, 23. Абруй Сәйфи, 26. Хөсәенгата Габәши, 28. Галимҗан Ибраһимов, 30. Габдулла Шонаси, 33. Касыймов. Уфа. 1917 ел.





Гөлнур
САФИУЛЛИНА

АБРУЙ АПА

«...Ә Абруйны шактый газапладылар... Төннәр буе сорау алдылар аннан. Иртән генә кайта иде. Сорау алучыларга нәрсә – алар алышынып тора. Ә Абруйның йокламаганлыктан күзләре шешенә, күз төпләре кара янып чыга иде...»
Укыган саен, боларның барысы күз алдыма килеп баса да, өшеп китәм – эчемә боз салкынлыгы иңә. Аның белән бер камерада утырган Галия апа истәлекләреннән бу юллар. Ярый әле киңәш бирүче табылган – ул чакта нинди темага тотынуымны белгәч, язучы Фәүзия апа Бәйрәмова: «Кем белән очрашсаң да, сөйләгәннәрен көндәлегеңә язып бар», – дигән иде. Ярый әле сүзен тыңлаганмын. 35 ел элек башлаган бу дәфтәрем үзе дә тарих инде хәзер...

«А. С. Сәйфи үзен гаепле дип танымады». (Татарстан партия архивы, фонд –15, опись – 27а, дело – 582, 14 бит.)

Студент елларымның барысы да Абруй Сәйфи исеме белән бәйле минем. Фәнни җитәкчем, филология фәннәре кандидаты Розалина Мәрдановна Нуруллина җитәкчелегендә язган курс эшләрем дә, диплом хезмәтем дә аның хакында булды. «Иң беренче татар хатын-кыз журналистларының берсе» дигән бер юлга сыйган мәгълүматтан башлаган идем А. Сәйфи турында өйрәнүләремне. Тагын – репрессия корбаны икәнен белә идем.

Ул чакта очраклы рәвештә генә Фәүзия апа ярдәм итте миңа: «Бу – Мәрьям апаның адресы. Исәнлеген тәгаен белмим. Барып кара. Ә адресны Сәгадәт ападан алдым диярсең. (Аның кем икәне инде истә калмаган. – *Г. С.*) Кинәт кенә килеп керсәң, аннан кайтканнарның һәркайсының куркып, шикләнеп кала торган гадәте бар: белмәгән-күрмәгән кешегә ачылмыйлар... Абруй апа белән бер камерада утырмадымы икән Мәрьям апа?» – диде ул. Барысы да шулай башланды... Абруй Сәйфи турындагы хатирәләрне берәмтекләп – җөмләләп җыйдым.

Мәрьям апа – «Эш» (бүгенге «Ватаным Татарстан») газетасының баш мөхәррире Вәли Шәфигуллинның җәмәгате булып чыкты. Ирен «халык дошманы» дип кулга алгач, чират аңа да җитә...

– Без бит ирләребез өчен утырдык... Чакыралар да гел бер сорау бирәләр: «Ни өчен иреңнең халык дошманы икәнен белә торып, кирәкле органнарга хәбәр итмәдең?» – диләр. Аптырагач, әйттем беркөнне: «Соң үзегез уйлап карагыз: менә сез эшегездә ниләр булганны өегезгә, хатыныгызга кайтып сөйлисезмени?» – дидем. Шулай дип әйткәч кенә тындылар, мине сорау алып артык аптыратмадылар башка, – дип сөйләгән иде ул.

Мәрьям апа белән ул очрашу бүгенгедәй истә. Фатиры безнең тулай торак белән янәшә диярлек булып чыкты. Иске генә шифоньер, карават, өстәл, урындык... Өй эчендәге бөтен җиһаз – нибары шул. Хезмәт-төзәтү лагеренннан чыккач, аларның берсенең дә кире кайтып керер җирләре булмый: фатирлар тартып алынган, булган мал-мөлкәт таралган, таланган... Хәер, хәтта Казанның үзендә яшәргә дә рөхсәт ителми бит әле, шәһәр тирәсендәге районнарның берәрсенә генә урнашырга яраган. Кечкенә генә бу фатирларны алар барысы да бик соң – күп нужалар күргәннән соң гына алалар. Пенсия акчасы инде иң кирәген сатып алырга гына җитә – өстәл-урындыкка, тимер караватка гына. Кайчандыр алар иң авыр көннәрен бергә уздырган камера кебек буш, шыксыз, салкын фатирлар...

Әйе, Абруй Сәйфи белән «Черек күл»дә бер камерада утырган апаларны таптым мин ул чакта. Аларны күрергә, сөйләшергә өлгердем. Мәрьям апа Галия апаның адресын бирде, Галия апа – Зөһрә апаныкын, ә ул – Абруй апаның каенсеңлесе Һаҗәр апаныкын... Күңелләренә мәңгелеккә курку кереп оялаган бу ханымнарны сөйләштерү җиңел булмады: алар өчен тыелган темага кагылам бит. (Гомумән, кем мин, алардан миңа нәрсә кирәк, нигә гел киләм һәм нигә ул «җайсыз» сорауларны бирәм?) Тормыш аларны сак булырга өйрәткән иде шул...

Һәрберсенең язмышы – үзе бер китап язарлык.

«Мин партия әгъзасы түгел идем, сорау алганда Абруйга авыр булды әнә, коммунист кешегә», – дип сөйләгән Галия апаны искә төшерәм. Кая аңа җиңелрәк булсын инде? Казан химия-технология институты ректоры Зәки Гыймрановның хатыны ул. Ирен кулга алганнан соң озак та тормыйлар, аның артыннан киләләр: «Төнге сәгать уникедә каты итеп ишек шакыдылар. Улым барып ачты, «Әни – алар!» – ди. Вакытлы-вакытсыз визитларына күнегеп килә идек инде. «Сезгә безнең белән китәргә туры киләчәк», – диләр. Кайбер кәгазьләрне тутыргач, кайтып китәрсез дисәләр дә, камерага илтеп яптылар». 15 һәм 12 яшьлек ике улын Дәрвишләр бистәсендәге балалар йортына алып китәләр. Бу йорттан ул чакта көннәр буе елау тавышы гына ишетелеп торган... Бөек Ватан сугышы башлангач, Галия апаның уллары үзләре теләп фронтка китә һәм кире әйләнеп кайтмыйлар...

Көндәлегемә кергән исемнәрнең тагын берсе – Зөһрә апа Мостафина.

– Абруй – бик чая, тере хатын иде. Күңел төшенкелегә аның өчен ят нәрсә булды. Лагерьда утырганда Абруй һәм тагын берничә хатын-кыз кулдан шахмат ясап, шуны уйнап йөрделәр, – дип сөйләде ул.

«Тегеннән» кайтканнардан бары тик ул гына Казанда прописка алуга ирешә. «Язсагыз да торам Казанда, язмасагыз да. Беркая да аягымны атламыйм – балаларым монда минем», – ди ул. Ут чәчеп торган хатынга каршы төшәргә ничектер җөрьәт итмиләр... Үзе белән бергә кулга алынган иптәшләрен реабилитацияләүдә зур эш башкара Зөһрә апа. «Абруй Сәйфи эше артыннан да мин йөрдем. Ахырына кадәр очлап та чыга алдым», – диде ул.

Өлгердем, иренең сеңлесе Һаҗәр апа белән дә очраштым, аларда сакланган «Сәйфиләр чемоданы»н да ачтыра алдым (абыйсы һәм җиңгәсе турында чыккан мәкаләләр, алардан калган кайбер язулар сакланган чемоданны ул шулай дип атап йөртә иде), Абруй апаның үз кулы белән язган кәгазьләренә дә кагылдым... «Ул аны күреп белә» дигәч, Уфага – Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи ага Кудаш янына да чыгып киттем. Менә ул Сәйфи ага хатирәләре:

– 1915 елда «Галия» мәдрәсәсендә укый башладым. Галимҗан Ибраһимов һәм Фатыйх Сәйфи

«А. Сәйфи комсомол оешмасының кирәк-ярагына үзенең ярты хезмәт хакын биреп бара». (Татарстан партия архивы.)

белән танышуым да шушы көздә булды. Укудан тыш мәдрәсәнең китапханәсендә дә эшләгәнгә күрә, укытучылардан Фатыйх Сәйфи белән аеруча якыннан аралаша идем. Аның аша хатыны Абруй ханым Сәйфи белән дә.

1917 елның августы. Революциядән соң Уфада спектакльләр һәм әдәбият кичәләре ешаеп китте. Җәй урталарында, Корбан бәйрәме уңае белән «ирек»челәр «Җир һәм ирек» кичәсе уздырдылар. Кичә башланыр алдыннан Галимҗан Ибраһимов сүз сөйләде. Кичәнең беренче бүлегендә «Адашу» исемле бер пәрдәлек пьеса уйналды. Рольләрнең берсен Абруй ханым башкарды.

Абруй Сәйфи белән бергә бер концерт куюыбыз истә калган. Ул анда Сәгыйть Рәмиев сүзләренә язылган җырны башкарды. Әлеге җырның ике юлын бүгенгәчә хәтерлим:

Сугышларда йөргән җан дустыма
Шушы булсын минем бүләгем...

Бу җырны Абруй концерт саен җырлый иде. Башкорт язучысы Шәһит Ходайбирдинның «Башкорт хәрәкәтләре» китабында шундыйрак юллар бар: «Абруй җырлаганда сакаллы солдатлар да елады...»

Бу очрашулар, сөйләшүләр янына Татарстан партия архивында табылган документлар да килеп өстәлде: Абруй апаның берничә рәсми юлга сыйган тормышы шулай әкренләп җанланды.

...1890 елны Казан губернасы Чистай өязе Күлбай Мораса авылында (хәзерге Нурлат районы) туа ул. Иске Татар Әдәмсуы, Әҗе авылларында, аннан Әстерхан шәһәрендә татар мәктәпләрендә укыта. Соңыннан журналист һөнәрен сайлый, татар газета һәм журналларында «Нәкыя», «Абруй Гыйльманова», «Миләүшә» псевдонимы белән мәкаләләр, әдәби очерклар яза. Аның язмаларында шул чор сулышы: хатын-кызларны капиталистик эксплуатациядән коткару, революцион көрәш юлына тарту; февраль революциясеннән соң солдат хатыннарын берләштерү; Октябрь революциясеннән соң татар хатын-кыз эшчеләрне һәм крестьян хатыннарын совет төзелешенә, Октябрь казанышларын ныгыту эшләренә тарту мәсьәләләрен күтәрә... Һәр мәкаләсенең ахырында килеп туган хәлдән чыгу юллары һәм моның белән шөгыльләнергә тиешле оешмалар күрсәтелә. Әдәби тәрҗемә белән шөгыльләнә – татар укучысына А. Чехов хикәяләрен тәкъдим итә. Аның ире – күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм журналист Фатыйх Сәйфи-Казанлы. Революция елларында чыгудан туктап торган «Сөембикә» журналын кабат тергезеп җибәрүдә – «Азат хатын»ны оештыруда алар ирле-хатынлы икесе дә катнашалар. (1926 ел белән имзаланган бу архив документы нәкъ менә шул хакта: «Чакыру. Иптәш Азановага, А. Сәйфигә, Ибраһимовка, Мансуровка, Фатыйх Сәйфигә 21 ноябрь, чәршәмбе көнне сәгать икегә, өлкә комитетына, 7 нче бүлмәгә татар крестьян хатын-кызлары өчен журнал чыгару комиссиясе утырышына килергә». (фонд – 15, дело – 315, 301 нче бит). «Азат хатын» исемен Абруй Сәйфинең ире – пьесалар һәм романнар авторы, «Кызыл Татарстан», «Крестьян газетасы» һәм «Яңалиф» журналы баш мөхәррире Фатыйх Сәйфи-Казанлы тәкъдим иткән дигән фараз да бар.

Абруй Сәйфинең иҗтимагый эшчәнлеге – үзе бер аерым зур тема. Ул – Милләт мәҗлесе эшендә катнашкан, Казан һәм Уфа шәһәрләре Думасында депутат булган бердәнбер хатын-кыз. Ике шәһәрдә дә солдат хатыннары бюросын җитәкли. Казандагы беренче биш балалар бакчасын, тәрбиячесез калган өлкәннәргә, ятимнәргә йортлар ача... Үзәк Комитетның хатын-кызлар бүлеге инструкторы буларак, кантоннардан кайтып керми: Әгерҗе һәм Мамадыш, Бөгелмә һәм Тәтеш, Мамадыш һәм Чаллы...

Ул – җырчы. «Абруй Сәйфи... җырчы буларак югары бәяләнгән. «Казанда мәшһүр Абруй ханым Сәйфи концерты» дигән афишаны да күрдем. Репертуары, шул чордагы шәһәр музыкасындагы популяр җырлар белән беррәттән, татар, башкорт көйләрен дә үз эченә алган». Солтан Габәши «Милли моңнар» дигән җыентыгында Абруй ханым башкаруында язып алынган «Ишкәкче карт» дигән борынгы матур җырның ноталарын да китерә. Ә менә бу юллар шагыйрә Заһидә Бурнашеваның архивта сакланган бер хатыннан: «Абруй Сәйфинең тышкы күренеше: ачык, мөлаем йөзле. Сүзе белән һәркемне үзенә карата ала, кыю. Кешеләр белән бик тиз таныша, сөйләшергә сүз таба. Сәхнәдә – 1916 елдан. Уфада Кариев җитәкчелегендә һәвәскәрләр «Ямьсез тормыш» дигән постановканы куйганда Абруй Сәйфинең дә кайсыдыр рольне бик оста итеп уйнаганы исемдә». Р. Гыйниятуллинага дип язган шушы хатында Заһидә Бурнашева Җамалиева дигән кешегә А. Сәйфи турында истәлекләр язган дәфтәрен биреп җибәрүен һәм шушы көнгә кадәр кире ала алмавын да хәбәр итә. Ул дәфтәрне табу һаман да минем бер хыялым булып кала...

Аның бер эшчәнлеген икенчесеннән аерып алып карау мөмкин дә түгел. Ничекләр өлгергән! Әйе, барысы да әйбәт булган. Ә аннан... Аннан ире Фатыйх Сәйфи-Казанлы хөкүмәт башлыкларына һәм большевиклар партиясе җитәкчеләренә карата террористик һөҗүм әзерләүдә, милләтчелектә гаепләнеп кулга алына. 1937 елның көзендә инде ул атып үтерелә. Абруй апа өчен дә кара көннәр башлана. Әйе, «халык дошманы хатыны» дигән исем йөртү җиңел булмый... Татарстан партия архивында сакланган документтан: «ВКП(б)ның Казан шәһәре Сталин райкомы бюросы утырышы прото-

колы. Тыңланды: 1920 елдан партия члены А. С. Сәйфи эше. Район халык мәгариф бүлегенең партия оешмасы карары нигезендә А. С. Сәйфи, үзенең буржуаз милләтче булганлыгы өчен партиядән чыгарылган ире Ф. Сәйфи кебек үк ВКП(б) сафларыннан чыгарыла. Алар икәү квартирларында – башында Эльвов һәм буржуаз милләтчеләр торган троцкистларны җыеп ятканнар һәм А. Сәйфи партия оешмасыннан бу хакта яшереп килгән».

1936 елның 27 августында аны эштән дә чыгаралар. Бу вакытта ул Казандагы 12 нче мәктәпнең директоры була. «1936 елның 17 сентябрендә иремне кулга алдылар. Шул вакытта миңа Ф. Сәйфинең хатыны булганым өчен партиядән чыгарылуым хакында әйтелгән протокол күчермәсен бирделәр. Күчермәне алуга Мәскәүгә киттем. Райкомның бу карары турында жалоба биргәнче, Н. К. Крупская янына бардым. Надежда Константиновна, иремнең эше ачыкланмыйча, апелляция язарга кирәкмәс дигән киңәш бирде. Ул: «Иреңне аклагач, синең өстән дә бу гаепне төшерерләр», – дип аңлатты. Мин кайтып киттем һәм беркая да бернәрсә дә язмадым. 1937 елның 20 августында мине кулга алдылар һәм бернинди гаепсез килеш, махсус киңәшмә нигезендә хезмәттөзәтү лагерена 5 ел бирделәр». Абруй апа язган юллардан бу...

Лагерь, әлбәттә, аларны үзгәртә: рухларын яртылаш сындыра, сәламәтлекләрен какшата, хыялларны юкка чыгара... Торыр җир юк – Казанга кайтырга ярамый, эшкә алмыйлар... Абруй апа ул елларда үзенең әле тегүче икәнен дә искә төшерә: туган ягында авылдан авылга йөреп, тегү тегеп җан асрый.

1957 елның 31 гыйнварында Абруй Сәйфи аклана. ТАССР Верховный суды Президиумы чыгарган карарда: «...бу эштә аны гаепләрлек бернинди дәлилләр юк. НКВД каршындагы махсус киңәшмәнең 1937 ел 4 ноябрьдә А. А. Сәйфи эше буенча кабул ителгән карарын җинаять составы булмау сәбәпле, юкка чыгарырга» диелгән. Күргән газаплар, кичергән авырлыклар, килгән югалтулар өчен берәү дә гафу үтенми, әлбәттә. Әрәмгә үткән еллар да кире кайтмый...

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Игнатьевка бер төркем элеккеге хезмәттәшләре язган хат Абруй апаның соңгы еллары турында бик күпне сөйли. Аны тулысынча китерәсем килә: «Без, түбәндә имзабызны куючылар, КПСС әгъзалары сезгә түбәндәгеләрне хәбәр итәбез һәм үтенеч белән мөрәҗәгать итәбез. 1937 елда репрессиягә эләгеп, бүгенге көндә реабилитацияләнгән иптәшләр арасында 1920 елдан КПСС члены булган А. Сәйфи дә бар. Менә бер елдан артык инде иптәш А. Сәйфи үзенә торак алу артыннан йөри. Әмма хезмәт ияләре депутатларының шәһәр башкарма комитеты советы аның үтенечен әлегәчә канәгатьләндерми. Үзенең почмагы булмаганга, ул әле – бер, әле икенче танышларында яшәп йөрергә мәҗбүр.

Аңа инде 70 яшьтән артык, каты авыру да. Еш кына янәшәдәгеләрнең ярдәменә мохтаҗлык кичерә. Тоткынлыкта яшәгәндә ул бөтен нәрсәсен югалтты һәм картлык көнендә бернәрсәсез калды: караватт куеп ятар, өстәл куеп ашар почмагы юк аның хәзер.

Бүгенге көндә ул Косогорная урамы, 67 а йортта тора. Тора диюебез: бусага төбендә, җәелмә ятакта йоклап йөри.

Иптәш А. Сәйфи хәзер пенсиядә. Ул элеккеге укытучы. Үзенең педагоглык эшчәнлеген 1912 елда Әстерхан шәһәрендә, Татар хатын-кызлар классында башлый. Реакция елларында ул «Идел» газетасы (ул чорда иң алдынгы газета булып санала) битләреннән бик кыю чыгышлар ясый. Н. Ушинский кебек атаклы педагогларның идеяләрен тормышка ашыру өчен көрәш алып бара.

Бу прогрессив карашлары өчен аны реакцион татар буржуазиясе эзәрлекли. 1915 елда ул мәктәптәге эшен калдырып, башта Казанга, аннан Уфага китәргә мәҗбүр. Уфадагы татар хатын-кызлар мәктәпләре Диния нәзарәте башлыгының – мөфтинең сеңлесе Мәрьям Солтанова тәэсире астында була. Солтанова А. Сәйфинең демократик элементларны мәктәпкә кертүеннән куркып, аңа укытучылык эшен бирүдән кискен рәвештә баш тарта. Бары тик Февраль революциясеннән соң гына ул мәктәптә үзенә лаек эш алуга ирешә.

Бөек Октябрь социалистик революциясен ул сөенеп каршы ала, совет властен ныгыту өчен үзенең көчен кызганмый. Хатын-кызларга совет власте һәм коммунистлар партиясе биргән хокукларның тормышка ашуы өчен бик нык тырыша.

Ул эшче хатын-кызларга – аналарга багышланган бик күп мәкаләләрнең, хикәяләрнең авторы булып тора. 1927 елда, Октябрь революциясенең унъеллыгына аның «Татар хатын-кызлары азатлык өчен көрәш юлында» дигән китабы чыкты, ул китап әле бүген дә тарихи белешмә булып хезмәт итә.

Аның бөтен бу эшчәнлегенә без шаһитлар идек. Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соң да озак вакытлар без үзебез дә укытучы булып эшләгән кешеләр. А. Сәйфинең соңгы вакыттагы хәле безгә бик авыр тәэсир итә. 1937 елда да ул бер гаепсезгә рәнҗетелде, аны үзенең яраткан эшеннән – яшь буынны тәрбияләүдән аердылар.

Пенсиясен ул педагог буларак ала.

Сәламәтлеге соңгы чиккә җитеп какшаган, ул дәвалауга, үзен карауга мохтаҗ.

Без, иптәш Игнатьев, аңа торак алуда булышлык күрсәтерсез дип, сезгә зур үтенеч белән мөрәҗәгать итәбез. Калган ярдәмне оештырырга без үзебез дә әзер. Кәримов Х. М., Шайнурова Ш. С., Кәримова З. Ш. 25 гыйнвар, 1958 ел». (Татарстан партия архивы, фонд – 30. опись – 3, дело – 892, 39–40 нчы битләр.)

Абруй апа 1960 елның 5 февралендә вафат була. Аның турындагы бу язманың нәкъ менә үзе бар итүдә катнашкан журналның февраль санына керүе гади очраклылык түгелдер. Рухы шат булсын!

Фотолар: редакция архивыннан.



АРЫСЛАНДАЙ БАТЫРЛАР



Алсу ШАКИРОВА

– Безне авылда гына түгел, якын-тирәдә дә «Каравайнықылар» дип йөртәләр. Исем белән әйтсәң дә юк. Әнә шул «Каравай» сүзен ишетүгә: «Ә-ә-ә, беләм, беләм», – диярләр инде. Мәгъсүмнең бабасы эш белән Казанга еш йөри торган булган. Балаларга һәрвакыт: «Мин сезгә түгәрәк ипи алып кайтам», – дип ышандырып киткән. Каладан кайткан авыз суларын китерерлек түгәрәк ак ипидән авыз итәр өчен бала-чага көне буе капка төбен саклаган. Әнә шул ак калач алып кайтучы бабаларына ияреп калган кушамат, – дип, Фәния апа нәсел тарихын сөйләп ала.
Бүген дә, түгәрәк ипи кебек, урамның бер башында оешып, күрше дә, туган да, бер нәсел дә булып яшәп яталар Фәния апа белән Мәгъсүм абый Камалиевлар. Ләкин без бүген аларның каршында гына, нәселнең төп йорты урынында йорт җиткереп, үз түгәрәк тормышларын төзегән Гөлшат һәм Руслан САДЫЙКОВларда кунакта.

Гомерлек сабак

«Гөлшат – Русланның бәхетенә туган кыз», – диде Олы Мәтәскә авылы мәктәбе директоры Марат Сөнгатуллин. Мәктәп яшендә укытучыларының күз алдында диярлек очрашып йөри башлап кавышкан бу парның уңышларына бик сөенә коллектив. Җиде ел очрашып йөри алар. Руслан, шаяртып: «Тәпи киткәннән бирле», – ди. Тормышның ачысын татырга өлгергән егеткә Гөлшат белән очрашып йөри башлавы әнә шул җиргә нык басып атлап киткән кебек тоелгандыр, бәлки. 8 яшендә дөм ятим кала малай. Әби-бабай тәрбиясендә үсә. Әбисе бакыйлыкка күчкәч, бабасы белән генә кала. Бөек Ватан сугышыннан исән-сау әйләнеп кайткан ветеран Салих бабайның холкын авылда белмәгән кеше юк. Кырыслыгы, таләпчәнлеге белән аерылып тора ул. Бабасының эш белгән кулы, үткен күзе астында бөтен эшне гомерлек итеп, җиренә җиткереп эшләргә өйрәнеп үсә Руслан. Сүз белән түгел, эш белән алдыра малай.

Бабасының һәр өйрәткәне тормыш сабагы алырлык була. Бервакыт Руслан утын өеп маташа. Әрдәнә аумасын өчен, артына утын кыстырып, тигезләп өяргә куша оныгына Салих бабасы. Җәй көне озаклап утын өеп ятасы киләме соң малайның? Җитмәсә, әнә дуслары су коенырга төшеп баралар, Русланны да чакыралар. Руслан тиз генә эшен тәмамлый да су буена чыгып чаба. Кайтса, утын әрдәнәсе авып ята. Салих бабай, үзе кушканча эшләмәгәне өчен, әрдәнәне үзе чыгып аударган! Русланга әрдәнәне инде яңадан, бабасы кушканча өяргә туры килә. Эшлисең икән, гомерлек булсын! Русланның тормышында иң төп сабак шул булгандыр, мөгаен.

Фото: Анна Арахамия

Эш – иң үтемле тәрбия. Баланы эшкә өйрәткәндә телен дә баетасың, мең соравына җавап эзлисең. Эш белеп үскән баланың теле дә – туган теле; ашаган ашлары, эчкән сулары да хезмәтенең җимеше.

Малай 10 нчы сыйныфта укыган чакта Салих бабай да дөнья белән хушлаша. Тормыш тулысынча Русланга кала...

– Шул чакта күршесендә яшәүче туганнары Мәрхәбә апа, Әнвәрә апалар бик ярдәм иттеләр инде, – дип искә ала Гөлшатның әнисе Фәния апа. – Алар һәрвакыт күз-колак булып, булышып тордылар ул балага, тәрбиясен дә, игътибарын да бирделәр. Шулкадәр кызгана идек без аны...

Кызгану – бер хәл, беркеме булмаган, авырлыкта үскән ятим егетнең үз кызың белән очрашып йөрүен кем хуплар иде микән... Мәгъсүм абый белән Фәния апа исә Русланда шикләнмиләр. Яшьтән фермада эшләп йөргән малайны ферма мөдире Мәгъсүм абый, эшен күреп, күптән бәяләп куйган. «Шулкадәр тырыш егет, бик яхшы эшли», дигән сүздән ары иреннән башканы ишетми Фәния апа.

Бөтен тормыш авырлыгын ялгыз иңендә күтәрсә дә, үгезләр асрап, аларны сатып, киләчәктә йорт төзерлек материалларын да Руслан үзе әзерли...

Сезгә тотынырга кирәк!

– Авылда яшәр өчен арысландай батыр йөрәкле, аттай тырыш булырга кирәк, – ди Гөлшат. Аттай тырыш Руслан янында батыр йөрәкле арыслан – Гөлшат үзе инде. Кечкенәдән Маһриҗамал әбисе белән үсә кыз. Фәния апа: «Кияүгә киткәнче үз өебездә бер генә төн кунгандыр, гел әбисе белән яшәде», – ди, уенын-чынын бергә кушып. Өйдәге эшләрен эшли дә, төнгә әбисе янына кереп китә Гөлшат. Маһриҗамал апа картаеп, күз-колак булып тору мәсьәләсе килеп чыккач, Фәния апа әнисен үзләренә күченергә үгетли. Маһриҗамал апа: «Керсәм, Гөлшатларга керәм», – дип, үз йортыннан шул шарт белән генә китәргә риза була. Яраткан оныгы күршедә генә яши, бәхетенә.

– Әни Гөлшатларда яши башлагач, Русланның никадәр мәрхәмәтле булуын тагын бер тапкыр күрдем. Әби-бабасын тәрбияләп яшәгән малай өлкән кешене ничек карарга кирәклеген миннән дә яхшырак белә булып чыкты. Әбигә чәйне тирән чокырга ясап бир, йомырканың кабыгын әрчеп, урталай ярып алдына куй, дип, Гөлшатны бик күп әйбергә өйрәтте әле киявебез. Бу кадәр нечкәлекләр минем башыма да килмәде! – дип, кияven мактый Фәния апа.

Ул вакытта яшь гаиләнең үз балалары була инде. Маһриҗамал әбиләре белән тәгәрәшеп үсәләр. Казанның мәдәният һәм сәнгать институтында белем ала Гөлшат. Авылда китапханәгә эшкә урнаша. Руслан күрше авылга барып эшләп йөри. Ә аннары... Тирә-якта дан тоткан Олы Мәтәскә авылындагы Фрунзе исемендәге колхоз тарала. Әмма бу бер чоргы яшьләр өчен авылны ташлап чыгып китәрлек сәбәп булмый. Ул елларда авылда төпләнеп калган унике яшь гаиләнең колхоз җирләрен, фермаларны үзләре алып, авылны таркатмыйча саклап калуларын Теләче районы хакимияте әле дә батырлыкка тиңләп, хөрмәт белән искә ала.

Унике гаиләнең алтысы җиң сызганып шәхси ферма хуҗалыгы эшенә тотына. Бу эшләргә керешүнең сәбәпләре төрле булгандыр, үзләре батырлык дип тә, изге максат итеп тә күрмәгәннәрдер, бәлки. Башта эшләргә кирәк бит әле аны! Теләк, тәвәккәллек кирәк...

– Дөресен генә әйткәндә, үзебез ферма эшенә алынырга курыктык та әле. Ләкин минем әти-әни, сезгә тотынырга кирәк, дип беренче адымнарны ясарга булыштылар. Алар инде меңләгән баш үрдәк үстереп, Казанның иң зур базарларында үзләре җитештергән продукцияне сатып, саллы тәҗрибә туплап өлгергән иде ул вакытта. Эре терлек, сөтчелек даирәсе болардан шактый аерылып торса да, Руслан белән киңәшләшкәннән соң әни белән җитәкләшеп диярлек грант алу артыннан йөри башладык. Әнидә – тәҗрибә, миндә – арыслан йөрәге һәм ышанычлы ирем.

Гел яхшы кешеләр

2014 елда Садыйковлар башлап эшләүче фермерларга бирелә торган грант ота һәм ферма төзү эшенә тотына. Ферманы элеккеге колхозның җәйләү урынында сала башлыйлар. Кызу табада биер чаклары алда була әле. Бөтен туганнары, Гөлшатның әтисе, энесе белән бергә ферманы үзләре күтәрә. Ирләр белән берләттән Гөлшат үзе дә шунда, төзелештә кунмый гына инде. Түбә япкан хатын-











кызны Фәния апа үз гомерендә беренче тапкыр әнә шулчак күрә. Аста икәү калайны бауга бәйләп бирәләр дә, баскыч буйлап Гөлшат өскә сөйрәп менеп китә. 25 баш сыерга дип планлаштырган ферманы 100 башлык итеп салып чыгалар.

– Юлыбызда гел яхшы кешеләр генә очрады. Үз фермабызда сигез ел эшлибез инде менә. 80 баш эре терлекнең 50 се – савым сыеры. Дәүләтнең ярдәме бик зур. Яңгырлы көннәр җитсә, әле дә башлаган чорлар искә төшә: керә торган да, чыга торган да түгел иде монда юллар. Махсус программа буенча юл да салып бирделәр, ут та керттеләр! Безгә генә түгел, авылдагы бөтен фермерларга дәүләт исәбеннән шулай эшләп бирделәр. Район җитәкчелеге дә бик әйбәт, Татарстанның авыл хуҗалыгы министрлыгында да шулкадәр яхшы кешеләр эшли дип сөенәбез. Дәүләт программасы буенча электр энергиясе дә бушка. 2018 елда тагын бер грант отып алган техника, пресс, тырма, тегермән генә дә нинди зур ярдәм. Кормораздатчик үзе генә ни тора! Грант – бүләк бит инде ул. Аны кире кайтарасы юк. Таләпләргә килгәндә, алар бөтен җирдә дә, һәр эштә дә бар. Ләкин ул кадәр акчаны – ун миллионны баласына әти-әни дә бүләк итә алмый бит. Сөткә субсидия бирәләр, ул да кулга кергән кисәкле акча, шөкер, – дип тезеп китте Гөлшат.

Әнә шулай килешеп эшләгәнгәдер, кунаклар да өзелми бу гаилә биләмәләреннән. Дагстан, Карелия кунакларын экскурсиягә алып килгәннәр, Бөтендөнья татар конгрессы кунакларын да берничә тапкыр кабул итеп, гаилә эше белән таныштырганнар. 2015 елда Садыйковларның фермасына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзе килә! Шулкадәр дәрәҗәле кунакның авылча гадилеген әле дә искә алып сөйлиләр гаиләдә.

– Ферма буйлап йөргән арада бер читтәге су җылыта торган мичкә күзе төште Рөстәм Нургалиевичның. Кара, нинди мич бу, дип, шуны бик җентекләп карады. Шулкадәр гади булуы, кызыксынучанлыгы белән гаҗәпләндерде. Балалар белән фотога да төште әле!

Бервакыт фермага төшсәк...

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә эш һәрвакыт алай җиңел генә бармый. «Бар инде аның авырлыклары», – дип кенә җавап бирсәләр дә, көтелмәгән хәлләр дә булгалый.

– Бик салкын төннәрдә су катып калган чаклар була. Йә аппаратлар ката. Иртәнге савымга төшеп киткән җирдән көндезге унбергә генә кайтып җитәбез кайчак. Шлангларны төзелеш фены белән җебетеп, чак савып бетерәбез 50 сыерны. Берсендә бозау югалттык бит әле без! Җәен сыерларны кардага чыгарабыз. Әй рәхәт чаклар инде ул! Иртән чыгып киткән тана-сыерлар кичен абзарга бозау ияртеп кайтып керәләр. Бер көнне тана бозаулады, диделәр. Ә бозавы юк! Эзләмәгән җир калмады. Бозау кадәр бозауны югалт әле син! Бер кеше дә алып чыгып китә алмый югыйсә. Ерак та китә алмас иде яңа туган бозау. Тау башларын, чыршы араларына кадәр әйләнеп эзләп кайттык – бозау юк. Инде аптырап басып торганда Гөлшатның аяк астында диярлек, таш өеме янындагы кычыткан арасында яткан бозауны күреп алдык.

Бу – көлеп искә ала торган бер вакыйгалары. Әнә шул 2015 елда, Президент та катнашасы семинар алдыннан зур сынау да узарга туры килә әле гаиләгә... Уку елы башланыр алдыннан балаларны куандырыйк дип, шашлык пешерергә уйлыйлар. Уртанчы балалары – 3 яшьлек Тәбрис тә шунда чуала. Учак яндыручы сыекчага ут кабып шартлап, Тәбриснең өстендәге футболкасына ут каба, баланың гәүдәсенә ябыша. Район хастаханәсеннән Тәбрисне Казанга реанимациягә озаталар. Бер атна шунда ята малай. Тирене күчереп утыртырга туры килә хәтта. Аннары ай буе Республика балалар клиник хастаханәсендә дәвалана.

– Шундый хәл белән очрашкач, дөньяның бөтен мәшәкате артка күчә икән. Берни кирәкми, балалар гына сау-сәламәт булсын дип, тормышка башка төрле карый башлыйсың. Хастаханәдә шулкадәр мәрхәмәтле табиблар дәвалады. Яраларны сүтеп бәйләр өчен, эшкәртер алдыннан сабын белән юарга кирәк иде. Ә Тәбрис тидертми тәнենә, үзе акрынлап юа. Бер тапкыр да ашыктырмыйча, шул 3 яшьлек баланың үзе юынганын көтеп тора иде табиб. Семинарда катнашыр өчен миңа хастаханәдән чыгарга туры килде, улыбыз янына апам Гөлназ кереп торды. Аллаһка шөкер, Тәбрис исән-имин савыгып чыкты, – дип, Гөлшат иң авыр көннәрен искә төшерә.

Бүген Тәбрис спорт сөюче бала булып үсә. Татарстанның атказанган тренеры, физик культура отличнигы, халыкара класслы спорт остасы тәрбияләү тәҗрибәсе булган Винер Әскәров кулы астында көрәш келәмендә чыныга Тәбрис. Аның төрле мәйданнарда бил алышасы бар әле! 4 нче сыйныфта гына укыса да, мәктәпнең баскетбол җыелма командасы белән Теләче районы беренчелеге призеры инде ул!

Гәрчә анда тумасам да...

Кайбер авылларга баргач, мин монда яшәр идем дип уйлап куясың. Әйе, туган авылыңны исәпкә алмаганда, күңелгә ятышлы матур авыллар була. Төзек, җитеш, матур! Табигате дә сайлап алынган кебек! Олы Мәтәскә авылы җиләкле алан уртасында урнашкан, диләр. Ә мәчете! Үз авыллары кызы Миләүшә Сәлахетдинова шулкадәр якты, зур мәчет төзеткән. Иdәннәре җылы, балконнары – челтәр бизәкле. Гает намазлары вакытында мәчет эченә халык сыя алмый хәтта, диләр. Юк, мәчет кечкенә булганга түгел, иманлы, дини гыйлемле халык яши авылда. Читкә киткәннәр дә изге бәйрәмгә туган авылларына кайтып, Аллаһ йортына ашыга. Ураза аеның башыннан алып ахырына кадәр мәчеттә авылдашлар ифтар ашлары уздыра, бер буш көн дә булганы юк!

– Безнең авылда халык тырыш, хәтта артыгы белән әле, – ди Олы Мәтәскә башкарма комитеты секретаре Энҗе Исхакова. – Колхоз беткәч тә читкә чыгып китмәделәр. Ит, сөт, эремчек, кош-корт белән эш итеп тормыш алып бардылар. Буш йортлар да юк авылда. Фельдшер-акушерлык пункты, мәктәп, балалар бакчасы бик яхшы. Мәктәптә уку программасы буенча гына түгел, тәрбия юнәлешендә дә бик зур эшләр алып барыла. Әле күптән түгел Шәүкәт Биктимеров исемендәге республика театр конкурсында беренче урын яуладылар! Берничә буын укытучы гаиләләре, ирле-хатынлы укытучылар эшли. Мәктәп директоры Марат Сөнгатуллин да хатыны Алия белән бик хөрмәтле укытучылар гаиләсе. Сигез ир-ат укыткан авыл мәктәпләре республикада бармак белән генә санарлыктыр. Без шуның белән дә мактана алабыз әле. Мәктәпнең үз бакчасы бар, 60 төп алмагач үстерәләр! Мәдәният йортында Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлнур Гыймранова эшли, махсус хореограф чакыртып биюләр әзерлиләр, бәйрәмнәр үткәрәләр.

Авыл җирлегендә нинди генә зур эш башкармасыннар, нинди генә чара уздырмасыннар – Садыйковлар беркайчан да читтә калмый. Фермерлар гаиләләре бергәләшеп мәктәпкә шахмат кабинеты да ясап биргәннәр.

Сер капчыгы

– Авылда матур яшәүнең сере – һәр гаиләнең үзенеке. Безнең төп этәргечебезнең берсе – кечкенәдән алып үскән хезмәт тәрбиясеdер. Көн саен иртәдән өстәлдә эшләр исемлеге язылган дәфтәр ята иде безнең. Әни шулай язып калдыра. Эштән курыкмыйбыз. Әле шушы ферма өстенә апрельдә үк йөз баш чеби алып куям инде мин, – ди Гөлшат.

– Бер тотынгач, артка чигенү юк, алга гына омтыласың. Маллар белән эш иткәндә ял да, бәйрәм дә юк. Көн саен иртәдән кичкә кадәр, яздан – көзгә, көздән – язга... Яңа елның озын ялларыннан соң эшкә чыгарга авырсынып утырган кешеләр бар, хәтта психологларга мөрәҗәгать итәләр. Андыйларны аңламыйбыз да... Эшкә тотынырга авыр булмасын өчен, безнең кебек туктап тормаска кирәк, – дип елмая Руслан.

Эшнең әҗерен күреп торсаң, авырлыгы да онытыладыр. Әле күптән түгел Авыл хуҗалыгы министрлыгы уздырган республика бәйгесендә «Татарстан Республикасы фермер хуҗалыгының иң яхшы җитәкчесе» номинациясендә җиңү яулап, акчалата бүләккә ия булганнар. Каршыларында гына яшәүче әти-әниләре дә – тормышның бер бүләге Садыйковлар өчен. Гаиләнең уңышларында аларның да өлеше бик зур. Мәгъсүм абый әле дә – фермада төп ярдәмчеләренең берсе, таянычлары. Йорттагы, каралты-курадагы эшләрне эшләүче балалары өчен сөенми дисезме әллә әти-әни? Кызлары Зилә инде күптән әнисенең кул арасына кергән. Әле кайчан гына Гөлшат үзе сәхнәдә җырлап йөргән булса, хәзер кызлары сәхнәдә биеп ут чыгара.

Эш – иң үтемле тәрбия. Баланы эшкә өйрәткәндә телен дә баетасың, мең соравына җавап эзлисең. Эш белеп үскән баланың теле дә – туган теле; ашаган ашлары, эчкән сулары да хезмәтенең җимеше. Уллары Тәбрис белән Рәнис өчен фермага төшеп бозауларга сөт эчерү вазыйфасы да йөкләнә инде хәзер. Тракторга утырып басуга чыгуларны көтеп алалар әнә! Әтиләре белән кибеткә кереп, тәмле әйберләр алалар, термоска җиләкле, гөлҗимешле үлән чәе ясыйлар. Эшләп арыгач, әти белән басу уртасында ашап, кайнар чәй эчеп алу бәхете малайларның иң матур балачак мизгеле булып калачак әле... Әлегә алар яшь колыннар кебек уйнаклашып, өй уртасында үзара көрәшеп тә алалар. Һичшиксез, арыслан батырлыгы бар үзләрендә!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. Фото һәм видео: Анна Арахамия.

ГӨЛЗӘЛИНӘНЕҢ МИЛЛИ МОЗАИКАСЫ





Эльмира ЗАКИРОВА

Ерак эстон җирендә армый-талмый милләтебезгә хезмәт итүче фидакарьләр яши. Шундыйларның берсе – Европа татарлары альянсы киңәшчесе, Ида-Вирумаа татар мәдәнияте җәмгыятенең идарә әгъзасы Гөлзәлинә ЖЕХТУНОВА. Аның турында Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында да җылы сүзләр әйттеләр, бу тырыш ханым хакында матбугат аша да укып белә идек. Тиз арада сорауларга күмәсем, аның җавапларын ишетәсем килә башлады. Миңа барысы да кызык. Эстониядә татарлар күпме? Алар анда каян барып чыккан? Үзара татарча аралашалармы? Ниләр эшләп яталар? Гөлзәлинә Заһит кызы Эстониядә ничек татар дөньясы вәкиле булып киткән? Үзе кайсы яклардан? Сирәк очрый торган матур исемен кем куйган? Эстония татарларының Татарстан белән элемтәләре ничек? Ватсаптан да, электрон почта аша да языштык. Гөлзәлинәнең ягымлы тавышы җай гына аудиоязмаларда агылды. Бераз тынып калып, күз яшьләрен йотканын да тоеп тордым, сагынуларын алыштырып, горурланып сөйләгәннәрен дә рәхәтләнеп тыңладым.



Фото: Гөлзәлинә Жехтунова архивыннан

Миндә менә шул татар рухы сакланган, ул үзен сиздереп тора.

ЭСТОНИЯДӘ ЯШИ БАШЛАГАНЫМА 50 ЕЛ БУЛДЫ ИНДЕ! Күмертау тау-механика техникумын тәмамлап, бирегә юллама белән килдем. Бик кирәкле белгеч идем: шахтада эшләдем. Бөтен җирдә актив булдым, миндә дөньяны үз кучәремдә әйләндерердәй көчләр бардыр кебек тоела иде. Менә шундый тиктормас кыз идем инде! Шундук күреп алдылар! Төрле җәмәгать эшләренә тарта башладылар. Бар нәрсә кызык, барысын колачларга тырышам... Ярты гасыр яшәү дәверендә бик кызыклы гомер кичердем: югары уку йортын тәмамладым, җитәкче урыннарда эшләдем, 1500 кешене берләштергән «Ноорус» тегү берләшмәсендә партия оешмасы секретаре булдым. 1991 елдан мин – бизнеста. Үземнең тукымалар кибетем, костюмнар тегү буенча зур фабрикам бар. Скандинавия илләре белән эшлибез. Үз брендыбыз бар. Бизнесны җайга салу бик четерекле, мәшәкатьле эш, әлбәттә. Ләкин теләк булганда барлык кыенлыкларны җиңәргә, максатыңа ирешергә мөмкин. Бизнесменның эше хәвефле дә, чөнки популяр булмаган адымнарга да барырга туры килә. Бигрәк тә кешеләр белән эшләгәндә. Бүгенге көндә минем предприятие тотрыклы санала, җитештергән продукциябез белән дә конкурентлылыкка сәләтле без! Холкым шундый инде: тик тора алмыйм, барысын да белергә, халык белән аралашырга кирәк миңа.

МИН – ШАРАЙ КЫЗЫ ДИЯРГӘ ЯРАТАМ. Әткәй – Башкортстанның Илеш районы Иштирәк авылыннан, әнкәй – Баулы районы Шарай авылы кызы. Әткәй Татарстанга килеп, нефтьчеләр янына эшкә урнашкан. Әнкәй белән сугыштан соң очрашып өйләнешкәннәр. Үзем Шарайдан ерак булмаган Татар Тумбарлысында тусам да, бәләкәй чакта гел Шарайга бара идем. Анда әбием бар иде – әнкәйнең әнисенең сеңлесе ул, үз әбием бик иртә үлгән. Әнә шул әби дип йөртә торган апа мине ат арбасына утыртып, Шарайга алып кайта иде. Авыл балалары белән сәкедә уйный идек... Берара Баулыда да яшәп алдык. Аннары әтине эше буенча Башкортстанга күчерделәр. Приютовода урта мәктәп тәмамладым. Аннары Күмертауга укырга киттем. 1972 елның мартыннан – Эстониядә. Ел саен кайтып китәргә талпындым, тик барыбер китә алмадым. Кияүгә чыктым, ике балабыз туды, оныклар Тимур белән Нуа үсеп җитте – шулай калынды инде. Советлар Союзы таркалгач, чит илдә яшәп калдык шулай. Әткәй-әнкәй инде күптән вафат. Менә шул Шарайга кайтасым килеп, гел алгысый идем. 2017 елда тәки кайттым бит! Юкса шунда үскән чорым гел исемә төшеп, йөрәгем телгәләнә иде. Шарайга кайткач күрәм – әйтерсең бернәрсә дә үзгәрмәгән! Чиста, матур кечкенә өйләр, бер урамлы авыл. Әбием яшәгән йорт юк иде инде. Ләкин мин барыбер ул урынны таптым! Сарай артында киндер үсә иде. Мине шул киндерне уып, орлыкларын ашарга өйрәттеләр. Аның тәмлелеге, аның хуш исе! Алты дистәдән артык гомер узса да, шул урынны таптым тәки. Ерактан зур каен урманы күренеп тора. Әнкәй белән шунда җиләккә йөри идек... Менә шул күренешләр гел уемда булып, төшемә кереп, һәрчак җанымда яшәде. Күр инде, бар да элеккечә дип сөендем. Хәтта чәчү җирләре дә шул ук! Әнә, сап-сары булып көнбагыш басуы җәйрәп ята. Ул төшемә дә шулай кояшлы булып керә иде. Кайткач, туган-тумача белән дә күрештем. Алар мине бала чагымнан ук хәтерли икән. Кызык чакларымны сөйләп көлдерделәр. Болар бар да бик кадерле мизгелләр.

ИСЕМЕМ МАТУР: ГӨЛЗӘЛИНӘ! Мин туганда, әнкәйнең туганнан туган апасы Халидә Үзбәкстаннан кайткан булган. Гөлзәлинә исемен куегыз, дип, ул әйткән. Мондый исемне беркайда да очратканым юк. Сирәк һәм матур исем. Мин аны беркайчан да үзгәртмәдем. «Гуля», «Зина», «Лина» дип, бозарга тырышып карадылар, «Юк, мин Гөлзәлинә!» – дия идем. Кайда гына эшләсәм дә, җитәкче урыннарда утырсам да, отчествоны да үзгәрттертмәдем. Соңыннан миңа кызык итеп сөйлиләр иде: әтинең исемен ятлап ишеккә кадәр киләләр икән дә, тагын онытып, кире борылалар, яңадан кабатлап, «Гөлзәлинә Заһитовна» дип килеп керәләр. Кайберләре «Зәлинә» ди, «Гөлзәлинә ханым» дип дәшүчеләр дә бар. Йөрәгем гел әйтеп торды: Син исемеңне беркайчан да үзгәртмәскә тиеш, диде. Минем өчен бу бик мөһим иде. Халидә апам куйган исем бит ул!

ТАТАР ДӨНЬЯСЫНА КИЛЕП КЕРҮЕМ – КЫЗЫКСЫНУЛАРЫМНАН. Эстониядә 2500 ләп милләттәшебез яши. Ә татарларның төпләнү тарихы моннан 450 еллар элек дип исәпләнә. Казан ханлыгы таркалганнан соң, кайбер морзалар бирегә качып килгән һәм төпләнеп калган. Кайберләренең исемнәре белән бәйле истәлекләр әле дә саклана. Мәсәлән, морза Баранов яшәгән йорт. Төньяк сугышыннан соң татарлар җир участоклары ала башлый. Таллинның алар төпләнеп утырган өлеше татар кварталы дип атала. Элегрәк, XVIII гасырда, бу тирәләрдә татар гарнизоны казармалары була. Ә бистәнең үзәк урамы Татари исеме белән йөртелә. Ул урам бүген дә бар. Эстония тарихында эз калдырган шведлар да, даниялеләр дә, немецлар да Таллинда үз исемнәрен йөрткән урам булу белән мактана алмый, ә татар урамы бар менә! Алар әле икәү – Татари һәм Уус-Татари.

ҖИРЛЕ ХАЛЫК БЕЗГӘ ХӨРМӘТ БЕЛӘН КАРЫЙ. Эстоннар татарларның кем икәнен яхшы белә. Горурланырлыгыбыз да бар: безнең халык үзе турында тырыш, хезмәт сөючән, нык тамырлы, бай мираслы, тирән белемле милләт дигән данын тараткан. Биредә биш татар иҗтимагый оешмасы эшләп килә: икесе Таллинда, калганнары Маарду, Нарва, Кохтла-Ярве шәһәрләрендә. Татарча сөйләшә торган милләттәшләребез күп. Дусларча аралашып яшибез. Сабантуйларда бергә җыелабыз.

НИЖГАР МИШӘРЛӘРЕ ДӘ БАР БЕЗДӘ. Бөек Ватан сугышыннан соң 1948 елда Түбән Новгородтан – Сергач районының Андреевка авылыннан – Маарду шәһәренә химия заводы төзелешенә йөзләгән татар күчеп килгән: үзләре бер авыл булып яшиләр. Бүгенге эстон

Гаиләдә татарча гына сөйләшәләр, балалары туган телебезне сеңдереп үсә.

шәһәрләрен төзекләндерүдә, икътисадны алга җибәрүдә безнең дә өлешебез бар! Нижгардан күченеп килгәч тә, телне, динне, гореф-гадәтләрне сакларга тырышалар. Хәер, бу илдә берничә буын татарлар яши. Икенче дулкын татарлар килү 1980 елгы Олимпиада белән бәйле. Таллинда «Иру» ТЭЦын төзүдә катнашалар. Тимур Салипов дигән дустыбыз – ул бабай инде – оныгын гел татарча сөйләштерә. Тимур белән күрешкәч, һәр сүзнең төмен тоеп, рәхәтләнеп үзебезчә сөйләшәбез, бездә татар җаны уяна. Еракта тел онытыла дигән сүзләр дөрес түгел ул. Сүз дә юк, тирәлекнең басымчаклыгы көчле, балаларыбыз барысы да белми телне. Ләкин бу хәлне җайлап кына төзәтәбез. Ул яктан иҗтимагый оешма төрле чаралар үткәрә.

ИҢ ЗУР ПРОЕКТЫБЫЗ – САБАНТУЙ БӘЙРӘМЕ! Ул Татарстан белән бергә үткәрелде. Аны Европа татарлары альянсы уйлап тапты, ә Казан, Татарстан Президенты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты хуплап алды һәм һәрьяклап булышты. Кайлардан гына килмәделәр безгә! Иң мөһиме – татарлар бергә җыелды. Тәнкыйтьләргә маташучылар да табылды. Европада нинди Сабан туе инде, янәсе! Ул бәйрәм дәүләт тарафыннан субсидияләнде. Сабантуй – ул татар халкының казанышы. Башка халыкларга да аңлаешлы итеп үзебезне, мәдәниятебезне, телебезне, гореф-гадәтләребезне күрсәтүнең бер формасы ул. Кызыклы идеяләребездән чыгып, проектлар төзибез. Ида-Вирумаадагы бию коллективы, мәсәлән, татар биюләрен куя. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты безгә махсус хореографлар җибәрде, алар мастер-класслар уздырды. Безнең биюләр дәүләт югарылыгындагы чараларны да бизи хәзер. Чит илләрдә чыгышлар ясап та, милләттәшләребез татар мәдәниятен дөньяга танытып кайта. Нарвада Сабантуй күргәзмәсе оештырдык. Интеграцион фонд җитәкчеләре, шәһәр хакимияте вәкилләре бу күргәзмәнең әһәмиятен ассызыклап билгеләп үттеләр. Татар дигән халык, Сабантуй дигән милли бәйрәм барын белеп киттеләр.

3 МЕҢ УРЫНЫНА 10 МЕҢНӘН АРТЫК ХАЛЫК ҖЫЕЛДЫ! Әйе, әйе, Сабантуй турында әйтүем. Таллинда 10 мең кешелек хор коллективлары Җыр кырында чыгыш ясый. Үзе бер тамаша! Сабантуй да әнә шундый олы бәйрәм биредә! Таллинның Башенная дип йөртелгән үзәк мәйданындагы борынгы йортлар фонында татар гармуннары уйнады, кызлар өздереп биеде, җанга якын җырларыбыз яңгырады – биш сәгатькә сузылган чын татар бәйрәме булды ул. Татарстан Республикасы җитәкчесе Рөстәм Миңнехановка зур рәхмәт әйтәсе килә. Ул – бөтенесен тирәнтен аңлый торган зирәк җитәкче. Безне хуплап алды. «Киләчәктә дә мәдәниятебезне әнә шулай күрсәтүне дәвам итәргә, татарларны бөтен дөньяга танытырга кирәк», – дигән фикере безне үсендереп җибәрде. 40 проект арасында «Европа Сабан туе» беренче премиягә лаек булды. Һәм ул, беләсезме, ничек аталды – «Кешеләрне берләштерүче ел чарасы». Юк, чара дип әйтергә тел әйләнми. Нәкъ менә шушы бәйрәм татарларны башка халыклар белән берләштерде. Бик югары бәя бу!

БЕР АКЦЕНТСЫЗ, НӘКЪ БЕЗНЕҢЧӘ ӘЙТЕП, ПӘРӘМӘЧ СОРЫЙЛАР!.. Чынлап! Ә бер фирма өчпочмаклар пешерү серләрен үзләштерде. Хәтта эстоннар да безнең өчпочмак, чәкчәк, пәрәмәчләрне инде белеп бетергән. Тәмле, туклыклы, дип, яратып алалар. Татар ашларын әзерләү буенча мастер-класслар оештырабыз.

«МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР МОЗАИКАСЫ» ФЕСТИВАЛЕ ТАРИХНЫ, МӘДӘНИЯТНЕ, ӘДӘБИЯТНЫ, ДИННЕ, МИЛЛИ РИЗЫКЛАРНЫ КОЛАЧЛЫЙ. Фестивальдә катнашып, татар тарихы, мәдәнияте белән таныштырдык. Башка халыклар таң калып тыңлады. Милләттәшләребез булдыра! Татар җәмгыяте җитәкчеләре Илзия Әхмәт, Мәрьям Малышева, Мядут Прокуроров, аталы-уллы җырчы Шәрәфетдиновлар белән ничек горурланмыйсың!.. Татарча сөйли торган «Дуслык» радиосы, милләттәшебез Фәүзия Һадиуллина әзерләгән тапшырулар һәр татар кешесе өчен бик тансык. Тагын бер сөенечебез: теләсә кайсы татар кешесе килеп намаз укый торган бүлмәбез бар. Татар җәмгыяте җитәкчесе Ренат Гарифуллин муллабыз да әле. Ураза гаете, Корбан бәйрәмнәре бик матур уза. Эстония мөфтие Илдар хәзрәт Мөхәммәтшин һәм аның хатыны, Таллинда татар якшәмбе мәктәбенә нигез салган Иман Лия ханым Мәхмүтова Татари урамында беренче хәләл татар чәйханәсе ачтылар. Аның диварлары милли орнаментлар белән бизәлгән, түбәтәй, шәмаил, кечкенә мендәрләр авыл өен хәтерләтә. Кем татарча күбрәк сүзләр белә, шуңа бушлай пәрәмәч бирәләр. Татарлар XX гасыр башында аеруча күп булган. Атаклы Виру мәйданындагы пожар депосы залын мәчеткә әйләндереп, җыелып намаз укый торган булганнар хәтта, дип сөйлиләр!

БЕЗНЕҢ БАЙ МИРАСЫБЫЗ БАР! Узган көз Ида-Вирумаада «Милләтара диалог һәм үзара аңлашуны үстерү»гә багышланган IX Халыкара конференция узган иде. Анда безнең татар мәдәни җәмгыяте вәкилләре дә катнашты. Милли җәмгыятьләр тәкъдим иткән китап күргәзмәләре белән таныштык. Мин Эстония Милли китапханәсенә инглиз телендә нәшер ителгән «Татар тарихы»ның җиде томлыгын бүләк иттем. Үзебезне әнә шулай күрсәтергә тырышабыз, татар дигән бөек халыкның кызлары, уллары булуыбыз белән горурланабыз. Татар телендә аралашу, берләшү, татар гаиләләре төзү – безнең төп максатыбыз. Безнең халык матур, аның эчке дөньясы бай, горурланырлык әйберләр җитәрлек бездә.

Нәүрүз бәйрәме, «Тукайга чәчәкләр» Таллин фестивале, җыр-бию бәйгеләре... Эстониядәге татар яшьләре Чәкчәк бәйрәме үткәрүне традициягә әйләндерде. Алар шулай ук татар киносы көннәрен дә уйлап тапты. Ачык һавада зур экраннан татарча кино карау элек башка да килмәс иде! Мостай Кәримнең «Кыз урлау» спектаклендә дә гел яшьләр уйнады. Болар һәркайсы рәхәт бер мохит тудыра, әлбәттә: туган җиргә, балачакка кайткандай булабыз.

МӘҢГЕЛЕК ДВИГАТЕЛЬ



Марат КӘБИРОВ,
язучы

Ниһаять, миндә дә сенсацион яңалык бар: Россиядә мәңгелек двигатель барлыгы ачыкланды. Ул борын заманнардан алып бертуктаусыз эшләп килә, башкаларны да хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә. Кайчан туктаячагы билгеле түгел. Үз илендә шундый могҗиза барлыгын белеп һәркем горурланырга бурычлы!

Ләкин…

Без проблемалар күплегеннән зарланырга яратабыз шул. Акча җитми, сәламәтлек юк, эш күп… Ярый, монысын аңларга да мөмкин әле. Тик без табигать күренешләреннән, һава торышыннан зарланабыз. Көн эссе булса – эссе дип тир түгәбез, болытлы булса, болытлы дип яшь коябыз, салкын булса – салкын дип. Безгә бернәрсә дә ярамый. Шуңа миңа кайчагында болай тоела: без проблемалар яратабыз.

Бәлки, монысы да табигый нәрсәдер инде. Проблема бар икән, димәк, сөйләшергә сүз бар. Ике бабай очрашса, чирләреннән зарланып ала, врачларны сүгә, даруларны тикшерә, кайдан алырга кирәген сораштыра, бәясен белешә... Шул рәвешле чир боларны берләштерә, татулаштыра, дуслар итә. Ә чир – проблема. Проблема булмаса, мондый аралашу каян килер иде?

Ике әби очрашса, усал киленнәрен чәйни. Аларның иртән эшкә киткәндә дөп-дөп атлап йөрүләрен, шалтыратып савыт-саба юуларын, эштән кайткач үбеп алмауларын… Күп нәрсә күренә бит инде әби кешенең очлы күзенә. Барысын да санап бетерерлек түгел. Менә алар өчен килен – проблема. Боларны шул проблема берләштерә.

Ирләр очрашса, эш авырлыгына, акча азлыгына зарлана. Бу өлкәдә дә сөйләр сүзләр күп: ил начар, җитәкчеләр башсыз, оештыру пүчтәк… Санап бетергесез. Боларның барысы да – проблема.

Ниндидер проблеманы хәл итәр өчен хәтта махсус җыелышлар җыялар. Ил агасы булган җитди ирләр шул проблема турында сәгатьләр буе сөйләшеп утыра. Чыгышлар ясыйлар, фикер алышалар, хәтта бәхәсләшеп тә китәләр... Ә проблема булмаса? Болай итеп җыелыша да алмаслар иде. Проблема аларга пар чыгарырга, үзләренең акыллы икәнен күрсәтергә, көчле икәнен билгеләргә мөмкинлек бирә. Ә проблема барыбер шул килеш кала инде ул – беркая да китми. Ә бит нинди зур чараларга сәбәпче була!

Гомумән, аны берничек тә чишеп булмый, чөнки бу тормышта бөтен нәрсә – проблема. Акчаң юк икән – проблема. Күп икән – шулай ук. Хатының юк икән – проблема, бар икән – икеләтә... Гомумән, нинди генә әйберне яки күренешне алма – барысы да проблема. Бар икән – бертөрле, юк икән – икенче төрле.

И-и, без нәрсәнедер хәл итәргә тырышып чәбәләнгән булабыз. Анда чабабыз, монда чабабыз, кызып китәбез, усаллашабыз, терсәкләрне эшкә кушып якындагыларны төрткәлибез, ничек тә булдырырга тырышабыз. Алда торган проблеманы хәл иткәч, тормыш матурланыр, бер баскычка югарырак күтәрелербез, күңелебез тынычланып калыр сыман тоела. Пүчтәк барысы да! Алай килеп чыкмый. Бер проблеманы хәл итү икенчесен барлыкка китерә. Анысын җиңсәң – өченчесе аркылы баса. Һәм шул рәвешле туктаусыз дәвам итә.

Будда мең кат хаклы булган ул. Хәтерлисездер инде: ул инь-янь тигезлеген сакларга куша. Һәйкәле дә бар: әнә шул тигезлекне саклап, аякларын бөкләп утырып, бер проблема белән икенчесенең үзара сугышканын күзәтә. Ике проблема шулай хәлдән тайганчы бер-берсен дөмбәслиләр дә, икесе дә аяктан егыла. Ә Будда үзенең җиңүенә сөенеп сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куя. Инь дә тук, янь да исән. Бу тигезлек безнеңчә күңел тынычлыгы була инде. Күңел тынычлыгы ул бәхет сыманрак нәрсә: кулга тими, күзгә күренми.

Ә проблемалар кешене әнә шул күңел тынычлыгыннан чыгару өчен хезмәт итә. Аннан бер чыктыңмы – бетте. Проблема арты проблема туып кына тора. Мәңгелек двигатель шикелле. Бер карасаң, чынлап та шулай инде. Проблема бит ул кешене хәрәкәтләнергә, нәрсәдер эзләргә, табарга, югалтырга мәҗбүр итә. Яхшылык эшләргә. Хаталанырга. Ә без күп чакта шулкадәр әйбәт итеп хаталанабыз: кабатлаган саен кабатлыйсы килеп тора. Яхшы ялгышларны кабатларга да мөмкин. Шул рәвешле туктаусыз хәрәкәт итәбез дә проблемаларыбыз бетәр дип уйлыйбыз. Бетми! Бетмәсен дә, чөнки ул – кешелекне хәрәкәткә китерүче мәңгелек двигатель.

Әгәр кешенең проблемасы бетә икән, димәк, ул үзе проблемага әйләнгән дигән сүз.


Гөлзадә БӘЙРӘМОВА

Кайсы гына әсәрен алма, аның артында – шагыйрә үзе, аның уй-фикерләре, дөньяга карашы, эчке дөньясы, күңел халәте... «Адәм баласының, бигрәк тә хатын-кызның эчке дөньясы, табигате яши-яши байый, күргән-кичергәннәр аша тулылана», – дип яза ул бер язмасында. Шигырьләре нигезендә дә тормыш тәҗрибәсе, үз ачышлары, үз фәлсәфәсе ярылып ята. Антуан де Сент-Экзюпери: «Мине әсәрләремнән эзләгез», – дигән. Кайта-кайта укып, Гөлзадәнең үзен дә шигырь-хикәяләреннән табабыз. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия лауреаты Гөлзадә Бәйрәмованы күркәм юбилее белән котлыйбыз! Тирән фикерле, хисле, якты әсәрләрен көтеп калабыз.

ЕЛЛАРЫМНЫҢ БАГЫП ТОРАМ КҮЗЛӘРЕНӘ...

Аңламыйм...

«Тәрәзәдән карамыйча гына
Каргый идем һәрбер бәйрәмне».
Л. Шагыйрьҗан

Каргый идем аны көтәр таңны,
Төнне, көнне, айлар, елларны.
Көн яктысы иңгәч тели идем,
«Исән йөрсен!..» – диеп аннары...

Бәйрәмнәре миңа түгел иде
Бу җиһанның, никтер, аңламыйм.
Күпме таңнар ялгыз каршыланган,
Тәрәзәдән күзем алалмый.

Бер сөенечкә – мең борчулы тормыш.
Бер елмаю көтеп көн үткән.
Каргышлы төн каралтканмы җанны –
Ерагайткан, җиде ят иткән.

Ерагайткан – күңел җепселләре
Өзелгәннәр соңгы чиккә җитеп.
Сагышлары калды гомерлеккә,
Бәйрәмнәре үтә читләтеп.

Яңа ел таңы бу

Санамыйк, дисәк тә,
Саныйбыз елларны.
Искегә, яңага
Бүләбез аннары.
Күрмәскә салышып
Чәчтәге чалларны,
Сарыга, карага
Буйыйбыз аларны.
Имештер, мәхәббәт
Яшьлеккә тиңләнә.
Азмы соң адаштык
Бураннар илендә,
Юл эзләп тилмердек
Төнен дә, көнен дә...
Чү, тукта, кем анда
Ут элә шәмемә?
Офыкны күзлимен
Уранып шәлемә.
Таң ата! Яңа таң!
Җиһанда яктылык.
Яңа ел таңы бу –
Сөенеп каршылыйк!

Белгән булсак

Сөйләдең дә хәлләреңне,
Бер җылы сүз көттең миннән.
Ни дип әйтим? Үз хәлем дә
Артык түгел синекеннән.

Синең, дисең, яшәү башка,
Язганнарың – җанга дәва.
Тик белмисең, ул җырларда
Күпме сагыш, әрнү-яра.

Син белмисең, яраларның
Уралганын бәгыремә.
Гаеплене эзләргәме,
Юат, диеп, әйтим кемгә?

Ничек кенә аклансак та,
Гамәлләрдә бардыр хата.
Кемнәр нәрсә сөйләмәсләр
Сөйләгәндә безнең хакта.

Алдавычлы бер ятьмәгә
Корылганын бу дөньяның
Белгән булсак, яшәр идек,
Яшәр идек табып җаен.

Яшәр идек абынмыйча,
Урап узып киртәләрне.
Уянам да уйлап ятам,
Шаклар катып иртәләрен.

Сары яфрак

Сары яфрак сибеләдер юлларыма,
Сагышлары ураладыр уйларыма.
И табигать! Сары төсләр өстәмәче
Кимегәннән-кими барган елларыма.

Шаян сүзләр сөйлим үзе,
форсат чыкса,
Җырлыйм-биим,
күбәләктәй очмасам да.

Ир солтанын тиңли алам Йосыфка да,
Соклanудан барып аны кочмасам да.

«Гөл әби» дип исем тапкан оныгыма,
Гөлләр бит, дим, саргаялар –
сөйлим аңа.
Сабый күңеле ал төсләрдән
балкып тора:
Өзелеп төшкән сары яфрак уен аңа.

Бер-бер артлы тезелешкән
көн-төннәрне
Каршылыйбыз, озатабыз
көз-кышларны.
Сары яфрак! Ничек сездәй
таратыйм соң
Күңелемә иңеп барган сагышларны...

...Сары яфрак сибеләдер алларыма,
Сары төсе сарыладыр жаннарыма.
Сары яфрак! Кунма әле кулларыма,
Киртә булма, килер булган елларыма...

Үземә

Котлыйм әле,
үз-үземне котлыйм
бүләк итеп шигырь бәйләмен.
Дуслар котлар,
һич тә икеләнмим,
тулыланыр гына бәйрәмем.

Шөкер, димен, алга барыла бит
тутыра алдык ничә дистәне!
Сабый чаклар йөгереп узып китте,
Дистәлесе күптән өстәлде.

Шаярыштык, көлдек, и сөендек –
Иң күңелле бәйрәм туган көн!
Кем уйласын яшьлек иленә дә
Олыгаю бер көн киләсен.

Әйттеләр лә: яшьлек гомере кыска,
Ишетмәдек, әллә ишеттек?
Шаянлыкны юлдаш итеп алдык,
Иш булырлык ярны иш иттек.

Кемдер туып, кемдер үлеп торды,
Шатлык-кайгы булды аралаш.
Яшәешнең кануннары белән
Килешәсең чараң булмагач.

Иялнәсең икән дошман-дусның
Битлек кигән йөзенә дә.
«Моңаймачы, күңелкәем!» дия-дия,
Елларымның багып торам күзләренә..

Үзгәрмәстер...

Мин булмаудан жирдә
берни үзгәрмәстер.
Ятим калыр бары «мин»ле дөньям.
Оныгымда булыр бераз ямансулык –
«Гөл әби, дип, ник өйдә юк,
китте кая?»

Аңлатырга тырышырлар, бу дөньяда
Мәңгелеккә түгел, диеп, бернәрсә дә.
Кабул итмәс сабый күңеле,
аңлый алмас,
Ничек кенә үзе аны теләсә дә.

«Мин»ле дөньям бик киң кебек,
кайчак бик тар.
Хәл-әхвәлне белүчеләр барын бар да.
Әллә нигә күңел төшә кисәк кенә,
Дус-туганны аерым-аерым барлаганда.

Кем беләндер шактый гына
гомер үткән.
Кайберләре болай гына
күренеп киткән.
Рәхмәтлемен, риза-бәхил һәммәсенә
Тормышымны жырлы-моңлы,
гамьле иткән.

* * *

Унсигез дә түгел, егерме дә,
Илле, алтмыш булса ни була?
Һәрбер яшьнең үзенең матурлыгы,
Һәрбер яшькә күңел куана.

Кемдер әйтер, гомер уза бит, дип.
Гомер узар өчен – узсын ла!
Матурлыгын жирнең тоеп яшим,
Яшәмәдем вакыт узсынга.

Картаюдан куркып яшәмәдем,
Еллар белән бардым янәшә.
Сабый чагым хәтерләтеп, оныгым
Күгәрченнәр белән гөрләшә.

...Һәрбер яшьнең үзенең матурлыгы,
Зирәклекләр – еллар өлеше.
Туар таңнар офыгына багып,
Сабый күңеле аша сөйләшәм.

* * *

Әҗәлләрдән дәва юктыр, диләр,
Таба алсаң, дәва табыла:
Жырың көчсә халык бәгыренә,
Моңың көчсә халкың аңына.

Жырланмаган жырлар юктыр, диләр,
Жыр туа ул хәтер таңында.
Чорны чорга тоташтыра алыр
Мең хәсрәтле халкың барында.

Кем баласы? Кайсы милләт, диләр,
Дан-шөһрәткә барыр юлында.
Ил кызлары илгә игелек кылып,
Ир-егетләр Илбаш булганда.

Илең бетсә – телең бетә, диләр,
Ул акмаса әгәр каныңда.
Канны канга тоташтырыр булган
Жан әрнүең булсын жаныңда.

Жан әрнүе жанны жылытalsын,
Анам сөте булып илемне. –
И милләтем! Яшәтә алсаң иде
Күркәм итеп Ана телемне!

* * *

Беркемнең беркемдә эше юк.
Хәсрәтнең төсе юк, исе юк.
Жаныңны, аңыңны томалый,
Беркем дә аралап алалмый.

Буталды дөньясы, заманы.
Ак-кара, яхшысы-яманы.
Хыянәт сөюгә әйләнде,
Ялганны дөресләп ялгады.

Ялганы, дөресе буталды,
Илкүләм ящерен төс алды.
Жир-Ана ничекләр түзсен соң?
Жавабы синдәдер, бер Аллам!

Чиллә

Жәйге чиллә. Жиләк исе.
Кыяк үлән, әремнәр.
Кычытканы – ни тамаша!
Табигатьне ямьлиләр.

Һәрберсендә бер матурлык,
Һәрберсендә үзгә ямь.
Тигәнәккә кулым сузам,
Балтырганга баш иям!

Аллы-гөлле, жете төсләр
Күзләр бит, әй, камаша.
Һәрбересе сабый чактан
Күңелемә урнашкан.

Һәрбересе сабый чактан
Озата килә, калышмый.
Бәбкә үләнле ишегалдым –
Төшләремдә саташам.





Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА

Шагыйрә Шәмсия Җиһангированың нечкә хис, яшьлек романтикасы белән сугарылган шигырьләрен яраталар. Ул шигырьләрнең күбесе инде җыр булып яңгырап, сагышлы моңга күмә. Иҗатына хас әнә шул лирика аның повесть-хикәяләренә дә үтеп керә. Китапларының исемнәренә генә игътибар итегез – күңелләргә сагынычлы якты бер дулкын йөгерә: «Яшел гармун», «Төсле моң», «Балачак кая китә?», «Якты сагыш», «Җирсү», «Бакый бул, Баек»... Игътибарыгызга «Бәкер хикәяләре» шәлкеменнән «Авыл малае» хикәясен тәкъдим итәбез.

АВЫЛ МАЛАЕ

(«Бәкер хикәяләре» шәлкеменнән)

Бәкер шифаханәсенә юллама бирделәр Нәфисәгә. Эш урыныннан. Аны, инде унбиш елга якын шул бер урында эшләүче сазаган кызны, кемдер исенә төшерер, «аңа да ял кирәк, аңа бирик...» дип искәртер дип башына да китермәгән иде. Иң кирәк җирдә иң кирәкле сүзне кем кемгә әйткәнен төпченеп тормыйча гына юлга кузгалды ул. Автобусларда, юл уңаенда очраган машиналарга утырып йөрүдән тәмам туеп, машина алып җибәргән иде быел. Курка-курка гына үзе рульгә утырып, беренче мәртәбә ерак юлга кузгалды. Ерак дигәч тә, ул яшәгән шәһәрдән ике йөз ярым чакрымнар тирәсе генә җыела икән. Кешеләр хәзер үз машиналарында Сочи, Абхазияләргә, халыкча әйтсәк, «җылы якка», хәтта чит илләргә чыгып китүне дә бернигә санамый. Нәфисә өчен монысы да батырлык иде.

Курка-курка гына кузгалып китсә дә, зур юлга чыккач, бераз тынычлана төште. Тирә-юньдәге табигатьнең илаһи хозурлыгы күзенә күренә, шул хозурлыктан кәефе күтәрелә барып, башын төрле-төрле уйлар өермәсе чолгап алды хәтта. Фәлсәфи уйлар. Адәм баласы шулай яратылгандыр, күрәмсең, янәшәсендәге матурлыкны тоемлый алмыйдыр, аңа аны читтән эзләргә кирәк. «Ерактагы кояш яктырак», ди шул халык. Хәер, хәзер кеше бөтен нәрсәне, хәтта гомер юлдашын да читтән эзли. Элек бит ата-бабаларыбыз күрше авыллардан да кияү-кәләшне бик карап, җиде буынын тикшереп кенә үз нәсел-нәсәбенә якынайткан, бик җентекләп өйрәнеп кенә кан катнаштырган. Үз авылында, теге урамда гына гомер кичерүче гаиләнең төбе-тамыры, нигә һәвәс, ни-нәрсәгә хирыс, ниндирәк нәсел сырхаулары бар – барысы да уч төбендәге кебек мәгълүм булган. Шуңадыр да, ата-баба киңәшен тотып гаилә коручылар аерылып-чөерелеп йөрмәгән элек, төшкән җирендә таш булган. Нәфисә дә «төшкән җирендә таш» булыр иде дә, әгәр сигезне бетерүгә үк яңа төзелә башлаган шәһәргә бәхет эзләп чыгып китмәсә. Матурлыгы да, акылы да җитәрлек иде югыйсә, бәйләнүче егетләр дә күп булды. Тик нигәдер берсенә дә күңеле ятмады шул. Әллә нинди хур егетләре эзләве дә түгел иде аның. Тәнен теләүдән битәр, җанын теләр кешене генә көтүе иде. Һәм, әгәр очрый калса, аның күкрәк читлегендәге нәни йөрәге сизенеп-сиздереп, һичшиксез дертләп куярга тиеш иде. Ә ул йөрәк тыныч кына типте дә типте. Нәфисәне кырык якасына китереп терәде. Аның сазаган, хәзер инде карт кыз булып калуына «хәсрәтләнүче» дус кызлары интернеттан, ял йортлары, курорт-санаторийлардан кияүне бик җиңел генә табучылар бар дип, аңа да шулай эзләп карарга киңәш иттеләр. Бәкергә барасы икәнлеген белгәч, «Кияүсез кайтма!» дип төрттереп тә алдылар. Юк! Нәфисәгә андый «тапкан» кияү кирәкми! Ир булсын

өчен генә, дус кызлары әйтмешли, бергә чәй эчеп утырыр өчен, култыклашып театр-концертларга йөрер өчен генә кирәк түгел, җанын ярып бирер өчен кирәк иде шул аңа юлдаш. Ә син ярып биргән җанны күз карасыдай саклап, учларында гына күтәреп йөртүче ир-егетләр бар микән, булса да, Нәфисәгә дигәне калды микән әле дөньяда?! Хәер, әнисе әллә уйнап, әллә чынлап гел әйтә килде: «Бер дә борчылма, кызым, вакыты җиткәч үз тиңең очрар юлыңда... Аллаһы Тәгалә һәрбер җанны икегә бүлә икән иңдерер алдыннан... Менә шул – Ходай тарафыннан тамгаланган үз яртысын тапкан кеше генә бәхетле була. Син дә табарсың, Алла боерса...» Ә ул – Нәфисәнең өлешенә тиеш «ярты» һаман табылмый да табылмый.

«Бәкер» дә «Бәкер» дип, юкка гына мактап сөйләмиләр икән! Оҗмах бакчасын барып күргән, кайтып сөйләгән кеше булмаса да, тауларга сыенып, яшеллеккә, гөл-чәчәкләргә тулып, һәр почмагында кайгыртучан кеше кулларының җылысы сизелеп торучы ял йортының капкасыннан килеп керүгә үк таң калды Нәфисә. Капкада кизү торучы агай йомшак дәшеп, машинасын куяр өчен урынны да күрсәткәч, бөтенләй аптырады. Юкса юл буе шул турыда уйлап, борчылып килгән иде. Кызның соклану-гаҗәпләнүле соравына җавабы кыска булды агайның: «Хуҗабыз әйбәт!»

Тиешле язу-сызуларны күрсәтеп, бүлмә ачкычын алгач, килүче-китүчеләрне теркәп-барлап утыручы кыз татарчалап «Аккош» дигәнгә аптырап калуын сиздермичә, үзенең өлешенә чыккан бинага юл тотты. Эзләп, буталып йөрмәс өчен, каршысына култыклашып килүче ир-ат белән хатын-кыздан сорыйсы итте Нәфисә. «Извините, подскажите, пожалуйста, корпус «Лебедь»?..» – дип башлаган иде, рус кешеләре аны төзәтте: Не «Лебедь», а «Аккош». Здесь все по-татарски: «Тургай», «Сандугач»... Менә сиңа мә! Ә без рус туганнарыбызга әйтү ансатрак булсын өчен татарча атамаларны гына түгел, мулла кушкан исемнәребезгә кадәр бозып-сындырып бетерәбез түгелме?! Әнә бит, башларына төшкәч, бик матур әйтәләр татарчасын да!

«Аккош»ка килеп җиткәндә, утыргычларда берничә ир-ат гәпләшеп-көлешеп утыра иде. Нәфисәне күргәч, кайсыдыр тел шартлатып, «оһо-о!» дип куйды. Тик араларыннан берсе генә сикереп торып, аның юл сумкасына үрелде:

– Гафу итегез мин авыл малаен әрсезлегем өчен... Әйдәгез, мин сезгә булышам...

Йә Аллам! Гәүдәсе бер якка кыйшайган. Җайсыз адым ясаса, егылып китәр кебек. Гәүдәсе кыйшайган яктагы кулы иләмсез озын булып, җиргә кадәр диярлек салынып төшкән. Аягы, киресенчә, кыскарак күренә. Нәфисәнең күргәне дә, ишеткәне дә бар: халык телендә ДЦП – детский церебральный паралич дип йөртелүче авыруга юлыкканнарның гәүдә төзелешенә генә түгел, йөз-кыяфәтләренә дә эз сала әлеге афәт гадәттә. Ни гаҗәп, бу егетнең битенә, авыз-борыны тирәсенә «кагылмаган».

Нәфисә дерт итеп сискәнеп китте. Моңарчы үзенең барлыгын сиздермичә, күкрәк читлегендә тыныч кына тибеп ятучы йөрәге сулкылдап куйды. Кызгану хисеннәндер дияр идең, кызганмады ул аны, киресенчә, сау-сәламәт ирләрдән алда урыныннан торып, ярдәм итәргә ашыкканына сокланды гына.

– Бу гарип нишләп йөри икән монда дип, аптырап калдыгызмы?! Аптырамагыз. Ялга килдем мин дә... Ел саен киләм. Үз кеше булып беттем инде... Бирегез сумкаларыгызны, хатын-кыз матурлык өчен яратылган, авыр йөк күтәрер өчен түгел... – дип, ай-вайлатып, Нәфисәнең йөген үз кулына күчерде. – Күтәрә алмас, егылып китәр дип курыкмагыз... егылмыйм. Мин бит авыл малае!

Һәр сүзенә диярлек «гарип» дип кыстырса да, оялу-кимсенү төсмерләре сизелми иде егетнең сүзләрендә, үзе әйтмешли, авыл малаенда. Шуңадырмы, кызгану түгел, аптырау, соклану хисләре арта барды Нәфисәдә аңа карата.

Билгеләнгән бүлмәгә урнашып, ерак юл тузаннарын «коеп» алуга, көндезге ашка барыр вакыт та җитте. Юл киемнәрен җиңелчә җәйге күлмәккә алмаштырып урамга чыгуга, күз алдында ачылып киткән көтелмәгән күренештән югалып калды хәтта Нәфисә. Каршысында костюм-чалбардан, ак күлмәктән баягы «авыл малае» басып тора иде. Аягында ялт иткән ботинкалар. Тик... киеме бик тә килешле, зәвыклы булса да, озын буйлы, ыспай ирләрнеке кебек гәүдәсенә ятышып тормый, ничектер таякка элеп куйган кебегрәк тәэсир калдыра...

– Ашханәгә юл күрсәтим дип сезне көтеп торам, – диде ул, Нәфисәнең гәүдәсе ишектән күренүгә. – Юл югалтуыгыз бар, сез беренче генә көн бит әле... Күлмәк килешә икән үзегезгә... бөтенләй икенче кеше...

– Рәхмәт. Сезгә дә шулай... Танымый тордым хәтта...

– Ышанды дип уйлагыз. Ни кисәң дә, минеке билгеле инде: алдан карасаң да, арттан карасаң да шул бер кәкре, янтайган... – дип, үз сүзеннән үзе рәхәтләнеп көлде.

Аңа кушылып көләргәме, авызны йомып, дәшми генә барыргамы икәнен белмәүдән бөтенләй гаҗиз калды Нәфисә. Алар ашханәгә килеп җиткәнче, каршы очраган ял итүчеләрнең һәрберсе диярлек, аптырау-гаҗәпләнүләрен яшереп тормыйча, борыла-борыла артларыннан карап калды.

– Менә күрдегезме, сиздегезме? Ничек гарипкә ияреп йөри икән бу чибәр кыз? Беткән микәнни нормаль ир-атлар шундыйга иярмәсә дигән карашларны? – Нәфисәнең җавабын көтеп тормастан, сүзен дәвам итте: – Мин гомерем буе тоя-тоя, ишетә-ишетә, аптырамый башладым инде хәзер. Фани дөнья шулай корылган: минеке кебек кәкре гәүдә түгел, бер аягы бераз кыскарак яки кулында бер генә бармагы булмаса, бер күзе сукыр яки борыны зуррак булса да, халык сәерсенеп карый. Андыйларның да күкрәк читлегендә йөрәк сулкылдап тибүен, аларның да яшәргә, яратырга тулы хокукы барын беркем дә уйлап карамый...



Чыннан да, үзе әйтмешли, гомере буена күрә-күрә, ишетә-ишетә шулкадәр күнеккән, күрәмсең, «авыл малае», тавышында, үз-үзен тотышында дулкынлану, борчылу хисләренең төсмере дә юк иде.

Ашханә янына килеп җитәрәк, барган җиреннән кинәт туктап, Нәфисәгә таба борылды:

– Сез дип сөйләшеп, җәфаламыйк әле үзебезне. Имеш, сез дисәң зурлау була дип ялгышабыз гына. Иң бөек кодрәт иясенә син дип табынабыз бит юкса, син дип ялварабыз... Ризык җыярга кергәнче, танышып, исемнәрне белешеп, сингә күчәргә вакыт җиткәндер... Мин авыл малае Камил.

– Мин Нәфисә...

– Исемең җисемеңә бик тә туры килә икән. Минеке генә... Нинди Камил булыйм ди инде мин!

– Сезнеке дә... гафу... синең исемең дә бик туры килә үзеңә. Камиллеккә акыл-фигыль камиллеге дә керә бит әле.

– Рәхмәт... Нишлисең, үзеннән тормаган яклары да бар шул кеше язмышының... Бәлки мин дә болай булмас идем...

Ашханәгә килеп кергәч, Камил алданрак атлап, ике поднос алды да, Нәфисәне үткәреп, үзе аның артыннан басты. Нәфисәнең тиешле ризыкларны алып бетергәнен күргәч:

– Борчылма. Үзем... – дип, подносны күтәреп тә китте.

Тик... бер-ике адым атларга да өлгермәде, поднос бер якка кыйшаеп, тәлинкә, кашык, чынаяклар идәнгә сибелде.

Хәлне аңладылар, күрәмсең, өстәлләр артында ашап утыручылар да, залда савыт-саба җыештырып йөрүчеләр дә «аһ» итмәде. Моны күреп, Нәфисә дә сер бирмәскә тырышты.

– Гафу итегез! Кирәк бит... Башка чакта тәлинкә-чынаякларны подноска куймыйча, берәмләп ташый идем өстәлгә... Бу юлы... Янәсе егетлек күрсәтәм... Шулай шул инде... Нишлисең, гәүдәмнең сул ягы миңа бөтенләй буйсынмый...

Ашханәдән чыккач, Камил күл буена төшәргә тәкъдим итте.

– Монда күлләр дә бармыни? – дип кызыксынган Нәфисәгә:

– Күл генәме соң, сөлекләре, су көзәннәре, аккошлары да бар. Җиде аккош! – диде.

– Җиде?! – дип гаҗәпләнде Нәфисә. – Каян килгән ди монда җидәү?! Булганда да гадәттә бер-ике булырга мөмкин.

– Дөрес фикерлисең. Шул икедән башланган инде эш монда да. Яз көне ике аккош күлгә төшкән. Бераздан аларның биш бәбиләре туган... – Камил көлеп җибәрде. – Тумаган ла инде, йомырка ярып чыккан. Бу – Бәкердә беренче очрак, диләр. Әнә-әнә, күрәсеңме, камышлар буенда йөзеп йөриләр.

Күпме генә караса да, Нәфисә ике аккоштан башканы күрмәде. Шул турыда әйткәч, рәхәтләнеп көлде Камил.

– «Гадкий утёнок» әкиятен исеңә төшер әле. Хәтерлә аккош бибиенең нинди төстә булганын.

Бу юлы Нәфисә рәхәтләнеп көлде:


– Әйе шул! Мин юләр җиде ап-ак кош эзлим тагын...

Аккошлар белән хозурлангач, күл тирәли ял итүчеләр йөри торган сукмак буйлап киттеләр.

– Игътибар иттеңме, – диде Камил, кинәт кенә барган җиреннән туктап. – Без килгәнне күргәч, тиз генә бәбиләрен камышлар арасына алып кереп яшерде аккошлар. Без күп очракта, берәр кешегә ачуыбыз килсә, «хайваннан да начаррак...» дип орышабыз. Ә бит хайваннар кешеләрдән акыллырак... Әнием дә мине шулай саклаган булса... – Камил, сөйләргәме-юкмы икәнен хәл иткәндәй, беравык дәшми торды. – Кеше саен сөйләп йөри торган сүз түгел инде. Сер дисәң дә дөрестер. Инде безгә танышып-аралашып китүне насыйп иткән икән Раббыбыз, сиңа ул серне белү тиеш дип исәплим... Беләсеңме, мин гомерем буе күңелемдә әниемә үпкә... Юк-юк! Үпкә генә түгел! Рәнҗеш саклыйм. Гафу ителмәслек рәнҗеш... Бала чактан ук килә ул... Синең шактый ачулы, хәтта усалланып киткән карашыңны тойдым, Нәфисә. Әйе! Аңлыйм. Безне бу дөньяга китергән әниләребезгә үпкәләргә, рәнҗергә һич кенә дә хакыбыз юк икәнлеген, оҗмах әниләрнең аяк астында икәнен дә беләм. Тик...

...Авылда урта мәктәпне тәмамлагач, институтка китапханәчелеккә укырга керә әнием. Беренче курс имтиханнарын уңышлы тапшырып, каникулга кайтып барганда, тузанлы юлдан җәяүләп атлаучы кызны күреп, район түрәсе машинасына утырта аны. Җай гына сөйләшеп кайткан җиреннән борылып урман юлына кереп китә... Һәм... әниемне көчли. «Авызыңны ачсаң, нәселегезне корытам...» дип яный. Дәшми әни. Бераздан балага узганлыгын төшенә. Укуын дәвам итү нияте белән Казанга килгәч тә, врачларга барырга курка. Баласын төшерер өчен ниләр генә майтарып карамый ул. Инде беленә башлаган корсагын өстәл урындык почмакларына ышку, тирән чокырларга сикерү, капчыклар күтәрү, ниндидер сыекчалар эчү дисеңме, берсе дә булышмый. Институтны ташлап, авылга кайтып китүдән башка чара калмый. Әтиәнисен, ягъни минем әби-бабайны, «бер егет белән вәгъдәләштек тә, торыр җире булмагач, аерылыштык...» дип алдый.

Вакыты җиткәч, мин дөньяга килгәнмен. Менә шушындый – камил җире бик аз, шыр гарип булып... Ирдән аерылу, бала ияртеп башка иргә чыгулар табигый хәл. Әмма... кайсы үги әтинең чит-ят, җитмәсә, гарип баланы карыйсы килсен?! Чыга алмады ул кияүгә. Иң гаҗәпләндергәне: үзенең бәхетсезлегендә гел мине гаепләде. «Син минем бәхетсезлегем... Син генә мине бәхетсез иттең! Корсагымда үлгән булсаң шунда... Тумаган булсаң...» дип, елый-елый каһәрләде. Кыйнаган чаклары да күп булды. Язган бит әле Әкрам Даутов: «...Күкрәк сөтең тәме телемдә. Изге теләкләрең мине җитәкләде адашамын дигән көнемдә...» дип. Мин күкрәк сөтенең тәмен белмим. Изге теләкләр



Рәсем: Наталья Васильева

ишетмәдем. Ышанасыңмы, ул мине бер генә мәртәбә дә кулларына алып сөймәде, күкрәгенә кысмады...

Бала күңеле авыр сүзгә, начар эш-гамәлләргә аеруча сизгер була бит! Шуның өчен дә без бала чакта үзебез белән булган хәлләрне гомер буе хәтерлибез... Кем белә, үсеп җиткәч, акыл утырткачрак әйткән булса, бәлкем уйлап та бирмәс идем. Ә болай... ул мине дөньяга тудырган анам икәнен онытмаган хәлдә, гафу итә алмадым... гафу итә алмыйм... Гарьлегемнән, батып үлмәкче булып, суга да ташланып карадым бала чагымда, күреп алып, тартып чыгардылар... Ә теге... миңа гомер бирүдә катнашкан ир кешенең кем икәнен белмим дә, беләсем дә килми. Кирәкмени мин аңа?! Кирәксенсә, җир тишегеннән дә эзләп табар иде... Бу – сиңа сөйләгәннәрем еллар дәвамында халык телендә йөри-йөри күгәреп-тутыгып беткән гайбәтләр, имеш-мимешләрдән исән калганнары гына...

Менә шулай... Яши-яши, бәхетсезлегемне бәхет дип алданырга, үземне шуңа ышандырырга, үземне үзем юатырга өйрәндем. Дөресен генә әйткәндә, уйсыз заманда яшибез. Хиссез... Иң мөһиме: тамак тук, өс бөтен... Җанында нинди хисләр кайный, нигә елый ул... нигә сыкрый... тыңлаучы да, аңлаучы да юк... Бигрәк тә минем кебек гарип... кәкре-бөкре гәүдә... Әниледән – әнисез, әтиледән – әтисез... Тоям бит мин үземә текәлгән кызганудан бигрәк чиркангыч карашларны, гомерем буена тоям...

Гафу ит, мин сиңа беркем белән дә бүлешмәгән, хәтта үземнән дә яшергән серләремне ачтым. Үземне аклау өчен түгел, аңлау табарга өметләнеп тә түгел бугай... Син мине аңлап та бетермәссең, гаепләрсең дә бәлкем, Нәфисә. Сөйләгәннәремә карашыңны, фикереңне дә ишетәсем килми. Нинди булса да, үзеңдә калсын... «Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә...» дип юкка гына әйтми халык. Әнием гарипләндермәсә, синең каршыңда нәүмиз басып торыр идемме?! «Бер күрүдә ошаттым мин сине...» дияр идем. Ә болай... син – үрелеп буем җитмәс биеклектә...

Төнне йокысыз үткәрде диярлек Нәфисә. Таң алдыннан гына бераз йокымсырап алды. Уйландым диярлек уй да кермәде юкса башына. Камил сөйләгәннәрне кабат башыннан үткәреп, үз нәтиҗәләрен дә чыгармады шикелле. Кызгану хисе дә юк, елыйсы да килми... Хәер, Камил үзен кызгандырыр өчен сөйләмәде бит боларны... Аның башында бер генә уй – Камилне күрү! Иртәнге ашка кадәр шактый вакыт бар әле. Камил «Тургай»да урнашканын әйткән иде. Киенеп урамга чыкты да туп-туры шунда китте. Шакыгач, шактый күтәреп, Нәфисә эзләп тапкан бүлмә ишеген ачтылар.



– Көттергән өчен гафу итегез, йоклый идек әле... – Ишек ачучы ир, күзләрен угалап, киерелеп алды. Камилне сорагач: – Ул бу вакытта бассейнда була. Шундадыр... – диде.

Нәфисә дә бассейнга язылды. Гомумән, монда дәвалану чаралары күп. Җаның теләгәнен сайлап алырга була. Күренеп торган чире булмагач, Нәфисә берничәсен генә сайлады. Күбрәк табигатьтә буласы, җәйнең матурлыгын күзәтәсе килде аның. Чыннан да, табигать искиткеч! Таулар, чишмәләр, тугайлыклар, болыннар, җәнлекләр. Байбаклары гына да ни тора Бәкернең! Буш вакытының күп өлешен Камил белән үткәрде. Бассейнда да йөзделәр, «Мәхәббәт тавы»на да менделәр. Анда менгәч, Камил:

– Бер елны мин ялга килгәч, «Мәхәббәт тавы»на өч йөз нарат утырттылар санаторий хезмәткәрләре. Миңа да бер агач утыртырга рөхсәт иттеләр. Үземнең агачыма тамга да салып калдырган идем. «Минем кебек кәкре-бөкере булып үсмә, шәм кебек зифа, нәфис булып үс...» дип дога да кылдым әле. Әйдә, шул наратымны табып, сәлам бирик үзенә, – диде. Эзләделәр, таптылар. Нәфисә үз күзләренә ышанмый торды хәтта. Камил утырткан нарат, чыннан да, үз яшьтәшләреннән буйга озынрак, шәм кебек сузылып үскән иде.

Тагын бер нәрсә таң калдырды Нәфисәне. Беркөнне көндезге аштан соң күкертле чишмә буена төшеп барганда җыр ишетте ул. Җыр гынамы?! Кемдер Рөстәм Яхинның «Киек казлар китә» романсын суза:

Киек казлар китә җылы якка
Төркемнәре белән гел бергә;
Казлар китә, ә без якын дуслар
Сагынышып килдек күрешергә...

Гаҗәпләнүен тыя алмыйча, җыр ишетелгән якка китте. Бераз алда, сул яктарак, куаклар буенда берничә ир-ат, дүрт-биш хатын-кыз боҗра ясап баскан. Якынрак килсә, боҗра эчендә Камил «Киек казлар китә»не җырлый!

– Татарларның тамаша залына рәхим итегез... – дип каршы алдылар аны. – Әйдәгез, сездән дә бер җыр. Камил сезне хор дирижеры диде бит...

Ялындырып торуны кирәк тапмады Нәфисә. Уртага кереп басты да сузып-сузып күңеленә килгән беренче җыр – «Тәскирә»не җырлап та җибәрде:

Агып ла китте, агып ла китте
Яулыгым кар суына, шул,
Яулыгым кар суына...
Их, дусларым, чыдый алмыйм
Йөрәгем ярсуына, шул,
Йөрәгем ярсуына-а-а...
Сикереп-сикереп агадыр кар суы-ы-ы,
Ник басылмый йөрәгем ярсуы-ы-ы...

Гөрләтеп кул чаптылар. «Кич танцыга килегез!» – дип озатып калдылар.

Нәфисә танцы-биюләр уза торган мәйданга килеп җиткәндә, кемдер уйнаган бию көенә халык шау-гөр килеп татарча бии иде. Игътибар итеп караса, Камилне урындыкка җайлап утыртканнар, каршысына тагын бер урындык куеп, аякларын җайлап урнаштырганнар. Баянны сузып салганнар. Камил, бар дөньясын онытып, бию көен сыздыра...

Бүгенге кебек танцылар, кичә-концертлар тәмамлангач, ял итүчеләр йокы алдыннан «урам әйләнә». Шунда Камилгә үзен гаҗәпләндергән җавапсыз сорауларын бирде Нәфисә:

– Син мине көннән-көн ныграк гаҗәпләндерәсең, Камил! Инде һөнәрләре беткәндер дисәм, тагын яңасы ачыла тора. Йә, мин белмәгән тагын нинди һөнәрләрең калды?!

Камил рәхәтләнеп көлеп куйды.

– Күп инде алар, – диде ул. – Капчык төбендә мәкинә бетәмени... Хәзер бит бөтен кеше бизнесмен. Хәтта ат тизәген җыючы да... Без авылда челтәрлебизәкле тәрәзә кашагалары, койма, капкалар, зиратка чардуганнар ясыйбыз. Мин эскизларын-сызымнарын әзерлим, ике егет калганын ясый. Ошый халыкка. Күрше авыллардан да, Татарстаннан да заказлар килә. Безнең авыл белән Татарстанны сай гына Сөн суы аерып тора бит... Өстәвенә, клуб мөдире дә әле мин. Гаҗәпләнмә. Эшләргә кеше юк миннән башка. Нинди акыллы баш өч тиенгә эшләп йөрсен! Ә миңа иш янына кушарга ярый. Әни минем өстә бит. Инде җиде ел була. Теле юк, хәрәкәт юк... Күзләремә мөлдерәп карап тик ята...

Ә икенче көнне, көтмәгәндә диярлек, Камилнең китәсе билгеле булды. Ниндидер парның санаулы ял көннәре беткән, кайтышлый Камилләрнең авылы аша узалар икән. Аны үзләре белән алмакчылар. Машинага утырыр алдыннан саубуллашканда, күзләрен түбән иеп:

– Мин сәер авыл малаен исеңә алгаларсың бәлкем, Нәфисә... Юлың төшсә, авылыбызга тукталмый узып китмә. Бәләкәй генә булса да, үзенең татар авылы икәнен онытмаучы авыл ул... Аерылышу минутларының шулай кинәт килеп чыгуы яхшырактыр да әле... – диде.

Камил киткәч, Нәфисәне ниндидер әйтеп аңлата алмый торган сагыш басты. Күктә кояш елмаеп торса да, тирә-юньдә ниндидер сорылык, төссез төкселек... Күңелдә бушлык... Кемдер, бик тә кадерле җан иясе көтмәгәндә-уйламаганда кинәт мәңгелек йортка – бакыйлыкка күчкән диярсең... Нигә кочаклап алмады ул Камилне?! Нигә җылы сүзләр әйтмәде... Башка беркемгә дә беркайчан да әйтелмәгән бик тә серле-кадерле сүзләре бар иде бит юкса!

...Тагын ике көннән, ялын тәмамлап бетермичә, Нәфисә дә юлга кузгалды. Моңарчы билгесез юл булса да, минут саен «через сто метров поверните направо...», «через триста метров – налево...» дип, юл өйрәтеп торучы навигаторы адаштырмас аны, «Авыл малае»ның авылына туп-туры китереп чыгарыр...

КИТАПНЫҢ БӘХЕТЕ – УКУЧЫ УЙЛАП БЕТЕРӘ АЛГАН ФАНТАЗИЯДӘ

Луиза ШАРОВА, шагыйрә, Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры директоры

КИТАП УКУ УЛ...

– Башка язмышларны кичереп, башка дөньяларда яшәп карый алу бәхете. Фильмнар, спектакльләр дә бирә бу мөмкинлекне, әмма аларда режиссёр концепциясе һәм актерлар уены бар. Ә китапларны син үз фантазияң белән баетып, каһарманнарны үзеңчә күреп, үзеңчә конструкцияләр кора аласың.

УКЫРГА МӘХӘББӘТ УЯТКАН КИТАП...

– Безнең өй китаплар белән шыплап тулган иде. Әле хәреф таный башлаганчы ук алар мине гел ымсындырды. Әбием миңа китапларны йокларга ятар алдыннан кычкырып укый иде. «Кыйссаи Йосыф»ны көйли, «Казан утлары»нда басылып чыккан әсәрләрне укый. Дүрт яшьтән мин инде үзем укый башладым. Иң беренче китаплардан Муса Җәлилнең зур кызыл альбомын, Каюм Насыйриның «Әбугалисина»сын, Дәрҗия Аппакованың кечкенә Бану турындагы хикәятен, «Маленький принц», «Пеппи Длинныйчулок», «Малыш и Карлсон», Шварц, Бажов, Туве Янссон, Джанни Родари әкиятләрен яхшы хәтерлим... «Бу китапны сиңа укырга әле иртә», – дип беркайчан да тыймадылар. Бездә һәрчак укыган китаплар турында сөйләшү гадәте бар иде. Ул хәзер дә шулай.

МИНЕ ҺӘМ ДӨНЬЯГА КАРАШЫМНЫ ҮЗГӘРТКӘН КИТАП...

– Решат Нури Гюнтекинның «Чалы кошы» булгандыр. Фәридәдә үземне таптым. Безнең ишегалды уртасында зур өрәңге агачы үсеп утыра иде, ул бөкре генә шыксыз бер агач иде инде, әмма минем өчен – үзе бер дөнья. Шуңа менеп утырып, алма кимерә-кимерә, Фәридә булып уйный идем. Владислав Крапивинның «Журавлёнок и молнии», Этель Лилиан Войничның «Овод»ы, Вальтер Скоттның «Айвенго»сы, Дюма романнары бик тәэсирләндерде. Мин кышларын ишегалдында замоклар төзеп, җәйләрен мәктәп бакчасында рыцарь турнирлары оештырып, декорацияләр корып, шул романнарны уйный идем. Татар классикасыннан – Заһир Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә», Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр», Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре», Аяз Гыйләҗев, Фәүзия Бәйрәмова әсәрләре тәэсирләндерде.

ҮСМЕР ВАКЫТЫМДАГЫ ДУСТЫМ...

– Луиза Мей Олкоттның «Маленькие женщины» әсәре. Кат-кат әйләнеп кайтканымны хәтерлим. Андагы героиня – Джо Марч бик ошый иде. Михаил Булгаковның «Мастер и Маргарита» романын укып туя алмавым хәтердә. Үсмер чагымда томлап-томлап классикларны укыдым, әсәрләрен генә түгел, ә бигрәк тә соңгы томнарда булган хатларын, истәлекләрен, мәкаләләрен. Мин әтигә озын исемлек язып бирәм, шуларны, иренмичә эзләп таба иде. Командировкалардан олаулап фәнни китаплар да алып кайта иде. «Жизнь замечательных людей» сериясендә чыккан китаплар хәзер дә китапханәмнең иң кадерле урынында саклана. Фәнни җитәкчем Резеда апа Ганиева миңа Көнчыгыш әдәбиятын ачты. Хәзер дә тирәюнемдә «китап җене» кагылган кешеләр – Ландыш Әбүдәрова, Айдар Әхмәдиев, Айдар Шәйхин. Бер-беребезгә китапларны һәм яңа авторларны бүләк итешәбез. Бу – зур бәхет!

ӨСТӘЛ КИТАБЫМ...

– Аерым гына андый китап юк, ул алышынып тора, чөнки үзебез гел үзгәреп торабыз. Шулай да гел-гел әйләнеп кайта торган романнарым бар. Мәсәлән, Питер Хёг исемле Дания язучысының «Фрекен Смилла и её чувство снега» романы. Үзәгемне өзә бу әсәр.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

– Америкадада яшәгән Азар Нафиси исемле иран язучысының «Читая «Лолиту» в Тегеране» китабы. Азар Нафиси – элеккеге Тегеран мэры һәм заманында Иран парламентына сайланган активист хатын-кыз гаиләсендә туып-үскән бала. Ислам революциясе башлангач, цензура белән янаулар нәтиҗәсендә күпләрнең хыяллары ничек җимерелгәне турында бәян итә. Югыйсә бу хатын-кызлар бернинди дә зыянлы эш белән шөгыльләнми, бары тик җыелышып Фицджеральд, Остин, Набоковны укый... Әмма...

БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН КИТАПНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ...

– Икесе дә бердәй уңайлы. Күбрәк телефондагы, планшеттагы кушымталардан укыйм хәзер... Машинада барганда, әчпошыргыч җыелышларда утырганда... Вакытның тамчысын да әрәм итәсе килми!

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ...

– Барлык классиканы, үзебезнекен һәм рус әдәбиятын, дөнья әдәбиятын! Классика юкка гына классика түгел, ул кешегә балачактан – умыртка һәм нигез, ә олыгая төшкәч юаныч бирә.



Фото: Салават Камалетдинов. Татар-информ



ЯШӘЕШ

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

500 елдан артык педагогик стажы булган бу династияне мин җирдәге кояшка тиңләр идем. Аларның нуры, гасырлардан гасырларга күчеп, яктылык, җылылык тарата.

Авыр, җаваплы һәм дә мактаулы хезмәтне үз иткән, илдә нинди генә үзгәрешләр, авыр чорлар булуга карамастан, үз һөнәренә тугры калып, бала-оныкларында да укытучылык һөнәренә мәхәббәт тәрбияли алган Даутовлар нәселе хакында бу язмам. Исәнбай авылында яшәүче, 40 ел гомерен балалар укытуга багышлаган беренче категорияле укытучы, «Мәгарифтәге уңышлары өчен» күкрәк билгесенә, бик күп Рәхмәт хатлары, Мактау кәгазьләренә ия булган Фәридә Җәмилова – шул буынның бер вәкиле.

«Белем орлыклары салуның чишмә башында әтием Даутов Мәхмүтнең, әнием Фатыйманың ерак бабалары тора», – ди Фәридә апа. Мәхмүт абый ягыннан – Әхмәтвәли Ризванов, Фатыйма апа Даутова ягыннан Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алган Хафиз Корбангалин халык укытучылары булалар. «Әтием, – дип сөйли Фәридә апа, – Чистай шәһәрендә укытучылар әзерли торган мәктәпне тәмамлый. Ә соңрак Алабугада югары белем ала. Бик тырыш, сабыр, сүзен үткәрә белә торган кеше иде».

Бөек Ватан сугышы елларында Мәхмүт абый мәктәп директоры булып эшли. Аның инициативасы белән авылда 20 мең акча җыелып, җимерелгән авыл-шәһәрләрне торгызу фондына тапшырыла. Сталин имзасы белән килгән Рәхмәт хаты бүген дә авылыбыз музеенда саклана. Әтиләре сугышта булган ятим, ялангач балалар мәктәпкә укырга йөри алсын өчен, укытучылар белән берлектә җылы оекбашлар, итекләр, кышкы киемнәр җыюны оештыра. 33 ел буе мәктәп дигән балалар дөньясының ышанычлы калканы, терәге, яклаучысы, саклаучысы була Мәхмүт Даутов. Җидееллык мәктәпкә 1951 елда урта мәктәп статусы бирелү дә аның башлангычы белән эшләнә.

1942 елда Исәнбайдан килеп Уразайда укытучы булып эшләүче бик сөйкемле, акыллы, тыйнак Фатыймага өйләнә ул. Утлы сугыш еллары кавыштырган бу пар 40 ел татулыкта, тугрылыкта, хезмәт сөючәнлектә күпләргә өлге булды. Фатыйма апа 42 ел башлангыч сыйныф балаларына белем бирде. «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медаленә, «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булды. «Әни һәр елны белем көненә яңа костюм-күлмәк тектерде, алар һәрвакыт ак якалы була иде... Туган мәктәбемдә әнием белән бергә укытып йөргән чаклар – иң бәхетле чакларым! Ул минем остазым булды», – дип искә ала Фәридә апа.

Мәхмүт аганың туганнары Гыймаева Роза, Ризванова Җәүһәр, Җәмилова Зәкия, Якупов Мирзанур, хәләле Фатыйманың якын туганнары Мөхәммәдиева Рафика, Исмәгыйлева Зәйтүнә, Мөлекова Шәфыйкалар – һәрберсе гомерләрен белем-тәрбия бирүгә багышлаган фидакарь җаннар! Алай гына да түгел, алар укытучыларны тудырган укытучылар, остаз, мәгърифәтчеләр! Балалары, оныклары да педагог һөнәрен сайладылар.

Мәхмүт абый белән Фатыйма апа үзләре өч бала үстерә. Алар янына Мәхмүт абый үз абыйсының ятим калган төпчек баласын да сыендыра.

Бу гаиләдә үскән иң өлкән кыз – Фәридә апаны, укытучы гына түгел, аяклы энциклопедия дияр идем. Һәр буынны барлый, эзли, таба, тарихка кертә... Сөйләшүе дә ипле, матур. Шулай булмыйча! Ул бит татар теле һәм әдәбияты укытучысы!

– Әти-әнием укытучы булгач, кем булыйм икән дип уйлап тормадым. Алар кебек укытучы буласым килде. Кызларым да шушы һөнәрне сайлады, – ди Фәридә Мәхмүт кызы.

Олы кызлары Ләрисә Казанның 88 нче мәктәбендә сигез ел инглиз телен укыткан, кечесе Лениза исә, татар теле һәм әдәбияты белгечлеге алып, бүгенге көндә Чаллыда белем бирә. «Эш стажым 20 ел, димәк, династиядә минем дә өлешем бар!» – ди ул елмаеп.

Язмамның башында бу буынның асыл затларын җирдәге кояшка тиңләсәм, хәзер кояш нурларында коенган искиткеч матур гөлләмәгә охшатам. Беркайчан да сулмас чәчәкләр... Яңадан-яңа бөреләре ачыла тора... Яшәеш дәвам итә...

Әлфирә НИЗАМОВА.
Әгерҗе районы, Исәнбай авылы.

Фото: Резеда Галиуллина

Узган гасырдагы үзгәртеп кору җилләре күпләрнең язмышларын чәлпәрәмә китерде. Тәҗрибәле бик күп белгечләр юл чатында калды. Кем кая булдыра алды – шунда урнашты. Әрәссам Рөстәм Ясәвиев гомере буе җирсеп, сагынып яшәгән туган авылы Күзкәйгә кайтты.

Тик ул вакытта туган нигезендә инде башкалар яши иде. Шуңа каршы гына урнашкан иске бер йорт сатып алды да баш-аягы белән иҗатка чумды ул. Аның остаханәсенә керсәң, чын иҗат кайнавын сизәсең. Борынгы нәкышләр төшерелгән кувшиннар, агачтан ясалган җәнлек сыннары, икмәк саклый торган тартманы гына күр! Кыскасы, кечкенә генә остаханәдә үзе бер әкияти дөнья.

Рөстәм төзегән йорт та башкаларныкына охшамаган: идәннән түшәмгә кадәр уелган тәрәзәләрдән кояш нуры бөркелеп керә. Ишегалды уртасына матур итеп чатыр ясап куйган.

Картиналар да яза Рөстәм. Тик пейзажларында нигәдер сагыш, моң тоемлана. Балачак, яшьлек хатирәләре белән уралган туган авылының кыйбласы үзгәрүдән киләдер ул, бәлки.

Рөстәм Ясәвиев Күзкәйдә урта мәктәп тәмамлаган, аннары Казан сәнгать училищесында талантын чарлаган, сәнгатьтәге төрле жанр серләренә өйрәнгән. Чаллыда төзелешләр кайнаган елларда «Камгэсэнергострой»-ның сәнгать-бизәкләү участогында эшләгән, 47 нче һөнәр училищесында укучы яшьләрне агачтан ясау осталыгына өйрәткән, яраткан хезмәтендә иҗади табышларга, югары нәтиҗәләргә ирешкән. Күпсанлы Мактау кәгазьләре, төрле иҗади конкурсларда алган дипломнар шул хакта сөйли. Авыр вакытларда кыенлыкларны җиңәргә булышкан хатыны Дамирага бик рәхмәтле ул.

Бер очрашуда: «Авыл баласына шулкадәр сәләт кемнән килгән?» – дип сорадым.

– Әти урманчы, бик оста итеп ат рәсемнәре ясый иде. Күрәсең, рәсем ясарга хирыслык миңа аннан күчкәндер, – ди Рөстәм. – Уйлаган композицияне агачтан уеп ясау кыен түгел, куллар чарланган. Ә менә бизәген уйлап табу, төсләр сайлау өчен эзләнергә кирәк. Эскизларны ясагач, архивымны актарам, компьютерда казынам, журналлардан хәзерге заман рәссамнарының иҗатын күзәтәм. Авылның табигате үзе үк матур, ул да илһам бирә. Иҗат ул – эзләнү, уйлану һәм табыш. Аның шатлыгы, куанычы да шунда, – ди оста.

Белемен балаларга өйрәтеп калдыру хыялы да бар аның. Әле кайткан гына елларында район башлыгы янына да барган, тик кызыксынучы гына булмаган.

– Хыялымны кызым Алисә тормышка ашырыр дип ышанам. Кечкенәдән җитәкләп сәнгать мәктәбенә йөрттем. Бик матур картиналар яза, минем агач эшләнмәләремә бизәк төшерә. Казанда балалар бакчасында махсус төркемдә сабыйларны рәсем ясарга өйрәтә ул, – дип сөйли Рөстәм.

Останың хыялы тормышка ашар, Аллаһ боерса. Әнә Алисәнең әле яңа тәпи йөри башлаган улы да, бөтен дөньясын онытып, нәни чүкече белән нидер чүки, нидер ясарга тырышып мәш килә. Алма агачыннан ерак төшми, диләр.

Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА.
Тукай районы, Күзкәй авылы.

Ульяновск өлкәсенең без яшәгән Димитровград шәһәрендә татарлар бик күп. Ләкин «Сөембикә» журналын бер мин генә алдырам. «Ник яздырмыйсыз?» – дип әйтеп карыйм, без – мишәрләр, татар сүзләрен аңлап бетермибез, диләр.

Мин дә мишәр егетенә кияүгә чыктым. Ул вакытта ирем чып-чын мишәрчә генә сөйләшә, күп сүзләрен аңлап та бетермим. «Русча әйт әле, ни дигән сүз ул?» – дип сорый идем. Еллар узды, ирем чип-чиста итеп татарча сөйләшергә өйрәнде. 62 ел бергә яшәп, ике бала үстердек. Узган ел 83 яшендә бакыйлыкка күчте.

Тумышым белән Татарстанның Мамадыш районы Вахит авылы кызы мин. 1941 елның 1 гыйнварында туганмын. Исемемне әтием Роза дип яздырып кайткан. «Роза – гөлем чәчәге, матур безнең тормышыбыз, бәхетле киләчәге», дип, сине кулында күтәреп йөрде», – дип сөйли иде әни. Аны шул ук елның июнь аенда сугышка алып киткәннәр. Баштарак «Кызым Розаны сакла, тәрбияләп тор», – дип язылган өчпочмаклы хатлары килеп торган. 1942 елның февралендә әни «Ваш муж Фатихов Ильдерхан пропал без вести» дигән хәбәр алган. Кайтыр дип бик көтсәк тә, әти кайтмады. Әни мине гел «укы, укы» дип үстерде. Яхшы укыдым. Безнең авыл – зур татар авылы. Барлык фәннәрне дә татарча гына укыдык.

Унынчы классны тәмамлагач, Тәтешкә – бухгалтерлыкка укырга керергә киттем. Диплом алгач, мине юллама белән Чистайга җибәрделәр. Тәтештә укыганда Ульяновск өлкәсеннән килеп, агрономлыкка укып йөргән бер егет белән дуслашкан идек. Укуын тәгәлләгәч, ул да Чистайга җибәрүләрен сораган. Мин бухгалтер булып эшләгән совхозга эшкә килде. Шулай итеп безнең тормыш сукмаклары бергә кушылды да уртак бер олы юлга әверелде. Иремнең туган ягына күченеп кайттык. Мин – бухгалтер, ул агроном булып эшлибез. Читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керде. Укып бетергәч, иремне бик зур совхозга директор итеп билгеләделәр.

Язмышым шулай булгандыр, гомер буе Татарстанымны сагындым. Әни янына бик сирәк кайтылды. Ул да ялгызы мине сагынып яшәде.

Балаларым русча гына укысалар да, икесе дә татарча яхшы белә. Өйдә бары татарча гына сөйләштек. Русчага күчсәләр, без бит татарча гына беләбез, дип әйтә идек. Инде ике балабызга дүрт онык, дүрт оныкка дүрт торын үсеп килә. Берүк бәхетләре генә булсын.

«Сөембикә» журналын «Азат хатын» чагыннан яратып укыйм. Ул килсә, берәр туганым килгәндәй була, сагынуларым басыла. Рәхмәт сезгә.

Роза ФАТЫЙХОВА.
Ульяновск өлкәсе,
Димитровград шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru



ГАП-ГАДИ БӘХЕТ

Тышта котырыпмы-котырып буран дулый, ә өстәлемдә җәйге нигъмәт – җир җиләкләре. «Ал, нәнәм, ал. Мине искә ала-ала чәй эчәрсең, түгәрәк алмам», – дип кыстый-кыстый Хәвәрия апа биреп җибәргән җиләкләр… 84 яшьлек Хәвәрия апаның үз кулы белән туган авылы Ташсу болыннарында – кояшның бар энергиясен үзенә туплап кызарган, мәмрәп пешкәннәрен генә чемләп җыйган җиләкләр. Җәйдән бирле суыткычта торып туңсалар да, табынга куйгач, салкын кышта да җәй җылысын мулдан өләшәләр. Чәйгә салуга аш-су бүлмәсенә таралырга өлгергән хуш исе эссе җәй, чәчәкле болыннардан бигрәк, Хәвәрия апаның үзе сөйләгәннәренә дә алып кайтты. Язмышында җиләк тәменнән бигрәк балан ачылары күбрәк шул аның…

Биектау районы Чәмәк авылында өч кыз, өч малай – алты бертуган үсә алар. 1938 елда дөньяга килгән Хәвәрия өчен авыр сугыш еллары ягылмаган, салкын өй, ачлык-ялангачлык белән истә калган. Әтиләре сугыштан биле чәрдәкләнеп кайта, әмма иң мөһиме – кайта! «Әти ике ел урын өстендә ятты. Әни матчага сөлге элә, әти шуңа тотынып кына урыныннан тора иде», – дип искә ала Хәвәрия апа. Хатыны тәрбиясе, авыл һавасы, аяз күк йөзе булыша – әтиләре тернәкләнә. «Әти гомер буе сарык көтүе көтте – бүтән авыр эшкә ярамады… Әнинең генә гомере кыска булды – 66 яшендә йөрәк белән китеп барды. Ул вакытта энем дә өйләнмәгән иде әле. Әти әнидән калып 12 ел яшәде…»

Яшь чак – җүләр чак

Чәмәк авылы умарталыгында тәҗрибәле умартачы Зиннәт абыйсы кул астында кайнашып йөргән Хәвәриянең дә 21 е тулып киткән ләбаса! Җиләк сыман пешкән кыз артыннан йөргән егет-җилкенчәкләр дә аз түгел. Араларыннан Фоат дигәне бигрәк үҗәт һәм гайрәтле күренә. Төс-кыяфәткә дә чибәр. Җитмәсә, Ташсу авылының атаклы Кыштыр нәселеннән! Тирә-юньдә тырышлыгы, үҗәтлеге, гайрәте, көч-дәрманы белән дан тоткан нәсел бу.

Кичке политуку вакытында сүз куша аңа Фоат. Калганын егет бик тиз тота. 1959 елның 10 июнендә никах

укыталар, ә 12 июньдә кыз күршедәге Ташсу авылына килен булып төшә.

– Иң җүләр вакыт булган инде, нәнәм... Тик моны яшияши генә аңлыйсың икән шул – ул вакытта бернәрсә дә белмәгәнмен инде... – дип елмая Хәвәрия апа. – Умарталыкта эшләгәндә, кырда бил бөккән халыкка карап: «Бер тамчы суга да тилмереп эшли инде бу кешеләр», – дип жәлли идем, Ташсуга менгәч, үземә дә шул булды. Нәрсә дип менгәнмен инде, умарталыкта эшләп ятасы гына калган да бит. Әйе, яшь вакыт – җүләр вакыт...

Юк, үткәненә уфтанып, үкенеп әйтми ул бу сүзләрне, яшьлекнең кадерен белеп калыгыз дип киңәш итә сыман.

Килен чак

Кайнанасы Бибиҗамал яшь киленне бик ярата. Бу көннәр турында Хәвәрия апа үзе дә бик җылы искә ала:

– Әни белән 17 ел бергә яшәдек. Бик акыллы, сабыр, әйбәт хатын иде, аның турында бер генә яман сүз дә әйтеп булмый. Мин килен булып төшкәндә әле кайнатам да исән иде. Зур гаилә булып бер генә ел яшәп калдык, аннан кайнатам авырый башлады. Иремнең бертуган абыйсы Газизулла аны хастаханәгә алып барып күрсәтте. «Операция ясый торган түгел, соңга калгансыз», – дип кире кайтардылар. Шуннан соң өйдә генә ятты. Гайрәтле кеше иде – Кыштырлар данлыклы нәсел инде алар.

Яшерен-батырын түгел, Фоат бераз салгаларга яратты. Заманасы шул иде бит аның, нәнәм. Язын-көзен – кырда, кышын салкында, тимер-томыр арасында эшләгән механизатор шулай җылынгандыр, күрәсең. Ул вакытта авылда техникасы да юк. Йомышка әле монысы, әле тегесе килә. Тыңламыйча да булмый. Ә түләвен үзең беләсең инде, нәнәм... «Әй әни, нишләп улыңа әзрәк әйтмисең икән», – ди торган идем шул вакытларда. Үтә дә сабыр кеше иде кайнанам. Улын яманлап әйтүем, бәлки, ошап та бетмәгәндер. Бәгыреннән өзелеп төшкән газиз баласы бит ул аның... Үлгәнне торгызудан мәгънә юк, тынычлап ятсыннар, Аллаһы Тәгалә иман байлыгы бирсен. Язмышым шулай булгандыр, нәнәм...

Хәвәрия апаның шулай җылы итеп «нәнәм», «түгәрәк алмам» дип эндәшүеннән бәгыре туң булып каткан, еллар буе күңелендә таш йөрткән кеше дә эреп китәр, мөгаен.

– Кайнанамны соңгы юлга үзем тәрбияләп озаттым. Ике улы исән-сау булсалар да, бер дә алар янына барам димәде, бик тату яшәдек. Балаларымны караштты. Бер-бер артлы дүрт бала алып кайттым бит, нәнәм. Тик менә беренчесе генә үкенечле булды. Салкын тиеп үлеп китте... 1960 елның августында туган иде, ноябрьдә инде күзләрен йомды. Җир йөзендә өч ай да бер атна гына торып калды. Һаман да үземне гаеплим, игътибарым җитенкерәмәгәндер, дим, яшь идем бит әле... Икенче улым Илшатны Казанга сөт-катык сатырга барган җирдән табып кайттым. Элек шулай көянтә-чиләк белән Ташсудан басу аркылы Казанга чыгып китә идек бит... Әле ул вакытта Казан тирәсендә яшәүчеләр тавык, кош-корт асрыйлар – алар бик яратып ала иде. Аннан соң катык белән чәч тә юган заманнар иде әле... Бераздан Фәүкать белән Фәнисебез туды...

Ире – колхозда алдынгы механизатор, үзе – күмәк хуҗалыкта эшче. Гаилә түгәрәк. Бәхет шушы түгелме?! Тик дөнья түгәрәкләнгәч, аның бер җире кителәсен көт тә тор икән.

– 15 ел эчендә өч малай бүләк итте дә, китте дә барды... Шул үзе җенләнгән тракторы белән харап булды, – дип искә ала ул фаҗигале көн турында Хәвәрия апа.

Гап-гади көн була ул, тик тракторын ремонтларга дип киткән Фоаты гына кичен кире өенә кайтмый...

Тол калганда Хәвәрия апага нибары 35 яшь була. Ике елдан кайнанасы да дөнья куя.

– Сорап килүчеләр, димләүчеләр булды, әлбәттә... Һай, түгәрәк алмам, өч малай белән андый нәрсә уйларыма да кермәде. Гомерем буе эш белән юандым. Башны түбән идем дә эшләдем дә, эшләдем... Урманнан бер генә көн дә буш менмәдем: үземне белә башлаганнан бирле һаман утын күтәреп ташу. Ничек бу иңбашлары сызламый торгандыр?! Чәмәк урманында мин аяк басмаган бер генә почмак та юктыр. Элек бөтенебез урманда идек шул. Халыктан урманда эт куарлык та чыбык калмый иде. Хәзер әнә аста – инеш буенда күпме ауган агач тәгәрәп ята. «Безнең заманда нишләп булмадыгыз соң сез?» – дип, аларны кочаклап елыйм кайчак...

Бергә-бергә эшләгән иптәшләрем, дусларым бөтенесе үлеп бетте, мин, нишләптер, исән-сау әле. Сызланып, сыкранып та ятмыйм... Аллаһыма чиксез рәхмәтлемен!

Бәхетле дәү әни

– Малайлар бер-бер артлы үсә торды. Алар да бер дә ялкау булмады. Күрәсең, тырышлык, эшне сөю, үҗәтлек нәселдән килә торгандыр. Берзаман өчесен дә армиягә озаттым... 14 май көнне автобус капка төбенә килде дә үз янымда калган төпчек малаемны да алып китте. Шушы өйдә берүзем калдым... Хайваннар бар, суны чишмәдән ташыйсы, печән өсте җитеп килә... Элек үзебез өчен печән әзерләргә нибары ике көн бирәләр иде! Анда кем печән чабарга өлгерсен ди?! Олы улым Илшат Ерак Көнчыгышта хезмәт итте. Фәүкать – Чехословакиядә, анда безнең акча да йөрмәде. Төпчеге Фәнис – Свердловскида. Барысы да исән-имин кайтып урнаштылар. Өйләнәбез дигәч, берсен дә ким-хур итмәдем: өчесенә дә гөрләтеп туй ясадым, икесенә йорт та алып бирдем. Әле хәзер тора торган нигезне дә тиенләп җыйган акчага 1991 елда җиткереп чыктык.

Бүген Хәвәрия апа Хәбибуллина кадерле дәү әни, Ташсу авылының Ак әбисе булып гомер итә. Әмма уйлары әле һаман эштә, хезмәттә.

– Авылыбыз матур җирдә, ялкауланмаган кешегә бездә яшәргә була. Нигезебез дә рәхәт, уңайлы урында. Өч сыер, дүрт бозауны арканлап куябыз – җиләк кенә ашап яталар. Исән-сау гына була күрсеннәр. Хәзерге тормыш бик рәхәт, – ди ул, ныклы хуҗалыгы белән таныштырып. – Җәй җиттеме, җиләккә чыгып йөгерәм, әле икешәр мәртәбә барам. Кырларга чыккач, быелгы җиләкләрне дә күрсәттең, шөкер, дип, елый-елый Аллаһы Тәгаләмә рәхмәтләр әйтә-әйтә җыям...

Раил САДРЕТДИНОВ

Фото: Анна Арахамия



МӘККӘДӘН – ПИРАМИДАЛАР ИЛЕНӘ



Әлфия САМАТ

Бу юлы мин диңгез сәяхәтенә, беренче чиратта Мәккәдә булып, Гомрә хаҗын кылуны төп максат итеп юлга чыктым. Гәрчә ике генә көнгә алдан китеп, Мәккәдә бер генә төн кунасы булса да, Кәгъбәтулла тирәли тәваф кылуның җанга якын мизгелләрен берни белән дә алыштырмас идем. Әйе, бик кыска булды әлеге сихри халәтебез. Әмма ул тагын берничә елга җитәрлек рухи ризык шикелле, тән һәм җаныбызның һәрбер күзәнәгенә томырылып кереп калды. Инде менә аннан соңгы сәяхәтебез Кызыл диңгез буена урнашкан илләрдә дәвам итә. Мәккәдән нибары 70 чакрым чамасы ераклыктагы Җиддә шәһәрендә тукталган 18 катлы «Сплендида» корабле Согуд Гарәбстаны, Мисыр, Иордания кебек гарәп мәмләкәтләрендәге борынгы пәйгамбәрләр, фиргавеннәр чорындагы тарихи урыннарга алып килде безне. Коръәндә телгә алына торган фиргавен, гад, сәмуд кавеме яшәгән урыннарны, кыя ташлары арасында мәгарәләр ясап гомер иткән һәм Аллаһы Тәгалә тарафыннан юк ителгән нәбәти кавеме эзләрен каян күрер идек?..

Беренче тукталыш – Согуд Гарәбстанының Янбу шәһәрендә. Транспорт корабльләре туктала торган төп порт санала ул. Шәһәрнең иске өлешенә үзебез генә йөрергә чыктык. Моннан 2500 еллар элек Йәмәннән китерелгән ризык тәмләткечләр һәм хуш исле үләннәрдән ясалган матдәләрне Кызыл диңгез аша Мисырга чыгару урыны буларак ачылган. Хәзер биредә нефть эшкәртү, химия заводлары һәм тозлы диңгез суын төчеләндерү предприятиеләре эшли. Хәрби диңгез базасы, халыкара аэропорт бар. Һәм, әлбәттә, ул Мәккә, Мәдинәгә хаҗ кылырга баручыларны кучереп утырту өчен төп транспорт үзәге булып тора.

Лайнерыбыз иртәнгә хәтле диңгездә йөзгәндә сизмәгәнбез генә: төн буена яшенле яңгыр яуган икән. Пальма агачлары үскән аллеялардагы без кыйммәт бәягә сатып ала торган җир тулы хөрмә (финик) җимешләренә һәм аларның тапталып-изелеп ятуына чын-чынлап гаҗәпләнеп һәм җәлләп йөрергә туры килде. Урамнарда бер кеше күренми, өйлә намазы җиткәндә берничә ир-ат мәчеткә килде. Хатын-кызлар ягы бикле иде, аны көчкә ачтырып, намазыбызны укып чыга алдык. Хатын-кызлар биредә, гомумән, мәчеткә йөрми, безгә дә сәерсенеп карадылар. Озак кына йөри торгач, бер кибеткә кереп манго согы алып эчтек. Гарәп иленә мин шушы сокны эчәр өчен булса да барыр идем...

Икенче көнне дөньяның җиде могҗизасының берсе булган пирамидалар иле Мисырга юл тоттык. Кай тарафка күз салсаң да – офыкларга барып тоташкан диңгез! Исеме Кызыл булса да, суы җете яшькелт-зәңгәрсу фирүзә төсендә – күзләрне ял иттереп карап торасы килә! Җир шарындагы иң тозлы һәм иң җылы диңгез ул, бер литр суга 42 грамм тоз утыра икән. Суүсемнәрнең чәчәк ату чорында диңгезнең ярга якын урыннары кызарганга, Кызыл диңгез дип аталган дигән фаразлар яши. Аның төбендә 150 дән артык төрдәге, төрле төстәге коралл утраучыклары бар, алар Мисырның милли байлыгы санала. Тикмәгә генә дайвингларның яраткан урынына әверелмәгәндер шул!

Бу – һәркемне тынсыз-өнсез калдырырлык бөек цивилизация, дөнья башланган җир.

Ләкин кеше өчен куркыныч тудыра торган диңгез керпеләре, акулалар, еланнар да аз түгел бу диңгездә.

Корабльдәге диңгез сулы бассейннарда – халык! Кем джакузида, кем кояшта кызына. Биш мең чамасы булган шәһәр халкы өчен нинди мөмкинлекләр тудырылса, биредә дә дөньяның төрле төбәкләреннән җыйналган, төрле телдә сөйләшүче халыкның ихтыяҗын канәгатьләндерерлек һәрнәрсә бар: ресторан, кафе тибындагы буфетлар төнге сәгать икедән иртәнге алтыга хәтле генә тукталып тора. Лайнерда үзебезнең илдән утырган рус телле туристларны очратмадык. Шулай да чит телле халык арасында үзебезне үги итеп тоймадык, татарча-төрекчә аңлашырга тырыштык. Рус телле казакълар белән күрешкәч исә, үзебезне Россиядә, Татарстанда итеп хис иттек

Могҗизалар дөньясында

Мисырның Сохна портына төшкәч, автобус безне пирамидалар дөньясына алып китте. 1990 елда минем бирегә килгәнем бар иде инде. «Татарстан яшьләре»ндә сәяхәтнамә дә бастырган идем. Мисыр пирамидалары турында китаплардан яки интернеттан укып кына әллә ни тәэсирләнеп булмый. Ничә тапкыр барып күрсәң дә, кешенең бөек акылы безнең эрага кадәр 2600, ягъни 4200–4700 еллар элек Гиза калкулыгында тезелеп киткән IV династия фиргавеннәренең мәһабәт пирамидалары серен аңлый алмый.

Иң өлкән Хеопс пирамидасының биеклеге 136 метр. Хеопс кешелек дөньясында иң зур һәйкәлне салып калдырган. Аның мәйданы Римдагы изге Петр соборы, Миландагы Флоренция соборы, Лондондагы Вестминстер сарае һәм Изге Павел соборы урнашкан мәйданнарга бәрабәр. Үзе исән чакта ук төзеткән әлеге пирамидада өзлексез 20 ел буена 300 мең кеше эшләгән. Хеопсның коллары бу әкияттәгедәй корылманы төзү өчен өч миллион данә таш блок җыйнап китергән. Аерым блокларның авырлыгы 30 тоннага җиткән. Әгәр таш блокларны күтәреп кайткан вакытта берәр кол хәле бетеп үлсә, аны пирамиданың нигез буена салганнар. Һәм ул тәнен козгыннар йолыккалап, сөякләрен шакаллар ташып бетергәнче шунда яткан. Меңләгән кешеләр шулай һәлак булган. IV династия хакимлек иткән елларның ахырында халык Хеопсның мумиясен алып, рәхимсез рәвештә юкка чыгарган.



■ Мисыр башкаласы Каһирә янында – уңдырышлы туфраклы Нил елгасы үзәнлекләрендәге комлыкларда – үлем шәһәрләре төзелгән.

Автор фотолары

PRESSA



■ Джосер пирамидасы фиргавеннең 11 кешедән торган гаиләсе өчен махсус төзелеп, җир астында 30 метр тирәнлектә таш табутлар урнаштыру өчен төрбәләр ясалган.



Шул чордан бирле аның җаны тәнен таба алмыйча адашып йөри, имеш.

Пирамиданың нәкъ уртасында фиргавеннең мумиясе тулы зурлыгында сакланырга тиеш булган. Борынгы мисырлылар кешенең үлгәннән соң терелүенә нык ышанганнар. Догалар укыганнан соң, мумияләштерелгән тәннең мәңгелеккә әверелүенә инанганнар. Кеше үлгәч, аның җаны тәненнән аерылып чыга һәм төрле җирләргә сәяхәт кыла. Җан, күмелгән җиргә әйләнеп кайтып, тәнне тапмаса, бу аның өчен авыр хәл булган дип уйлаганнар. Нәкъ шул максат белән Мисыр патшалары үлгәннән соң тәннәрен мумияләштереп куюһәм таш сыннарын җимерелүдән саклау өчен үзләренә төрбә – бина сыман эшләнгән кыйммәтле каберләр төзеткәннәр. Пирамидалар барыннан да ышанычлырак төрбә ролен үтәгән. Аларга үтеп керү юлы нык яшерелгән һәм адаштыргыч булган.

Аларны кайчан һәм нинди максат белән, кем төзегәнлеге турында күптөрле фаразлар яши. Кемнәрдер аны гыйбадәт кылу корылмасы дип атаса, кемдер бу фикерне инкарь итә, чөнки пирамиданың эченә алып керә торган тар һәм тәбәнәк түшәмле коридор булып сузылган баскычлардан күтәрелеп, мумияне урнаштыру мөмкин түгел. Беренче тапкыр бирегә килгәч, әлеге баскычлардан менеп, фиргавен мумиясе ятарга тиешле таш табутны мин дә күргән идем. Буш иде. XIX гасыр башында ук әлеге күмү бүлмәсенә күтәрелгән галимнәр таш табутта мумиянең булмавын ачыклаганнар. Ул пирамида төбендәге җир асты төрбәсендә дә табылмаган.

Икенче пирамиданы әтисе Хеопска хөрмәт йөзеннән, 40 елга соңарып, Хефрен аны бераз кечерәк итеп төзеткән. Аның өслеге шомартып ялтыратылган ташлардан торган. Бераз читтәрәк өченче бөек төрбә – Микерин пирамидасы. Дөньядагы җиде могҗизаның беренчесе буларак тарихка кергән Гиза пирамидалары арасында ул иң кечерәге саналса да, мөгаен, иң тәэсирләндерә торганыдыр. Төзеп бетергәннән соң, коллар, мәрмәр тау битләренә төшеп, үзләре башкарган корылмага шаккатып карап торган, дип сөйлиләр. Сокланырлык шул! Безнең эрага кадәр ничә мең еллар элек Хеопс, Хефрен, Микерин хакимлек иткән чорда ук нинди гаҗәеп могҗиза тудыра алганнар! Бернинди техника, механизм, ташларны кисү, тигезләү, шомарту өчен махсус кораллар булмаган чорда да сылаусыз-цементсыз, таш өстенә таш куеп, алар арасына кәгазь кыстырырлык та ара калдырмыйча төзелгән бит алар! Чиста мәрмәрдән эшләнгән матур плитәләр Асуандагы атаклы таш чыгару урыныннан Нил елгасы буйлап көймәләрдә китерелгән. Ышанасы да килми хәтта! Хәер, дөнья яралганнан бирле өйрәнүләргә дә карамастан, дөреслекне борынгы кешеләр генә түгел, тикшеренеп өйрәнүче фән галимнәре дә белеп бетерә алмый. Бер генә мисал: нәкъ шушы пирамидаларга охшаш, ләкин аларга караганда өч тапкыр зуррак пирамидаларны самолет, корабльләрне үзенә «йота» торган «Бермуд өчпочмагы» дип аталган урында, океан төбендә дә тапканнар түгелме соң? Әлегә кадәр моның серен дә аңлата белүче юк. Бер Аллаһы Тәгаләдән башка! Мисыр пирамидалары өстеннән очканда 1967 елны Израиль самолётының ком чүленә егылып төшү очрагы да булган. Шулай ук хәзерге заманның иң катлаулы электрон аппаратуралары эшчәнлеге бозылуны да күзәткәннәр. Пирамидалар әнә шулай серләр яшергән..

Каһирәдәге тәэсирләр

Гиза пирамидаларын узып, Саккара һәйкәлләренә юнәләбез. Үле Сахара чүленә биредән 15 чакрымлап кына ара кала. Сары ком таулыкларына җиткәч, кыздырылган мич эченә кергән шикелле түгел инде – ни дисәң дә, ноябрь ахыры, 29 градус. Әмма бернинди агач, яшеллек заты юк! Күзләрне сукырайтырлык дәрәҗәдәге сары ком илендә – үлем шәһәре. Тарихтан белүебезчә, менә шушы юллардан фиргавеннәрнең мумияләрен мәңгелек ял урынына илткәннәр. Биредәге иң борынгы баскычлы пирамида III династиягә нигез салучы фиргавен боерыгы буенча



торгызылган. Җир астындагы төрбәләр дә шарсыман гөмбәзләр, биек-биек колонналар белән эшләнгән. Соры, кызыл, кара төстәге мәрмәрдән таш табутлар тезелгән, аларның бәлзәмләнгән үгез гәүдәләре куелган капкачлары 60 шар тонна булган дип сөйлиләр. Таш табутлар, таш төрбәләрнең дивар колонналары төрле төстәге буяулар белән бизәп язылган иероглифлардан, барельефлардан тора.

Туристлар автобуслары килеп туктауга, пирамидалар тирәсендә дөяләр йә ишәкләр җитәкләгән бәдәвиләр үзләренең хезмәтен тәкъдим итә башлый. Матурлап бизәлгән дөяләренә, арбага җигелгән ишәкләренә утыртып йөртеп, фотога төшереп, сувенирлар, яулык-эшләпәләрен сатып акча эшләп калырга тырышалар. Аз гына кызыксыну күрсәтсәң – беттең инде, нәрсә булса да алдыртмыйча туктамаячаклар. Инде тәмам аптыраткач, жәлләп, берсенә сәдака өчен дип 5 доллар биргән идек, өчебезгә дә Мисыр патшабикәсе Нефертити сурәте төшкән сумка тоттырды. Бомж кыяфәтендәгесе туристларны үзе янына бастырып, фотога төшерттерә, акча түләүне таләп итеп йөри. Алар да кызганыч, гаиләләрен туйдырыр өчен акча эшләп йөриләр. Гаиләдә димәктән, Каһирә урамнарында кечкенә балалары белән тротуарда ашап утыручыларны да күрергә туры килде. Моннан 30 еллар элек тә Каһирәдә һәм аның тирәсендә шундый соры, ярым җимерек, тәрәзәтүбәсез йортлар булса, хәзер дә шул икән. Дөрес, шәһәргә керү юлында, ком чүле уртасында йөзләгән игезәкләр төсле биш-алты катлы йортларны, ком тауларын кисеп-ертып төзелгән юлларны да күрдек. Әйе, юлларга сүз әйтә торган түгел – йомырка тәгәрәтерлек!

Хәерчелек аеруча күзгә ташланган урыннар шактый, бигрәк тә ике-өч катлы йортлар тирәсе пычрак. Казандагы Болак суы шикелле каналның ике ягы да буеннан-буена чүплеккә әверелгән: мәңге череми торган пластик шешәләрдән башлап, дөньяда нинди калдык-постык бар – барысы да шунда чыгарып ташланган. Казаныбызда, шөкер, кайсы яктан карасаң да, оҗмах икән ләбаса! Экскаваторлар су төбеннән ләм чумырып алып, аны яр читенә өеп куя. Әлеге ләмне үзбушаткыч автомашиналарга төяп, кешеләрнең йортлары янындагы участокларга илтеп бушаталар һәм шунда нәрсәдер үстерер өчен кулланалар икән. Бөтен җирдә комлык бит, бездәге шикелле, икмәк өстенә ягып ашарлык кара балчык юк шул биредә. Буш яткан җирләр күренми, кая гына күз салсаң да – нииндидер яшел плантацияләр.

Безнең лайнерның чираттагы сәфәргә кузгалыр вакыты җитеп килә. Юлда Сохна порты ягына агылучы фураларның очы-кырые күренми, нәкъ кытай дивары шикелле тезелешкәннәр. Шофёрыбызның полициягә мөрәҗәгать итмичә чарасы калмады. Ниһаять, полиция машинасы озатуында ком чүленнән шактый гына баргач, асфальт юлга чыга алдык. Корабль ике сәгатькә соңарып кузгалды ул кичне. Әгәр экскурсиягә лайнерның үз автобусы белән бармыйча, такси белән китеп соңарган булсак, безне портта калдырып китәргә тиешләр иде. Җиңел сулап, арып-талып, ләкин дөнья күрүдән олы тәэсирләр белән кайтып кердек каютабызга.

Сафага

Бу – Мисырның диңгез порты урнашкан тагын бер шәһәре. Корабль үз вакытында китә алмау сәбәпле, бирегә дә ике сәгатькә соңарып килде. Шунлыктан Луксор, Асуан якларына булган экскурсиягә барырга кыймадык, чөнки ара ерак – бер якка гына өч сәгатьләп юл узасы. Лайнерга өлгермәсәң, Кызыл диңгезнең аргы ягындагы Иорданиягә йөзеп кенә чыгып булмаячак. Минем Асуандагы Элефантин утравында, Луксордагы Патшалар үзәнлегендә һәм башка шундый тарих «чоңгыллары»нда булганым бар иде. Мисырның бик борынгы мәдәни үзәк икәнлегенә һич шигем калмыйча, исем-акылым китеп кайтканымны әле дә хәтерлим. Корабльдән төшкән туристларның бер өлеше таксилар яллап Хургада якларына китте. Ә без Сафага шәһәренә юнәлдек. Шәһәр әллә ни зур түгел, җыйнак кына дүрт-биш катлы йортлардан тора.

Бу шәһәр XVI гасырда ук төрекләр тарафыннан порт буларак төзелгән. Мәккәгә хаҗ кылырга баручыларның корабльгә күченеп утыра торган урыны булган. (90 нчы елларда нәкь менә шушы тирәдә, су асты кыясына юлыгып, хаҗга сәфәр чыгучылар утырган корабльнең төпкә китүен язганнар иде.) Шәһәрдән ерак түгел фиргавеннәр гаване урнашкан. Ул элекке заманнарда фил сөяге, аш тәмләткечләр, кыйммәтле бизәнү әйберләрен кабул итеп алу порты итеп файдаланылган. Сафаганың тагын бер мактанычы – биредә сәламәтләндерү курорты бар. Андагы кап-кара төстәге ком белән буыннар авыртудан һәм псориаздан дәваланырга мөмкин, диләр. Бирегә төрле илләрдән, шул исәптән, Россиядән дә ял итәргә килүчеләр аз түгел.

Мисыр бездә кабатланмас тирән һәм ерак тарихи сәхифәләре белән истә калды. Янә биш йолдызлы отель вазыйфасын үти торган лайнер тормышы белән яшәү мизгелләренә күмелдек. Кичен кемнәрдер театрда концерт-спектакльләрдә утыра, кемдер сәхнәле махсус мәйданчыкларда җыр-музыка тыңлый, кемдер спорт залларында, күңел ачу урыннарында... Без дә яңа танышлар белән иртәгәсе көннең экскурсиясе турында гәпләшәбез. Иртәгә бит – Иордания. Акаба портына төшкәч, кыялар арасындагы атаклы борынгы Петра көтә безне.

«ХАТЫНЫҢ – ИҢ ЯКЫН КЕШЕҢ...»



Айдар ХӘЙРЕТДИНОВ,
галим;
гаилә стажы – 29 ел;
өч бала әтисе.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Бу сорауга җиңел генә җавап биреп булмый. Билгеле бер тормыш тәҗрибәсе туплагач, фикер дә үзгәрәдер. Мин үзем күбрәк буй-сынга күз төшерәм, әмма булачак хатынымның иң элек... холкына игътибар иттем. Купеда, тар җирдә башкача булмагандыр да – без поездда таныштык.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Хатын-кызга хас булган кимчелекләрнең барысын да диярлек кичерергә мөмкин. Гомумән, тормыш иптәшен сайлаганда үзең кичерә алырлык җитешсезлекләргә ия булганын сайларга кирәк. Сайладың икән, түз, чөнки ул кимчелекләр аның өчен кимчелек түгел – яшәү рәвеше. Яшәү рәвеше өчен кешене гаепләп булмый бит инде...

3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Иренең кадерен белмәвен. Мәсәлән, ир тырышып-тырмашып, хәрамләшмичә, башкаларның хакына кермичә тормыш дилбегәсен тарта, җаваплылыкны үз өстеннән төшерми: ир-ат буларак, кулыннан килгәннең барысын да эшли. Ә хатын-кыз шуңа бәя бирә алмаса, «тегесе болай түгел, монысы алай түгел», дип, иренең башына тукып торса, чыраен сытып, көйсезләнеп, иреннән канәгатьсезлеген гадәткә әйләндерсә... Андыйны йә ташлап кит, йә...

Хыянәт дигәндә исә... Ир-атлар заводта җыелган роботлар түгел бит, бу сорауга җавапта һәркайсыбызның үз фәлсәфәсе, тормышка мөнәсәбәте чагылачак. Минемчә, хыянәтне кичерергә була. Әгәр хатын-кыз, күтәренеп, үзе чыгып китмәсә, билгеле... Ир-ат хатынын ярата икән, нинди хыянәт булса да, кичерә ала. Аллаһ та ширектән кала барлык гөнаһларны кичерә, кичермәс өчен без кем булдык әле? Хыянәттән тыш, тагын бер бәла бар: кайчак ир үзенең башында туган уйдырмаларга үзен үзе ышандырып, хатынының тормышын җәһәннәмгә әйләндерә – көнләшә. Ә хатыны, чынлыкта, хыянәт итми – уенда да юк. Сүземне дәвам итәр өчен, кузгалтылган мәсьәләнең даирәсен бераз киңәйтәсем килә: Без татар, мөселман буларак, азмы-күпме ислам хөкемнәрен дә исәпкә алып эш итсәк, дөресрәк булыр иде. Бу күзлектән караганда хыянәт нәрсә ул? Шәригать буенча, бәяләмә бер: әгәр хатын-кыз чит ир белән якынлык кылса, һәм бу хәлне дүрт кеше – дүрт шаһит күреп торса, аннан шәригать хөкемханәсендә шәһадәт кылып: «Без ул хатынның зина кылганын күрдек», – дисә, шул очракта гына бу вакыйганы чын мәгънәсендә хыянәт дип атап була. Әмма: «Юк, хыянәт итмәдем!» – дип, хатын судны алдаса да, бу гөнаһ өчен җаваплылыкны үз өстенә алуын һәм хөкемне Аллаһның үзенә тапшыруын аңларга тиеш.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Була ала, әлбәттә. Иренең һәм, әлбәттә, хатынның рухи сыйфатларыннан, акыллары дәрәҗәсеннән, әдәп-әхлакларыннан тора бу. Әгәр бик примитив кешеләр икән – дус була алмыйлардыр, рухи үсешләре билгеле бер дәрәҗәгә күтәрелсә – дус булырга мөмкиннәр.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Поезд купесында танышканны әйткән идем инде. Эш сәфәре иде ул минем. Шунда ук: «Бу – минем кеше», – дип уйлаганымны хәтерлим: күңел йә тартыла, йә юк инде ул. Аннары без икенче тапкыр очраклы рәвештә генә күрештек... Укыганда бер укытучыбыз: «Безне хатын-кызлар сайлый», – дигән иде. Ягъни хатын-кыз үзенә игътибар күрсәткән ир-атны кабул итсә, якын күрсә генә гаилә оешырга мөмкин, юк икән – ир-ат башын бәреп ярса да, бернишли алмый... Ул чакта укытучым белән эчтән генә ризалашмаган идем, яши-яши аның хаклы булуын аңладым. Элекке заманнарда кызларны ирексезләп яратмаган кешесенә дә биргәннәр. Шуңа күрә хәзерге вазгыятьне күпкә дөресрәк дип саныйм: ир-ат та, хатын-кыз да танышуда, мөнәсәбәтләр коруда ирекле. Әмма тормышның билгеле бер өлкәләрендә беренчелек хатын-кызда булырга тиеш: йортны багу, аны тәртиптә тоту, бала-чагаларны тәрбияләү... Бу беренчелек хәтта ислам динендә дә чагыла. Мәсәлән, никах укыганда ризалыкны беренче итеп кәләштән сорау шушыны күздә тота, ягъни хатын-кыз ире була-

чак кешегә барырга ризалыгын гына түгел, яңа гаиләнең хуҗасы, бикәсе булырга ризалыгын да игълан итә. Булачак тормыш юлдашым белән исә берничә ай очраштык. Тәкъдим ясаганда һичнинди романтик, пафослы сүзләр әйтмәдем – урамда барганда: «Миңа чыгасыңмы?» – дип сорадым. Чәчәк тә бирмәдем, алдына да тезләнмәдем.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр, шулаймы?

– Минем очракта алай түгел. Әмма булачак хатынның үзең белән бер даирәдән, ягъни, бер иҗтимагый катламнан булуы мөһимрәк. Мәсәлән, минем әти-әнием гади эшчеләр иде, шуңа күрә әллә нинди югары катламнардан кызлар эзләмәдем: бер-береңне аңламау ихтималы зураер иде. Үзеңә тиңнәр арасыннан сайларга кирәк.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Мин үзем андый хәлдә түгел, шуңа күрә белмим, киңәш тә бирә алмам... Пәйгамбәребез (с.г.в.) беренче тапкыр үзеннән күпкә бай хатынга өйләнә. Хәдичә тирән акыллы хикмәт иясе була. Андыйлар элек тә сирәк очраган, хәзер дә шулай. Никадәр хәлле, абруйлы, дәрәҗәле булса да, ул үзеннән 15 яшькә кече егетнең яхшы сыйфатларын – тугрылыгын, сүзендә торуын, гаделлеген күрә алган. Иренә пәйгамбәрлек иңгәч, иң авыр вакытта аңа терәк булган – беренче булып ислам динен кабул иткән. Шуңа күрә бу мәсьәләдә эшнең асылы акчада, кемнең күпме эш хакы алуында түгел.

8 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Көтмим, андый вакытлар үтте инде. Ә кызларга әчми-тартмый торган, әдәпле, йомшак күңелле егетләргә игътибар итәргә тәкъдим итәр идем. Тагын – ир-атның пөхтәлегенә. Хатын-кызлардан ишеткәнем бар: «Без, беренче чиратта, ир-атның аяк киеменә карыйбыз, аннары кием-салымының пөхтәлегенә, хәтта ыспайлыгына», – диләр. Ир-атның акылына игътибар итүче ханымнар да бар. Әмма бу сыйфатка бәя бирү өчен хатын-кыз үзе дә акыллы булырга тиеш.

9 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Кешесенә караптыр. Кайбер ир-атлар бар: буе метр ярым гына, ә мин-минлеге Каф тавы кадәр. Үзенең тапкырлыгы, кыюлыгы, тәвәккәллеге белән ул теләсә кайсы хатын-кызның йөрәген яуларга мөмкин. Күңел бит хатын-кызның һәрберсендә бар... Мин үзем, мәсәлән, чибәр хатын-кыз белән мөнәсәбәт кормас идем. Юрганыңа карап аяк сузарга кирәк. «Чибәр хатын – күршенеке була», диләр. Андый хатыннарга өйләнеп, алардан колак каккан ирләр юк түгел. Гел игътибар үзәгендә булганга күрә, татлы сүзләрдән, ир-атларның карашыннан чибәр ханымның күңеле эреп китәргә бик мөмкин... Аннан андыйларның таләпләре дә югары буладыр. Үз көче белән дөнья көткән ир-ат аның бөтен ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмаска да мөмкин. «Чибәрлек туйда гына кирәк», дип, юкка гына әйтелми.

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның берберсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Әйе, ике Галәмнән! Бер очрак искә төште. Байтактан булган хәл инде. Телевизордан дәүләт җитәкчеләренең берсе сөйли. Нәрсә беләндер кызыксындырды – бирелеп тыңлыйм. Һәм ул үзенең чыгышын тәмамлар алдыннан, хатыным ниндидер сорау бирде дә, соңгы җөмләләрен ишетми калдым. «Бүлдердең, әһәмиятле әйбер сөйли иде бит, син тыңламадыңмыни?» – дим. Миңа кинәт кызык булып китте. «Янымда утырдың бит, әйт әле, нәрсә турында сөйләде ул?» – дим. Ә ул миңа сорау бирә: «Ә менә син ул таккан галстукның төсен хәтерлисеңме?» – ди. Галстукның төсенә игътибар итү уемда да юк иде... Ә ул күргән, «мыегына чорнап», аның тышкы кыяфәтенә үзенчә бәя биреп утырган булып чыга!

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Мондый тарткалашу башланса, ир-ат фикеренең яки ниятенең төбендә ни ятканын аңлатып карарга тиеш, минемчә. Тик бу тарткалашу берәр эшкә кагылса, ир кеше үзенекен итәргә тиеш. Нигәме? Әгәр хатын сүзенә күнеп, ул эшне эшләмәсә һәм нәтиҗәдә уңышсызлыкка тарыса, хатын-кыз аңа: «Нишләп эшләмәдең?» – диячәк. Ир-атның табигый сурәттә: «Соң син үзең эшләмәскә куштың бит!» – дип аптыравына каршы, тегесе: «Син – ир кеше, үзеңнекен итәргә тиеш идең», – дип җавап бирәчәк... Әлбәттә, бу гел үзеңчә генә эшләргә дигән сүз түгел, хатының белән киңәшләшү кирәк. Киңәшле эш таркалмас.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора.

– Сорауда «кырын ятып тора» диелгән. Монысы мөгез чыгару билгесе, димәк, нәрсәгә карата булса да каршылыгын, ризасызлыгын белдерергә маташа, протест игълан итәдер. Бу хәлнең сәбәбен ачыкларга кирәк. Тик аны ач карынга эшләү дөрес булмаганга күрә, башта нәрсә дә булса әмәлләп, тамагыңны туйдыр, аннары кырын ятуының сәбәбен тап.

13 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Гадәттә, бер-береңә нәрсә кирәген беләсең, белмәсәң – сорыйсың. Инде бүләк эзләп баш ватасың килмәсә, «Үзеңә кирәк нәрсәне ал», дип, акча тоттыр. «Бергәләп сайлыйк» кына димәсен... Сайлашкан бар: кибеткә керәсең икән, әйтик, зур бер сәүдә үзәгенә – Казанда андыйлар күп – ул аны әйләнеп-айкап, актарып чыга да (артыннан ияреп йөреп «бүләк сайлашкан» иренең алҗып бетүендә эше юк!): «Монда бер әйбер юк», – ди. Шаккатып: «Соң кибетләр шыплап тулган, ничек инде бернәрсә дә булмасын?!» – дигәнем бар... Бүләк алу өчен талант кирәк.

Тулысынча укыгыз »





СОРАУ—ҖАВАП



Сорауларга Республика клиник хастаханәсенең акушер-гинекологы Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА җавап бирә.

? Еш кына молочница гөмбәсе борчый. Табиб миңа гына түгел, иремә дә дәваланырга кирәк, диде. Ләкин ирем риза түгел, мине берни борчымый, ди. Дәваланмаса, нәрсәгә китерергә мөмкин бу?

Молочница йә кандидоз – кандида гөмбәсе китереп чыгара торган авыру. Ирләрдә дә, хатын-кызларда да булырга мөмкин ул. Гормональ фоны һәм анатомик төзелеше үзенчәлекле булу сәбәпле, хатын-кызларда кандидоз ешрак очрый. Молочница җенси юл белән күчмәсә дә, ирегезнең дә дәвалануы зарур. Ирләрдә кандидозның симптомнары булмый диярлек. Бары тик иммунитет какшау йә хроник авырулар аркасында гына тышкы җенси органнарның ялкынсынуы, кызышуы, кычытуы аша сизелә башларга мөмкин. Аны вакытында дәваламасаң, бәвел бүлеп чыгару процессына зыян килә, сизгерлек кими. Бу, үз чиратында, җенси яктан канәгатьсезлеккә китерә. Авыру азган аерым очраклар бөерләр, баш мие сүрүе, йөрәкнең эчке катламы ялкынсынуына китерергә мөмкин.

? Хатын-кызга цистит белән кайсы белгечкә мөрәҗәгать итәсе – урологкамы, гинекологкамы?

Цистит симптомы булган күпчелек хатын-кыз гинекологка мөрәҗәгать итә. Әмма цистит ул бәвел куыгы авыруы, аны уролог дәвалый. Хатын-кызларны да, ирләрне дә. Шуннан соң гына, хатын-кызның җенси органнары үзенчәлеген истә тотып, уролог гинекологка җибәрергә мөмкин. Аннары табиблар дәвалауны бергә алып бара. Кайбер очракларда терапиягә башка табиблар да кушыла.

? Күрем ун көннән артык бара. Соңгы биш көнендә бераз гына буялуга кала, ләкин барыбер шул ун көн булмыйча туктамый. Сәбәбе нидә булырга мөмкин?

Гадәттә менструация 3–8 көн дәвам итә. Шуннан озаккарак сузылуы – гормональ фоны тотрыкланырга өлгермәгән яшь кызлар һәм климакс чорындагы хатын-кызлар өчен норма дип санала. Шушы категориягә кермәсәгез, патологияне кисәтү өчен гинекологик тикшеренү узарга киңәш ителә. Еш кына аналык патологиясе белән бәйле булырга мөмкин бу (эндометрий гиперплазиясе, миома, аденомиоз, көчле эндометрит). Шулай ук гормональ фон бозылу да йогынты ясамыйча калмый. Аның сәбәпләре күптөрле – артык көчәнү, стресс, дөрес тукланмау, кисәк ябыгу, авырлыкны артык тиз җыю, кайбер препаратларны озак куллану. Кайбер очракта гормональ препаратлар куллану да менструациянең озак баруына китерергә мөмкин. Кайчак канның оешу системасы өчен кулланган препаратлар да йогынты ясый. Шуңа күрә гинекологик тикшеренү узарга кирәк.

Республика клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Валерия Белова ярдәме белән әзерләнде.

Кадерле укучылар!
«Сорау–җавап» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Үзегезнең һәм балаларыгызның сәламәтлегенә кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.

Фото: ru.freepik.com



Сорауларга Республика балалар клиник хастаханәсенең отоларингологы Ләйсән АЗИЗОВА җавап бирә

Вирус инфекциясе йоктырып озак авырганнан соң баланың борыныннан авыр ис килеп калды. Томау төшүе дә бар. Бу нәрсә булырга мөмкин?

Кечкенә балалар вирус инфекциясе белән еш авырый. Вирус кичергән арада иммунитет кими, бактериаль инфекция кушыла. Борында эрен җыела. Шуның аркасында борыннан ис килү, борын томалануы борчый.

Грипп белән авырганнан соң улыбыз начар ишетә башлады. Кечкенә чакта йоктырган вируслар колакка зыян сала, диләр. Хәтта бөтенләй ишетмәслек хәлгә дә китерергә мөмкин дип ишеттем. Ничек шул хәлгә җиткермәскә икән?

Әйе, чыннан да, вируслар нерв тамырларына начар тәэсир итәргә мөмкин. Грипп вирусын игътибарга алсак, ул нейротропик сәләткә ия. Ягъни нейроннарны (нерв күзәнәкләрен) «агулый», алар, вирус йоктырып, төп функцияләрен начар үти башлый. Бу ишетү нервларына да кагыла. Шуңа күрә грипп белән авырган кешенең ишетү сәләте кимергә мөмкин. Әгәр дә балагызда шундый симптом барлыкка килсә, аны сурдологка күрсәтергә киңәш итәм.

Бәләкәй чакта бик еш ангина белән авырдым. Әлеге авыру балага нәселдән күчәргә мөмкинме? Аңа профилактик чаралар уздыру кирәкме?

Хроник тамак авырулары нәселдән килә дип уйлау бик үк дөрес түгел. Локаль анатомия, иммунитетның үзенчәлекләре әти-әнидән балага күчәргә мөмкин. Алар аркасында инде хроник процесс формалаша ала.

Профилактика чаралары, әлбәттә, кирәк, чөнки күп очракта дәвалауга караганда авыруны булдырмау кулайрак. Хроник тамак авырулары профилактикасы чаралары: сәламәт яшәү рәвеше алып бару, организмны чыныктыру, витаминнарга һәм микроэлементларга бай туклану, инфекцияне вакытында дәвалау.

Кызыбызга 1 яшь. Колак эчен чистартырга кирәклеген күрәм, ләкин куркам. Бәләкәй баланың колагын ничек чистартырга?

Әлбәттә, кечкенә балаларның да колак эчендә колак сагызы (сера) җыела. Аны мамык таякчыклар ярдәмендә казымаска киңәш ителә. Шулай ук колак эченә очлы предметлар кертү катгый тыела.

Әгәр дә колак сагызы күп икән, баланың башын югач, кайнаган су белән чылатылган мамык диск яки тампон ярдәмендә колак яфрагының эчен һәм колак артын сөртәләр. Кабатлап узыйк – колак эченә керергә ярамый!

Нәниләргә күчтәнәч!
Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

КУНАК БУЛСАҢ, ТЫЙНАК БУЛ

Татар халкы бик кунакчыл. Ул кунакларны еш җыю белән бергә, үзе дә кунакка йөрешә, аның табыны мул, ризыклары да күп төрле була. Кунакта булган вакыт сезнең өчен дә, хуҗалар өчен дә уңай эмоцияләр белән генә истә калсын өчен, әдәп кагыйдәләрен белү һәм үтәү зарур. Шуны онытмыйк, хөрмәт төбе – әдәп. Күренекле аш-су остасы, кулинария буенча күп китаплар авторы, татар кухнясының «атасы» Юныс ӘХМӘТҖАНОВ татар ашларын популярлаштырудан тыш, кунак булганда, өстәл артында утырганда әдәп кагыйдәләрен дә барлап, өйрәнеп халыкка җиткергән. Аларны сезгә тәкъдим итәбез. Искә төшереп, белмәгәннәрен хәтердә калдырыгыз. Әдәпле кеше – солтан, әдәпсезнең бите олтан, диләр бит.

Аш өстәле янында үз-үзеңне тотуның өч кагыйдәсе турында сөйләргә мөмкин. Беренчесе – кешенең үз-үзен тота белүе, икенчесе – дөрес итеп ашау, өченчесе – пөхтәлек саклау.

Чакыргач, кунак беркайчан да соңга калмыйча, вакытында килергә тиеш. «Ашка килсәң – элек кил, үз кадереңне белеп кил», – диләр.

Өйгә килеп кергәч, кунак тәртип белән генә чишенә, аяк киемен, өс-башын теләсә кайда түгел, бәлки, тиз генә киенерлек уңайлы урынга куя. Үзенең пөхтәлеген тикшерә, аннары алданрак килгәннәр белән күрешеп чыга. Хатын-кыз үзе кул биреп күрешә.

Соңга калып килгән кеше булса, табын янында аның белән сузыла-сузыла кулыңны биреп күрешмә. Башыңны кагып кына исәнләшү бик җиткән.

Өстәл артында төз утырсаң, күршеңне дә борчымассың. Шуны да истә тот: күршең белән сөйләшергә теләсәң, башка кешегә аркаң белән борылма, терсәкләреңне өстәлгә куйма, колакка пышылдап утырма. Мәҗлестә катнашучылар – бербөтен коллектив.

**Кузгалырга туры килсә, күршеңнән рөхсәт сора.
Кунак булсаң, тыйнак бул: сыйланасың икән – буеңа сеңдер.
Аша, эч, уйна, көл, мәҗлестә сөйләшкән – шунда калсын.**

Үзеңнең эшең яки үзең турында гына сөйләү белән мавыкма. Сөйләшә торган сүзнең эчтәлеге һәркемне диярлек кызыксындырырлык булсын.

Алданрак кайтып китәргә туры килсә, хуҗадан гына рөхсәт сорау да җитә, бу турыда барлык кунакларга да белдерү шарт түгел. Чыгып киткәндә сине күрүчеләр белән кул сузып саубуллашуның кирәге юк, бу очракта баш кагып кына куялар.

Ашыккан – ашка пешкән, диләр. Кабаланып, ашык-пошык, ашама. Авызыңа азыкны күп итеп тутырма, ашаганда сөйләшмә, авызыңны чәпелдәтмә, битеңне һәм иягеңне тастымал белән сөртмә, аны иреneңне җиңелчә сөртеп алу өчен генә куллан.

Ашап бетергәч, чәнечкене һәм пычакны тәлинкәгә аркылы куялар, бу – кунакның башка ашарга теләмәвен күрсәтә.

Чәйне иң элек – өлкән яшьтәге хатын-кызларга, аннары ирләргә бирәләр. Зурлар мәҗлесенә балалар белән йөрергә киңәш ителми.

Ир-ат колагына гына әйтелә торган киңәш тә бар. Әгәр янәшә-тирәндә хатын-кыз утырса, аңа аеруча игътибарлы бул. Хатын-кызның кулы җитмәгән җирдән (әгәр сораса) ул теләгән ризыкны алып бир. Бу – ир-атның ни дәрәҗәдә тәрбияле һәм, димәк, культуралы булуын күрсәтә.

ТОМАУ ТӨШҮДӘН ПРОФИЛАКТИКА

Томау төшү белән күпләр интегә. Бигрәк тә кыш айларында. Вакытында дәваламасаң, ул гайморитка ук әйләнергә мөмкин. Массаж ярдәмендә томаулауның беренче билгеләрен җиңеләйтеп була. Ул гаймориттан да профилактика булып санала. Борын куышлыгын массажлау сулыш алуны җиңеләйтә, кан тамырларындагы циркуляцияне яхшырта, алмашу процессларын активлаштыра. «Берничә массаж хәрәкәте шундук хәлегезне җиңеләйтәчәк. Аның өчен әллә ни күп вакыт та кирәкми, кирәк-кирәкмәскә дару да кулланмассыз», – ди массажист Ләйсән САБИТОВА.

- Имән бармаклар белән спираль рәвешендә массажлый-массажлый, борын яфракларыннан алып күзнең эчке почмагына кадәр менәбез.
- Борын сыртын чеметкәләп, буйдан-буйга тартабыз.
- Бер кул белән борын яфракларын, икенче кул белән өске ирен өстендәге тирене тотып, әкрен генә селкеткәләп, «ябышкан» урыннарны «кубарып» чыгабыз. Бу фиброзлардан файдалы.
- Имән бармаклар белән спираль рәвешендә массажлап, борын яфракларыннан өскә таба менәбез. Күз төбен узып, каш асты, чигә буйлап массажлап, колакка таба барабыз. Әлеге күнегүне ясаганда ук борын аша сулыш алу җиңеләйгәнен сизәрсез.
- Бер кул бармаклары белән борын сөяген тотабыз, икенче кул бармаклары белән борын кырыеннан чигәгә таба сыпырабыз. Бу лимфа йөреше өчен файдалы.
- Бер кул бармаклары белән – маңгай сөяген, икенчесе белән борын сөяге башланган урыннарны тотабыз да капма-каршы якка тартабыз.
- Күнегүләрдән соң берберсенә ышкып уч төбен җылытып, борын тирәсенә куеп торабыз.

Бу күнегүләр томау төшкәндә генә түгел, борын тирәсендәге тирән җыерчыклар белән көрәшкәндә дә файдалы. Массажны көн аралаш косметик май белән ясагыз. Матур һәм сәламәт булыгыз!



QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Калҗа

Халкыбызның төрле өлкәләрдә, шәһәр һәм авылларда сакланып калган борынгы рецептларын барлауны бу санproblemыбызда да дәвам итәбез. Калҗа да татар халкының борынгы ризыкларыннан санала. Калҗа әзерләү серләрен безгә Әлки районы Түбән Әлки авылында туып-үскән Рамилә ЗАКИРОВА өйрәтә. Исегездә булса, ул безнең белән пәхләвә пешерү серләрен дә уртаклашкан иде. Элегрәк чорларда район үзәге булып торган Түбән Әлки – урта мәктәбе, балалар бакчасы, мәчете, бетон, май заводлары гөрләп эшләп торган зур авыл ул. «Авылның яшәрүендә, яшьләрнең авылда төпләнеп калуында эшмәкәр Дамир һәм Альберт Шәйхетдиновларның өлеше зур», – ди сәхифәбезнең бүгенге кунагы. Бәйрәм һәм туй табыннарына гына куелучы әлеге калҗаны әзерләү нечкәлекләрен Рамилә әтисенең туганы Рузалия Әхмәтовадан отып алган. Рузалия ханым – атаклы аш-су остасы Юныс Әхмәтҗановның шәкерте, 1980 елда Мәскәүдә узган җәйге Олимпиада кунакларын сыйлауда ул да катнашкан. Борынгырак чорларда, әлбәттә, калҗа бераз гына үзгәрәк пешерелгән. Аш тәмләткечләр ассортиментының киңәюе әлеге рецептка да йогынты ясамый калмаган. Хәзер аны әзерләгәндә яшел үләннәр дә кулланалар. Артык катлаулы булмаса да, калҗа пешерү өчен түземлек һәм вакыт сорала.

Кирәк

600 г сарык яки терлекнең юка карын ите. (Әлки ягында аны алъяпма дип йөртәләр) / түбәнчә тоз-борыч / ярты чәй кашыгы аджика (яратсагыз) / 1 чәй кашыгы шикәр комы / 3 аш кашыгы аш серкәсе / 3 тырнак сарымсак / 2-3 бал кашыгы сарымсак сабакларыннан ясалган яшел паста (мәҗбүри түгел) / бер тотам укроп, петрушка, кинза (ул аеруча тәм бирә) / фольга.



Борынгы рецепт:
Карын итенә тоз-борыч, аш серкәсе сибеп, өч-дүрт сәгатькә салкын урынга куярга. Кабаттан иткә бераз тоз сибеп, уылган сарымсак ышкырга һәм рулет итеп бөтереп, җеп белән урап бәйләргә. Майлы табада рулетның һәр ягы да кызарганчы кыздырырга. Сулы кәстрүлгә салып, бер сәгать пешерергә. Шулпадан алып, суытырга.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия







Эш барышы

■ Үләннәрне, сарымсакны ваклап, аджика, сарымсак сабаклары пастасы, шикәр комы, аш серкәсе салып, бутыйбыз. Калҗаны сарык итеннән әзерләсәгез, серкәне күбрәк тә куша аласыз, ул итнең үзенчәлекле исен ала.

■ Карын итен артык майларыннан, элпәләреннән арындырып, 35 кә 25 см чамасы турыпочмаклык итеп кисәбез. Тоташ кисәк булмаса, өлешләрдән дә эшләргә мөмкин.

■ Иткә тоз, борыч сибәбез. Кул белән суккалап, тозны иткә сеңдерәбез.







■ Ит өстенә әзер соусны ягып, рулет сыман бөтереп төрәбез.

■ Билгеле, борынгы чорда калҗаны фольгага төреп пешермәгәннәр. Ләкин фольгага төреп пешерсәң, калҗа тагын да йомшаграк, сусылрак була. Итне берничә кат фольгага төреп, бер тәүлеккә суыткычка куеп торабыз.

■ Калҗа кайнар мичкә куелган сулы табада ике сәгать пешә. Су кайнап чыкканчы, температураны 200 градуста тотабыз, аннары 180 градуска киметәбез. Таба төбенә суны гел өстәп торабыз, ул кайнап бетәргә тиеш түгел.

■ Пешкән калҗаны табадан алып, фольгада килеш суытабыз. Аннары 1 см калынлыгында телемләп турыйбыз. Табынга салкын кабымлык итеп тә, кайнарлатып, гарнир белән дә бирергә мөмкин.
Тәмле булсын!



МАТУРЛЫК һәм ЛӘЗЗӘТ ОСТАХАНӘСЕ



Һәр хатын-кыз чибәр, стильле булып күренергә тели. Моның өчен матур итеп киенеп йөрү генә җитми, гүзәл затлар үз-үзен карарга, тәрбияләргә дә тиеш. Хәзер инде күпләребез матурлык салоннарына йөреп, үзен белгечнең ышанычлы кулларына тапшыра. Маникюр, педикюр, прическа, битне карау... Безнең белән килешерсез, матурлык процедураларыннан соң үзегезне бөтенләй башкача хис итәрсез. Матурлык салоннары – үзгәреш урыннары. Анда осталар могҗиза тудыра. «Melek» остаханәсендә осталар һәр хатын-кыздан матурлык алиһәсе ясый. Шуңа да ул матурлык һәм ләззәт урыны дип атала. Остаханәдә исә белгечләрнең иң-иңнәре эшли. «Melek» хуҗабикәсе Раилә ЗАРИПОВА «Сөембикә» укучылары өчен генә кышын битне тәрбияләү буенча шәхси алымнары белән бүлешә.

Кышкы чорда биткә ике тапкыр күбрәк игътибар сорала, чөнки һава температурасы үзгәреп тора, җылылык радиаторлары бинадагы һаваны корыта, урамда салкын җил... Болар барысы да тирене стрësска китерә. Шуңа күрә һәр көнне иртә һәм кичен битегезне карау буенча берничә этапны үтәргә кирәк.

1. **Чистарту.** Тирене әзерләү буенча төп этап бу. Моның өчен мицелляр су, пенка йә юыну өчен крем-гель кулланыгыз.
2. **Битнең тонусын күтәрү.** Битне чистартканнан соң тоник сөртегез. Ул бит тиресен тагын да ныграк чистартачак.
3. **Битлек ясау.** Тукландыра һәм дымландыра торган битлекләр кулланыгыз. Тукымадан ясалган битлекләр киңәш итә белгеч. Бит тиресе сизгер булганнарга мондый битлекләр бигрәк тә туры килә.
4. **Тәрбия.** Бу этапта, гадәттә, гиалурон кислотасы белән сыворотка кулланалар. Үзегезнең яраткан кремыгызны сөртсәгез дә була.
5. **Күз тирәсенә крем йә гель сөртү.** Күз карашыгызны яшь килеш саклыйсыгыз килә икән, бу этапка бармак аркылы карамагыз. Күз тирәсендәге тире бик юка, шуңа әлеге урыннар өчен махсус кремнарны иртән һәм кичен кулланыгыз.

«Бу этапларны берсен дә калдырмыйча һәр көн эшләсәгез, битегез сезгә рәхмәт әйтер», – ди Раилә. Тик берсен дә төшереп калдырмау шарт! Остадан тагын бер лайфхак: «Битнең бөтен төре өчен» дип язылган кремнарны кулланмагыз. Бит тиресенә индивидуаль хасият кирәк.

Битегезгә профессиональ тәрбия үткәрергә дә телисезме? «Melek» остаханәсендә сезне тылсымчы косметологлар көтә. Остаханәдә бит тиресе картаюны профилактикалау һәм аны яшәртү буенча уникаль тәрбия программалары булдырылган. Битегезне профессиональ күзлектән караганнан соң нәкъ менә сезгә нинди процедура үтәргә кирәклеген киңәш итәрләр. Ә алар төрле. «Детокс терапия»се чистартуга, бит тиресе микроциркуляциясен яхшыртуга юнәлдерелгән. «Тиз арада яшәрү» йә «G4 Яшьлек эликсир»ы алҗыган, сусызланган тирегә туры килә. «Антистресс» – битне көчле дымландыру программасы. «Кислород белән баету» процедурасы тире күзәнәкләрен кислород белән баета. «Ботокс эффекты» матурлык инъекцияләреннән башка гына битне яшәртә. Күз тиресе өчен дә махсус программа бар. Һәр программада тәрбия буенча профессиональ косметика куллану һәм массаж каралган.

Казан шәһәре, Пушкин урамы, 12 (цоколь катта) адресы буенча урнашкан «Melek» остаханәсендә косметологлар гына түгел, башка матурлык феялары да сезне көтә. Остаханәдә маникюр, педикюр (хәләл матурлык процедурасы сораучылар өчен япон маникюры), күз керфекләрен ламинатлаштыру, прическа, макияж, массаж ясатырга да була. Остаханәгә барганчы 89270346559 номеры буенча алдан язылыгыз.



Студиядә шулай ук тәрбия процедураларына сертификатлар да сатып алырга мөмкин. Якыннарыгыз өчен ул менә дигән бүләк булачак.

Остаханәдә осталар могҗиза тудырганнан соң кәефегез, үзбәягез күтәрелеп китәр. Яшәү энергиягез артып, таулар күчерергә әзер булганыгызны тоярсыз. Көзгедәге чагылышыгыздан, һичшиксез, ләззәт алырсыз.

Реклама

тест: педантлык хасмы сезгә?

Педантлыкка безнең мөнәсәбәт төрлечә. Бер яктан ул – төгәллек, җаваплылык. Икенче яктан – вакчыллык, кабул ителгән нормалардан һич кенә дә читкә тайпылмау. Әлеге тестны узып, сез үзегездәге педантлык дәрәҗәсен ачыклый аласыз. Сорауларга «әйе» яки «юк» дип җавап бирегез.

1. Акча янчыгыгызга купюраларны үсү тәртибендә салып, бу тәртипне сакларга тырышасызмы?

2. Зур җаваплылык таләп ителгән эшләр белән шөгыльләнергә яратасызмы?

3. Башка кешеләрне бер-берләренә тиешле дәрәҗәдә таләпчән түгелләр дип саныйсызмы?

4. Өстәлгә кыек җәелгән эскәтер яки тигез итеп куелмаган аяк киемнәре эчегезне пошырып, тизрәк шуны дөресләп куясыгыз киләме?

5. Күп көч сорый торган кара эшне дә яраткан эшегез шикелле үк җентекләп һәм ашыкмыйча башкарасызмы?

6. Көне буена берәр проблема яки алдагы көн турында уйлап йөрсәгез, кичтән тиз генә йокыга китә аласызмы?

7. Өйдә һәр әйбернең үз урынында ятуына зур игътибар бирәсезме?

8. Берәр эшне эшләп бетерми яки үзегез теләгәнчә тәртип урнаштырмый торып, эштән яисә өйдән чыгып китәсезме?

9. Йокларга ятар яки өйдән чыгып китәр алдыннан утлар сүнгәнме, краннар ябылганмы дип тикшереп чыга торган гадәтегез бармы?

10. Чәй ясаганда чынаякның кырыена кадәр тутырып ясыйсызмы?

11. Автобуста барганда кинәт кемнедер кычкырып ачулану (уйдагы кешене) яки күз күрмәгән якка чыгып китәсе килү кебек бәйләнчек идеяләр буламы сезнең?

12. Көндәлек планнар төзергә яратмыйсыз, кирәкле эшне болай да онытмыйм дип санйсызмы?

13. Берәрсенең эшен яратмыйча, аны куып җибәреп, үзегезнең яхшырак итеп эшлисе килгән чаклар буламы?

14. Озаклап, бөртекләп эшли торган эш сезне тынычландырып, проблемаларны онытып торырга булышамы?

Балларны саныйбыз.
1, 3, 4, 5, 6, 7, 9, 10, 11, 13, 14 нче сорауларга «әйе» дип җавап бирсәгез, һәрберсенә – 1 балл;
2, 8, 12 нче сорауларга «юк» дип җавап биргән булсагыз, шулай ук 1 балл куеп чыгыгыз.

0–4 балл. Сезгә педантлык бөтенләй хас түгел дип әйтерлек. Сез төгәллек түгел, ә тизлек яклы. Эшне тиз һәм көч түкми башкарасыз. Вак-төяккә игътибар итмисез. Гадәттә, иҗади, фантазиягә бай кешеләр шундый була. Кәеф юклыкка сылтап, мөһим эшләрне дә читкә этәрергә мөмкинсез. Эшнең сыйфатына күбрәк игътибар бирергә тырышыгыз.

5–9 балл. Сездә педантлык дәрәҗәсе уртача. Сезгә эш тиз дә, сыйфатлы да эшләнсен. Вакчыллану кебек гадәтегез юк, ләкин пөхтәлекне яратасыз. Үзегезгә бирелгән эшне җиренә җиткереп башкарасыз, килеп җитмәгән җирләренә чама белән күз дә йома аласыз.

10–14 балл. Сез – педант. Иң төп сыйфатларыгыз – гаделлек, төгәллек, җаваплылык. Ләкин артык вакчылланасыз, барлык кагыйдәләрне сакларга тырышасыз. Эшне сыйфатлы итеп башкару – яхшы нәрсә, ләкин сез моңа артык күп көч түгәсез.

йолдызнамә март

Кучкар. Авыр энергетикалы, мәшәкатьле ай. Бик игътибарлы булуны таләп итә, хаталану ихтималы зур. Ә менә шәхси тормышта көтелмәгән уңышлар юлдаш булыр. Алдагы эшләрне планлаштыру өчен яхшы вакыт.

Үгезбозау. Кызыклы, позитив һәм вакыйгаларга бай ай. Әллә кайчан планлаштырып куйган эшләрегезне, ниһаять, төгәлләрсез. Профессиональ яктан үзегезне уңышлы итеп күрсәтү җае чыгар.

Игезәкләр. Энергиягезне тиешле юнәлешкә борып җибәрсәгез, уңыш озак көттермәс. Эштә дә, шәхси тормышта да сөенечле вакыйгалар көтелә. Файдалы тәкъдимнәр ишетерсез.

Кысла. Рухи уяну, яңа белемгә омтылу чорына аяк басасыз. Булган мөмкинлекләрегезне бәяләп, җиң сызганып эшкә тотыныгыз. Яңа проектларга алыну өчен уңышлы вакыт.

Арыслан. Каршылыклы ай. Компромиссларга барырга кирәк булачак. Күчемсез милек, матди керем белән бәйле проблемалар белән шөгыльләнергә туры килер. Ай ахырына энергиягез артачак.

Сөмбелә. Очрашулар, аралашулар активлашкан чор. Партнерлык элемтәләрен ныгытырга омтылыгыз, киләчәк уңышыгыз һәм матди керемегез аларга бәйле булачак. Айның стихиясе күп һәм нәтиҗәле эшчәнлеккә корылган.

Бизмән. Катлаулы булса да, кызыклы вакыйгаларга бай ай көтелә. Позитив яңалыклар белән тормыш «ребус»лары чиратлашып торыр. Интригалардан сак булыгыз. Энергиягез кимеп киткән чак, моңа игътибар итегез.

Чаян. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылырга тора. Уйлаганыгыз белән мөмкинлекләрегез туры килә торган сирәк чорның берсе. Һөнәр өлкәсендә мөһим адымнар ясарсыз, яхшы хәбәрләр ишетерсез.

Укчы. Күп көчегезне өй, гаилә мәшәкатьләренә сарыф итәргә туры килер. Матди хәлегезне яхшыртырдай шәп тәкъдим ишетерсез. Күчемсез милек сатып алу, төзелеш, ремонт эшләрен башлау, яңа эшкә керешү өчен яхшы вакыт.

Кәҗәмөгез. Күңелле вакыйгаларга бай, гармонияле ай. Мөһим эшләр йорт, гаилә белән бәйле булачак. Очрашулар, сәфәрләр көтелә, чараларда актив катнашырга туры килер. Мәгълүматның барысына да ышанып бетмәгез, башта тикшерегез.

Сукояр. Тормышыгызның һәр өлкәсендә уңышлы перспектива көтелә. Иң мөһиме – яңалыклардан курыкмагыз. Энергиягез сүлпәнрәк булса да, уңышлар озак көттермәс. Тормышыгызга үзгәреш кертеп җибәрердәй кеше очрар.

Балык. Берьюлы бик күп вазыйфа башкарырга туры килер. Яңа эшкә керешер өчен кулай чор. Тәвәккәллекне, уйлап табуга маһирлыкны күрсәтер өчен шәп форсат туар. Башлаган эшләрегезнең нәтиҗәсен тоярсыз.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.







ҖИҢЕЛЛЕК, ХИС, ГРАЦИЯ!

Талантлы рәссам Илдар Сафин 1965 елда Әлмәттә туып-үсә. Әүвәл Казан сынлы сәнгать училищесын, аннары Ленинградтагы В. И. Мухина исемендәге сәнгать-сәнәгать училищесын уңышлы тәмамлый. Берникадәр вакыт Санкт-Петербургта эшләп ала. Соңрак гаиләсе белән Казанга кайтып урнаша.

Илдар Фоат улы, Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы буларак, бик күп күргәзмәләрдә, шул исәптән, 1986, 2014 елларда узган төбәкара «Зур Идел» күргәзмәсендә дә катнаша. Аның шәхси күргәзмәләре 1995 елда – Казанның «Ак Барс банк» галереясында, 1996 елда – Түбән Камада, Чаллыда, 2005 елда Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музеенда уза. 2016 елда, Татарстан Рәссамнар берлегенең 80 еллык юбилеена багышланган күмәк күргәзмәдә Илдар Сафин хезмәтләре дә экспозицияләнә.

2017 елда «Хәзинә» милли сәнгать галереясында «Балериналар» сериясеннән торган «В атласной тапочке, на пробке» дип исемләнгән шәхси күргәзмәсен ачып та, үз иҗаты белән тамашачыларны таң калдыра. 2019 елда исә шул ук галерея залларында Лев Толстойның тууына 190 ел тулу уңаеннан Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музее белән берлектәге «Лев Толстой. Казан хронологиясе. 1841–1847 еллар» дип аталган күмәк проект-күргәзмәне дә тормышка ашыра.


Искиткеч акварель әсәрләре – сәнгать хакында. Рәссам күп еллардан бирле балет темасында булып, элегант, зифа буйлы, матур сынлы, грацияле балериналарыбыз образларын сурәтли, аларның эчке дөньяларын, күңел халәтләрен яктырта. Балериналар – аның яраткан модельләре. «Балет сәнгате акварельгә хас җиңеллек, хисчәнлек белән аваздаш ул», – ди Илдар Фоат улы. Талантлы рәссам тагын бер үзенчәлекле акварель сериясе белән дә күпләр күңелен яулады. Бу серия кинематография сәнгате белән бәйле. «Яраткан кинофильмымдагы сюжет сүтелә барганда, экрандагы бер мизгел, бер кадр мине кинәт кенә үзенә җәлеп итә. Гадәттә, төп сюжет линиясе, төп персонажларның гамәлләре белән бәйле дә булмаска мөмкин. Әйтик, ул шушы фильмда тасвирланган гасыр атмосферасын төгәл сурәтләп бирүче кадр да була ала. Һәм мин шул мохит сурәтләрен сайлап алам да, аларны акварель әсәрләргә әверелдерәм», – дип аңлата оста.

Илдар Сафин киндергә майлы буяулар белән бихисап портретлар яза, иҗатында теләсә кайсы интерьерны бизәп торачак пейзажлар, натюрмортлар да шактый. «Мин үземне төрле техникаларда ясаучы югары профессионализмга ия рәссам дип саныйм. Нинди дә булса картина бүген тиешенчә килеп чыкмый икән, димәк, иртәгә мин бу мәсьәләне барыбер чишәчәкмен. Рәссам үсештә булырга тиеш», – дип ассызыклый әңгәмәдәшем.

2019 елда аны Акварельчеләрнең бөтендөнья ассоциациясенә кабул итәләр. Илдар Фоат улының хезмәтләре Гонконг һәм Пакистанда онлайн форматта узган мәшһүр халыкара күргәзмәләрдә күрсәтелә. Аның бер хезмәте рәссам-акварельчеләрнең 2022 елда Мәскәүдә оештырылган «Бер сулышта» Бөтенроссия конкурсы күргәзмәсе өчен дә сайлап алынып, югары бәяләнә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
















ИЛДАР САФИН



ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES




KazanExpress




ТАТМЕДИА



Я Маркет







АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама